Безнең Мирас

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

10

октябрь 2021

ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ

Сарманның бәхетле Фатыймасы

20 бит

Әби биргән сабак

86 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

10
(334)
октябрь 2021

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ильяс Җиһаншин
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рүзәл Мөхәммәтшин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Мөдәррис Әгъләмов

ТАРИХИ МИРАС

4 Алтын Урда тамгалары. *Д.Гайнетдинов*
9 Казан фаҗигасе
11 Сарманның Фәхерле бәете. *Н.Мәхмүтов*
14 XIX гасыр хәлегъ документы
16 «Учитель мулла Садыйк». *Д.Гарифуллин*
18 Нефтькә багышланган мөнәҗәт. *Ә.Шәрипов*
20 Сарманның бәхетле Фатыймасы. *Д.Кәшипова*
24 Сарманның атлы казаклары. *В.Ихсанов*
27 Сарманлылар Беренче бөтендөнья сугышында. *Г.Нуретдинова*
30 Сарман сәяси репрессия еллары шаукымында. *Ф.Салихова*

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

34 Сарман һәм Мөслим районнарының уртак тарих чорлары: 1963-1965 нче еллар. *Р.Шәфигуллина*
42 «Ай, авылда булырга!». *М.Фәйзи*

ТАТАР ГАМЕ

48 Фәрит Хөснуллин: «Үткәнебез – горурланырлык, киләчәгебез – өметле»
53 Җәфалый торган җанисәп. *Ф.Уразай*
58 Атлар, этләр һәм кешеләр. *Р.Җамал*
63 «Безнең мирас» котлый!

ДИНИ МИРАС

64 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
70 Дин дәресләре. *С.Бикбулат*

ӘДӘБИ МИРАС

74 Бөек шагыйребез Котб әсәренең Истанбул басмасы (1968). *Х.Миңнегулов*
79 Югалган дәфтәр. *С.Сөләйманова*
84 «Кешеләрне кызганам...». *А.Тимергалин*
86 Әби биргән сабак. *М.Әгъләмов*
88 Ризван Хәмиднең «Хан кызы» драмасында Сөембикә ханбикә образы. *Г.Каюмова*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

94 Гамьле затлар онытылмый. *Т.Галиуллин*
100 Аркаимга сәяхәт. *Л.Хәмидуллин*
104 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
106 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

110 «Зәңгәр күз» җыры

ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә...

БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Октябрь*

Заказ №Е-3899. Тираж – 2736 данә. Формат 70х100 1/16
Басарга кул куелды: 27.09.2021. Чыгу көне: 04.10.2021.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
Мөдәррис Әгъләмов

Имәннәр ваклана чыпага,
Кыялар бары тик чылана...
Тауларның һәм батыр ирләрнең
Тарихта урыны бер чама.

Мөдәррис Әгъләмов

Мөдәррис Әгъләмов, Муса Маликов, Сәнифә Рангулова һәм Марсель Галиев

Безнең мирас №10 октябрь 2021



МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ

(3.01.1933-21.12.2004)

Дәүләт теле

Күз төбен ярып, яшьләрем
Тәгәри телем-телем:
Акчага сугылмаган тел
Ул дәүләт теле түгел.

Кәнфит-перәннек алырга
Йөгергән бала-чага
Акчага сугылган сүзне
Хәрефләп таный ала.

Нәкъ шулай белеп үсә ул
Туган телнең бар тәмен:
Ни-нәрсә бер тиен тора,
Ни-нәрсә – бер тәңкәлек.

Әткәң-әнкәңнең теленнән
Назлы моң ташып тора;
Ул, дәүләт теле дә булса,
Бер башка ашып тора.

Мохтаҗларына ярдәмле,
Яманга гыйбрәтле ул –
Бары акчага сугылган
Тел генә дәүләтле ул. ■

Алтын Урда тамгалары

Дамир Гайнетдинов*

Садри Хәмид ясаган рәсем. Финляндия музеенда саклана.

Спектакль вакытында. Сәхнәдә беренче рәттә уңнан – Садри Хәмид, Хәсән Хәмидулла. 1930 нчы еллар. Ул чорда хатын-кыз рольләрен ирләр башкарган.

Садри Хәмид

Тамгалар турындагы мәкаләнең авторы Садри Хәмид (Sadri Hamid) 1905 елда Түбән Новгород губернасының Сергач өязендәге Актук (Яңапар) авылында Бәдретдин Хәмидуллин гаиләсендә дөньяга килә. 1870 нче елларда аның бабасы Хәмидулла Мөхәммәдрәхимов (Хәйретдин исемле бабасының атасы) Сергач якларыннан китеп, Финляндиядә сәүдә итә башлаган беренче татарлардан була.

Садретдин бик сәләтле бала булып үсә. Үз авылындагы мәдрәсәне тәмамлый һәм соңрак 14-15 яшьләрендә якыннары янына Финляндиягә күчә. Әмма туган ягын, үз авылының болын-кырларын сагынып яши һәм, «Садри Хәмид» исеме астында татарча шигырьләр язып, ата-баба туфрагыннан аерылган милләттәшләребезнең үзаңын арттырып тора. Шагыйрьне Финляндиядәге милләттәшләребезнең ислам диненнән ерагаюлары һәм татарлыкны онытулары бик борчый һәм бу аның шигъри юлларында да чагылыш таба.

* Дамир Гайнетдинов – тарихчы, Фин-угыр һәм Фин-Шәрык җәмгыятьләре әгъзасы.

Хәсән Хәмидулланың туенда. С.Хәмид – өченче рәттә уңнан беренче. 1925 ел

Татар баласына

Ана телең – татар телең якка селтәп ташлама!
Йөреп киткән юлларың да шул телеңнән башлана.
Нинди алтыннан да кыйммәт һәрвакытта үз телең,
Үз телеңнән син табарсың төрле гыйлемлек-белем.

Көйлә-сөйлә үз телеңне, үз телең нидән дә зур,
Ана телен сөйли белгән җир йөзендә булмый хур.
Һич оялма үз телеңнән, сөйлә ятлар бакканда да,
Шул тел белән кыл догаңны иртә, кич һәм ятканда да.

Оулу, Финляндия, 1946 ел

Садри Хәмид Финляндиянең Оулу шәһәрендә төпләнә һәм гомеренең зур өлешен шунда сәүдә белән шөгыльләнеп үткәрә. 1944 елда ул Хәят ханым белән тормыш корып җибәрә, аларның Илхан һәм Балкыр исемле ике уллары туа. Соңрак, олыгайгач, Садри Хәмид 1974 елда үз балалары янына Хельсинкига күчә. Ул 1987 елда вафат була һәм шәһәрнең татар каберстанына җирләнә.

Шигърияттән тыш, Садри Хәмид башка әсәрләр дә яза, мәҗмугалар әзерли. Шулай ук рәсем ясау, борынгы экспонатлар, почта маркалары җыю белән дә мавыга, үзенең хезмәтләрен китапчыклар рәвешендә бастырып та чыгара. 1967 елда Финляндиядә Садри Хәмид, Гомәр Таһир (Ymär Daher) һәм танылган фин тюркологы Мартти Рясянен Габдулла Тукай исемендәге мәдәни җәмгыять оештыра. Бу җәмгыять фин татарларының Советлар Союзында яшәгән милләттәшләре белән элемтәләр урнаштыруында бик зур роль уйный.

1967 елда Садри Хәмид кулдан язылган «Тавыш» журналын чыгара башлый. Бу исем белән мәҗмуганың барлыгы 6 саны чыгарга өлгерә. Халык арасында «Тавыш» исеме бик хуш каршыланмагач, журнал «Ак юл» дип атала башлый. «Ак юл» озын гомерле була, 1967-1977 нче еллар арасында аның барлыгы 63 саны дөнья күрә.

Садри Хәмид журналның 1970 елгы 30 нчы санындагы «Төрле тамгалар» исемле мәкаләдә укучыны Алтын Урда һәм аңа күрше булган дәүләтләрнең тамгалары белән таныштыра. Тарихи яктан гаять кыйммәтле әлеге язманы сезнең хозурга да тәкъдим итәбез. Безнең уйлавыбызча, Садри Хәмид бу материалны әзерләгәндә үзенең коллекциясендәге бай нумизматик материаллардан һәм борынгы китаплардан файдаланган булырга тиеш.

Төрле тамгалар

Авыл җирләрендә, ягъни Русиядәге игенчеләрнең үз тамгалары булган кебек, бөтен мәмләкәтләрнең дә үзләренә хас милли тамгалары бар. Һәм шулай ук патша, солтан, ханнарның да үз тамгалары билгеле. Ничә мең еллар элек яшәгәннәрнең дә тамгалары булып торган. Әле шунда кыска гына итеп шул тамгалар хакында язып узам:

Чыңгыз ханның тамгасы (милади 1160-1227).



Чыңгыз хан туганнары, нукларының (оныкларының) бергәлек тамгалары.

Бату ханның тамгасы (милади 1226-1256).

Бәрәкә (Бәркә) ханның тамгасы (милади 1256-1266).

Сәмәрканд солтаны Аляүтдин (Галәветдин) Мөхәммәднең тамгасы (милади 1195-1220).

Үзбәк ханның тамгасы (милади 1313-1339).

Алтын Урда ханнарының акчаларындагы тамга.

Тула Буга ханның тамгасы (милади 1287-1290).

Җанибәк ханның тамгасы (милади 1339-1357).

Олуг Мөхәммәд тамгасы (милади 1317-1321).

Килдебәк тамгасы (милади 1321-1330).

Туктамыш ханның тамгасы (милади 1376-1406).

Кырым ханнарының тамгасы.



Кырым ханнарының акчаларындагы тамгалар.



Афшин пантшаның (патша) тамгалары. Бохара (һиҗри 160).



Чатша (Ташкенд).



Иһшид (Иран).



Мөхәммәд әл-Ашрның тамгасы (һиҗри 144). Бу тамга «Мөхәммәд» дигән сүз була. Моны Габбасийә халифәсе әл-Мәһди әмир итеп куйган булган.

Баркуман (Сәмәрканд).

Иһшинид тамгасы.

Йәзит ибне Исәгыйт (һиҗри 159).

Хәлид ибне Йәзит (һиҗри 177).

Асад ибне Йәзит (һиҗри 185).

Мөхәммәд ибне Йәзит (һиҗри 195).

Әл-Мәмүр әл-Мөхәммәдия (һиҗри 195).

Хөсәен ибне Һәзим (һиҗри 187).

Шәмседдин Илдәгиз (Иран, һиҗри 531-568).

Арыслан ибне Тугрул (Иран, һиҗри 580-587).

Сәлҗук солтаны Гыядетдин (Гыясетдин) Дауд бине Мәхмүд (525-525). Төрекләр, шул тамгадан үрнәк алып, ай белән йолдызны вөҗүдкә (барлыкка) китергәннәр булырга кирәк.

Төркиянең хәзерге тамгасы – ай белән йолдыз. Татарларның үз милли тамгалары булмаганлыктан, шул ай белән йолдызны үз тамгалары кебек кулланалар. Чит мәмләкәтнең тамгасын тотарга ярый микән?

Сәлим II тамгасы (һиҗри 974-992). Мисыр.

Әхмәд III тамгасы (һиҗри 1115-1143).

Мәхмүд I тамгасы (һиҗри 1143).

Мәхмүд II тамгасы (1226-1263).



Гаяз Исхакыйларның үзләре ясаган тамгасы.



Финляндиянең иске милли тамгасы. Хәзер йөри торган берничә бакыр акчаларында шул тамга.

Украинаның милли тамгасы.



Литваның милли тамгасы.



Садри Хәмиднең «Яз хәбәрләре» исемле китабы. Оулу, 1948 ел ■

15 ОКТЯБРЬ – МИЛЛИ ДӘҮЛӘТЧЕЛЕГЕБЕЗНЕ САКЛАП ШӘҺИД КИТКӘН КАҺАРМАН БАБАЛАРЫБЫЗНЫ ИСКӘ АЛУ КӨНЕ

Казан фаҗигасе

Казанны яулап алу. ***XIX гасыр немец рәссамы Карл Вениг эше***

Бөек рус тарихчысы Михаил Худяков язганнарга нигезләнеп, Казан яулап алыну турындагы фаҗигале вакыйганы хәтердә яңартабыз…

Бу – Явыз Иванның Казанны бишенче мәртәбә камап алуы була. Баштагы һөҗүмнәр 1469, 1506, 1524, 1530 нчы елларда оештырыла. 1545 һәм 1550 нче елларда да шәһәрне алырга тырышулар барып чыкмый.

Мәскәү тарафдарлары коточкыч зур гаскәр һәм күпсанлы туплар белән казанлылардан өстенлек алуга ирешәләр: камаучыларның саны (150 мең кеше) саклаучылар санынннан (33 мең кеше: шуларның 30 меңе – казанлылар, 3 меңе – аларның аркадашлары булган нугайлар) биш тапкыр диярлек артып китә.

Арттан гел һөҗүм итеп торган атлы чирүне тар-мар итәр өчен, 1 (15) сентябрьдә руслар Биектауга юнәлә.

Аны яулап алып юк итәләр, аннары рус отряды Арчага һәм Арча җиренә ябырыла һәм, күп ганимәтләргә ия булып, кире Казанга кайта.

4 (20) сентябрьдә астан чокып кереп, кирмән кырындагы чишмәне шартлаталар. Ләкин, Казан эчендә сусаклагычлар күп булу сәбәпле, бу шартлатуның әллә ни әһәмияте булмый.

30 сентябрьдә (4 октябрь) кирмән диварын шартлатып, Мәскәү тарафдарлары һөҗүмгә күтәрелә, тик һөҗүм кире кагыла.

2 (16) октябрьдә тагын шартлату. Бу юлы Явыз Иван гаскәриләре шәһәргә бәреп керә.

«Гәүһәршадның соңгы алышы».
Зөфәр Хәкимов рәсеме

Урамнарда кул сугышы башлана. Күп урыннарда христианнар белән татарлар йөзгә-йөз килеп, бер-берсенең күкрәкләренә сөңгеләр бәреп, сәгатьләр буе чигенмичә сөңге очында торалар.

Бәреп керүгә үк шәһәрне таларга тотыналар. Рус яубашлары мародерларны үтерергә боера. Моннан соң гаскәрдә тәртип урнаша, каршы як яңадан һөҗүмгә күчә.

Казанлылар Кол Шәриф мәчете янында, Таҗик ермагында соң чиккәчә сугышалар. Кол Шәриф һәлак була. Шуннан соң Казанны саклаучыларның соңгы терәге булган Хан сарае яулап алына.

Шәһәрдә исә коточкыч суеш башлана, чөнки Явыз Иван гаскәренең яубашлары ир-ат затыннан булган бөтен кешене дә, шул исәптән ир балаларны да үтерергә фәрман бирә. Шәһәрдә үлекләр шулкадәр күп ята ки, бөтен шәһәр буйлап, мәеткә басмасаң, басар урын да калмый; Хан сарае ишегалды артында, шәһәр диварлары янында һәм урамнарда диварлар биеклегендәге таулар булып үлекләр ята. Казансу кан төсенә керә.

Шулай ук хатын-кызларга да шәфкатьсез булалар: патша аларны тулысы белән үз сугышчылары карамагына тапшыра. Кала Явыз Иван гаскәриләренә таларга бирелә.

Меңнәрчә асылташлар, бизәнү әйберләре, тукымалар, зур осталык һәм талант бәрабәренә генә ясала торган сәнгать әсәрләре янгында һәм җимерекләр астында юкка чыга.

*Текст **Михаил Худяков**ның «Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар» (1923) китабындагы мәгълүматларга таянып әзерләнде.* ■

Сарманның Фәхерле бәете

Назыйм Мәхмүтов

XX гасыр башында хәзерге Сарман районының Карашай-Саклау авылында Шәңгәрәй улы Фәхерле (1886-1926) һәм Миңнеҗамал гаилә корып яши башлый. Фәхерле сәүдә белән шөгыльләнә, тик җитеш гаиләнең балалары булмый. Нәсел калырга тиешлеген яхшы аңлаган Миңнеҗамал иренә икенче хатын эзли башлый. Тирә-як авылларны барлап чыгарга иренми, хәтта яшьләрнең кичке уеннарына кадәр йөри һәм хәзерге Сарман районына керүче Сөлек авылыннан Фәрхетдин кызы Кәшифәне (10.08.1895-12.05.1962) эзләп таба. Кәшифәнең ире Беренче бөтендөнья сугышыннан кайтмаган, балалары булмый. Каратут йөзле, чибәр Кәшифә Фәхерлегә хатын булып килә, Миңнеҗамал исә аларның гаилә тормышына башкача катнашмый. Әмма, гаиләгә матди яктан авыр булганда, гел ярдәм итеп тора. Мөмкинлеге дә булгандыр, чөнки ул хәзерге Мөслим районына караучы Тугаш авылындагы хәлле кешенең кызы була. Бәет текстында «җәмәгатьләрем», «хәләлләрем» дип әйткән урыннар бар. Фәхерленең Миңнеҗамал һәм Кәшифә әбиләргә эндәшүе була бу. 1926 елда Фәхерлене базардан кайтышлый үтерәләр. Аның ике баласы – 1920 елгы Габделәхәт һәм 1923 елгы Мәликә туган була. Бәеттә искә алынучы «ике бала» шулар инде. Ялгыз яшәү, балаларны ялгыз үстерү бик авыр булганлыктан, Кәшифә авылның Солтанморат улы Солтанмәхмүт (1904-1941) исемле егетенә кияүгә чыга. Аларның Габделхәй (1929-1992), Әзһәм (1932-2017), Кафия (1935) һәм Әмин (1941) исемле балалары туа. Солтанмәхмүт үги балаларына да рәхим-шәфкатьле ата була. Тик гомере генә озын булмый: Бөек Ватан сугышының беренче атнасында ук фронтка китеп бара, яралана, әсирлеккә эләгә һәм 1941 елның декабрь аенда Белорусиянең Масюковщина авылындагы лагерьда вафат була. Фәхерленең балалары – Габделәхәт (1920-1980) белән Мәликә (1923-2010) туган авылларында лаеклы гомер кичерә, Бөек Ватан сугышыннан да исән-сау кайталар, гаилә коралар, балалар үстерәләр. Хәзер вафатлар инде.

Бәет 1926-1927 нче елларда стандарт булмаган 35х22 см үлчәмле кәгазьгә гарәп хәрефләре белән нәсех ысулында кара белән язылган. Беренче биттә – 24 юл, икенче битнең бер ягында – 22, икенче ягында – 8 юл. Кульъязманың сакланышын уртача дип бәяләргә була, тик, кара очу сәбәпле, аерым юллар укылмый.

Текстны хәзерге хәрефләргә күчергәндә язылышны сакларга тырыштык, күп сүзләр борынгы әдәби стиль традицияләренә турылыклы булып бирелгән. Бу – бәет авторының укымышлы булуы хакында сөйли торган факт.

Журнал укучыларга шулай ук «XIX гасыр хәлегъ документы» дигән мәкаләмне дә тәкъдим итәм.

Бисмилләһ, дип башладым бу бәетнең башларын,
Базарлардин кайткан чакда әрәм булды башларым.

Бәндин калган күк атымны авыр йөккә җикмәгез,
Бәндин калган балаларны җәтим итеп йөртмәгез.

Бәндин калган күк алаша көзгә керсә симерә,
Бәндин калган ике балам, әткәем, дип тилмерә.

Улым, малларың кычкыра, алларында беткәндер,
Җылашмагыз, җәмәгатьләр, миңа вахыт җиткәндер.

Бәнем җиккән күк атым башын чайкай кайтадыр,
Әй, Кәшифә, ник килмисең, җаным чыгыб ятадыр.

Безнең Саклауның урамы кыйблаларга каршы,
Базарларга барганмын әҗәл(ләр)емә каршы.

Ак намазлыгымны җәеб, бән укыдым икенде,
Базарларга барырларга йөрәкләрем җилкенде.

Бәндин калган бүрекләрне чөйдән-чөйгә элегез,
Бәндин калган балаларны бәңа охшатуб сөегез.

Җәмәгатьләрем су ташый, ташый-ташый – суы юк,
Базарлардин кайтыб керде, гәүдәсе бар, җаны юк.

Безнең Саклау урамына дүрт багана какганлар,
Бән үлгәй читән дыяратны (зиратны) көчкә эзләб табканлар.

Йөгереб төштем, сулар алдым арҗак әрәмәләрдин,
Дыяратлары күренә безнең тәрәзәләрдин.

Быел тектергән чикмәнем, кыска булса да, таман,
Рамазан айларын ташлаб китүләре (бик) җаман.

Өстемдәге күлмәгем уймак-уймак уелган,
Бәнем зифа буйларыма каравыллар куелган.

Быел карлар бик вак ява, төймә-төймә тезелеп,
Ике балам бик саргая, әткәем, дип өзелеп.

Каты такта өсләрендә ята бәнем тәнләрем,
«Ятмыйм», – дәйүб әйтерләргә юк бит бәнем телләрем.

Бәнем салган келәтемнең тирә-ягы сары үлән,
Җыламыйсыз бит, хәләлләрем, мин бит әҗәлсезләрдән.

Иртән торыб тышка чыксам, сандугачлар сайраша,
Үтә язлар, җитә җәйләр, җәмәгатьләрем җылаша.

Җигеп йөргән тур(ы) атымның үреп куям җалларын,
Чаналарда алынды бит бәнем газиз җанларым.

Матур җәйләр җитә инде, (утыра) алмадым арбага,
Зекер-тәсбих әйтә алмадым, җаннар (к)иткән талларга.

Өйләремнең тәрәзәсе … пыяла.
Бәетләрем бәнем сезгә, догалар кылыгыз безгә.

Догалар кылыгыз безгә, ахыйрәтдә оҗмах сезгә! ■



Бәетнең тексты менә шундый кульязмаларда сакланып калган.

XIX гасыр хәлегъ документы

Безнең кулда саклана торган бу кульязма документ XIX гасыр азагына карый. Ул 17,5х22 см үлчәмле кәгазьгә нәсех ысулы белән гарәп хәрефләрендә язылган 16 юлдан гыйбарәт. Әлеге документ – «аерылышу кәгазе», ягъни ир ягы, хатын ягы бер-берсенә карата бернинди дәгъва булмавын шаһитлар алдында белдерә һәм дүрт як та имза сала: ир үзе, хатын, хатынның әтисе һәм шаһитлар.

Билгеле булганча, 1828 елдан башлап парларның аерылышу факты метрикә кенәгәләрендә теркәлә башлый. Шулай итеп, метрикә кенәгәләре язылышу һәм аерылышу вакыйгасын раслый торган төп чыганакка әйләнә. Имамнар татар телендә, кайбер очракларда рус телендә дә таныклыклар, кенәгәдән күчерелмәләр дә биргәннәр. Бу документларның исемнәре төрлечә булган: метрикә таныклыгы, күчерелмә, копия, шәһадәтнамә һәм кайбер очракларда иске традиция буенча «хәлегънамә» (аерылышу акты) дип тә атаганнар. Метрикә кенәгәләрен алып бару, аларга нигезләп таныклыклар бирү Диния нәзарәте тарафыннан даими күзәтелгән. Ләкин барыбер параллель рәвештә чын хәлегънамәләр дә язылган икән. Тарихчы Җәүдәт әфәнде Миңнуллин, мисал өчен, үз хезмәтендә шундый 8 документны тикшерә. Шуларның бишесе – берьяклы документ, өчесе – икеяклы акт үрнәкләре.

Без тикшергән документ – икеяклы хәлегънамә үрнәге. Ул татарда гаилә-никах мөнәсәбәтләренең кайбер якларын конкретлаштырырга мөмкинлек бирә. Без бит хатын-кызның бернинди хокукы булмаган, өч тапкыр «талак» сүзен ишеткән дә атасы өенә кайтып китәргә мәҗбүр булган дип уйларга өйрәнгәнбез. Чынлыкта ислам кануннары хатын ягын хаклый икән, документтан күрәбез: мәһәр тулысынча кайтарыла! Аерылышуга сылтау итеп «өлфәт мәхәббәт» юклыгы китерелсә дә, чын сәбәп уртак сабый булмауда; ниндидер сырхаулар аркасында, Бибишәрифә балага уза алмаган. Икенче хатынга өйләнгән Исхакның балалары була.

Шунысы игътибарга лаек: документта искә алынган Йосыф улы Исхакның, Хәлиулла улы Гибадулланың, Биктимер улы Бикмөхәммәднең нәсел-нәсәбе бүген дә Татарстанның Сарман районындагы Карашай-Саклау авылында яшәвен дәвам итә.

Текстның хәзерге язуга күчермәсе

(1) 1884 нче елда априлнең 12 нче көнендә Өфе губернасы Минзәлә өязе Нөркәй

(2) вулусы Иске Саклау *(Татарстан Республикасы Сарман районындагы Карашай-Саклау авылы)* аулында ясаклы *(дәүләт файдасына салым түләүче социаль катлам)* Исхак Йосыф углы *(соңыннан Габделгани кызы Бәдигылҗамалга өйләнәчәк, балалары Мотыйгулла (1897-1900), Хәкимулла (1890-1943), Мөхлисулла)* шушы вулусның

(3) Теләнче Тамак *(Татарстан Республикасының Тукай районы)* аулының типтәр *(татарлар арасында бер социаль катлам)* Гыйзбулла Госсаметдин углының кызы Бибишәрифә илән

(4) арамызда өлфәт мәхәббәт *(ике яктан да мәхәббәт)* юклы сәбәбле хәлегъ итгелде *(аерып җибәрелде)*. Хәлегъ бирелте: бер җон түшәк дәхи *(тагын)* бер җон



Хәлегъ документы. XIX гасыр

(5) ясдык вә һәм мәһәр муассилларга *(әйберләре)* вә һәм мануфакларны *(мануфактура)* вә һәм кисваи *(кием)* вә сиккинаи *(көмеш акча)* хакларындан аергай

(6) вә фәхелелмәк *(өстенлек)* шарты илән хәлегъ кылдым. Мән мәхлүгем Бибишәрифә Гыйзбулла кызы хәләл җәмәгатем

(7) Исхак Йосыф углы илән арамызда өлфәт вә мәхәббәт юклыг сәбәбле хәлегъ әйтүб, хәлегъ бирелгәй

(8) бер җон түшәк вә һәм бер ясдык вә һәм мәһәр могаҗәлләрендән гайре мануфакларындан вә кисваи,

(9) вә мугайанәт сиккиләремездән ибрәә шарт илән һичкемнең икрааһ вә иҗбар зарар *(үпкәләмичә, зарар китермичә)*

(10) гакылым дөрес хәлендә хәлегъ кыйлмакны кабул итдем. Растлыкны шаһидәеннәр хозурында

(11) махсус тамгам *(тамга)* салдым. Мән Габдейосыф углы хатыным Бибишәрифә Гыйзбулла

(12) кызының хәлегъ улуның кабул итүб мәзкүр шартлар илән шаһидәеннәр хозурында хәлег

(13) кылдым *(тамга)*. Шаһидлар Гыйбадулла Хәлиулла углы ошбу мәҗлестә улуб кулым куям.

(14) Бикмөхәммәд Биктимер углы ушбу мәҗлестә улуб тамгам *(тамга)* салдым.

(15) Мән Гыйзбулла Госсаметдин углы кызым Шәрифәнең җәмәгате илән хәлегъ мәҗлесендә сәгыйр улуб кызым ризалыкмагын

(16) ир киявем Исхакда низагыбыз калмай вә бу шаһидлар хозурында тамгам салдым.

Кереш мәкалә һәм текстларны журналга ***Назыйм Мәхмүтов*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №10 октябрь 2021

«Учитель мулла Садыйк»

Дамир Гарифуллин

Садыйк Хәмиди

Элекке Минзәлә өязенең күп кенә авылларында аны шулай атап йөрткәннәр. Яхшыбай, Иске Теләнче, Нөркәй һәм Теләнче Тамак авылларында, өяз үзәге Минзәләдә алтмышынчы, җитмешенче елларда аны белүчеләр бар иде әле. Сарайлы авылында яшәүче Вагыйзь ага Нуриәхмәтов, Җәлил поселогының ак әбисе Зәкия апа «Учитель мулла Садыйк» хакында сөйләргә ярата иде.

Күтәмәле авылында аның кызы Фатыйма апа Хәмидуллина яшәде. Гомере буе балалар укыткан бу ханым заманында Ленин ордены белән бүләкләнде, Сарман районының хөрмәтле кешесе булды. Әмма ул әтисе хакында сөйләмәде диярлек. Чөнки ул аннан сабый килеш ятим калган. Ә менә Казанда яшәүче кызы Суфия апа Улумбекова әтисе турында якты истәлекләр саклый иде.

Садыйк Әсәдулла улы – шактый гомерләрен Минзәлә өязенең Яхшыбай авылында үткәргән имам-хатиб вә мөдәррис, Коръәнгә тәфсир язучы Шәйхелислам һәм мәгълүм зыялыбыз Шакирҗан Хәмидиләрнең энесе. Ул хәзерге Чүпрәле районына кергән Татар Төкесе авылында 1883 елның 10 декабрендә (иске стиль белән) туа. Гасыр башында Казандагы «Учительская школа» дип шөһрәт казанган уку йортын тәмамлый. Шуннан соң аны «Учитель мулла Садыйк» дип йөртә башлыйлар.

Казанда укытучылар мәктәбен тәмамлагач, Садыйк Хәмиди Казан губернасына кергән Царекокшай өязенең Мөрки волостендагы Әлмәмәт авылының казна училищесында укытучылык итә башлый. Биредә ул 1910 елга кадәр балалар укыта. Җәй айларында Яхшыбайга әнисе һәм өлкән абыйсы янына кайткалап йөри. Гаилә корып җибәргәч тә, аның өчен абыйсы Шәйхелислам яшәгән йорт «төп йорт»ка әверелә. Әниләре Васфикамалдан туган барлык балалар да шушы йортка җыела торган булалар.

Минем кулда Шәйхелислам Хәмиди тарафыннан 1911 елның 15 мартында энесе Шакирҗанга Надеждинский шәһәренә җибәрелгән хат бар. Ул болай

башлана: *«Мөхтәрәмә әнкәмез илә мөхтәрәм борадәрләрем җанәбына, һәм киленнәргә, вә сеңлемә, вә балаларга сәлам»*. Әйе, Хәмидиләр гаиләсеннән бу вакытта биредә Шакирҗан белән Садыйк, аларның сеңелләре (икенче атадан туган) Мәргупҗамал, хатыннары Гайшә белән Маһирә һәм аларның балалары Әминә, Сафия һәм Суфия яшәгәннәр.

Төбәкне өйрәнүче Назыйм Мәхмүтов, Дамир Гарифуллин һәм Ләбиб Лерон

Садыйк Хәмиди 1910 елның 1 октябреннән Надеждинский урыс-татар училищесында укыта башлый. Шакирҗан исә бу вакытта биредә мулла була. Әмма 1911 елның 11 февралендә аны, советка каршы җыеннар җыюда гаепләп, Сарапул төрмәсенә илтеп ябалар. Менә шундый шартларда Садыйк Хәмиди әнисе һәм Хәмидиләрнең башка гаилә әгъзалары белән Яхшыбай авылына кайтып төшә. Бераздан Садыйк хәзерге Зәй районындагы Олоҗы авылында хәлфәлек итә башлый. Аннан соң алар Теләнче Тамак авылына күчеп киләләр. Биредә Садыйк Хәмиди мәдрәсәдә мөгаллимлек эшенә керешә. 1914 елда Иске Теләнче авылында казна хисабына мәктәп салына. Садыйкны шушы мәктәпкә чакыралар. Мәктәп бинасының бер башында шактый иркен фатир да була. Садыйк Хәмидиләр гаиләсе шунда яши башлый.

1919 елның язында Садыйк Хәмиди салкын тигезә һәм кыска вакытлы авырудан соң кинәт кенә вафат була. Якын-тирә авыллардан җыелган ир-атлар аны елый-елый соңгы юлга озаталар.

Шуннан соң Садыйк Хәмидинең гаиләсе өчен авыр заманнар башлана. Җиде баланың бишесе балалар йортына җибәрелә. Искәндәр белән Тәзкирә исемлеләре Яхшыбайда үлеп кала. Габбас белән Сафия исемлеләре Теләнче Тамак балалар йортыннан Семипалат балалар йортына озатыла. Ә 1921 елда әлеге балалар йорты таратыла һәм бу ике баланы казак кардәшләре тәрбиягә ала. Шуннан соң алардан хәбәр өзелә.

Казанда яшәгән Суфия апа Улумбекова да балалар йортында тәрбияләнә. Элекке чорның салкын карашыннан өшеп-туңып үсә ул. Хәмидине Хәмидуллина фамилиясенә әйләндерә. 1925-1929 нчы елларда Суфия апа Казан җир төзүчеләр училищесында (соңыннан ул техникум итеп үзгәртелә) укый.

Үзем дә җир төзүче булганлыктан, Суфия апа белән сөйләшәсе сүзләребез, уртак фикерләребез күп булды. Гомере буе карталар ясаган, сызымнар сызган кечкенә генә гәүдәле, мөлаем йөзле бу ханым мин танышканда 85 яшен тутырып килә иде. Зиһене ачык, хәтере әйбәт иде аның.

Суфия апа Фатих Кәрим белән бергә укыган, мелиорация төркемендә белем алган Абдулла Алишны да яхшы хәтерли иде. Әмма безнең сүзебез Хәмидиләр турында барды. Нибары 37 яшьтә арабыздан киткән «Учитель мулла Садыйк» хакында бик озак сөйләшеп утырган идек... ■

Безнең мирас №10 октябрь 2021

Нефтькә багышланган мөнәҗәт

Әнвәр Шәрипов

1950 нче елларда Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарында нефть чыга башлау, нефть сәнәгате барлыкка килүне татар халкы зур рухлану белән каршы ала. Бу як авыллардагы егетләр һәм кызлар нефть эшенә тартылалар. Әлмәттә Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге оештырыла. Язучылар һәм шагыйрьләр нефть чыгару, нефтьчеләр тормышы турында очерклар, хикәя, шигырь, повесть һәм романнар иҗат итә башлый. Ибраһим Газиның «Гади кешеләр», Гариф Ахуновның «Хәзинә» белән «Хуҗалар», Шамил Бикчуринның «Каты токым», белән «Тирән катлам» романнары һәм хикәяләре бу теманы яктырткан иң беренче күренекле әсәрләр булды.

Нефть темасы, әлеге төбәк тормышына үзгәрешләр керткән вакыйгалар үзләрен шагыйрь яки язучы дип исәпләмәгән гап-гади кешеләрне дә кулларына каләм алырга этәргән, аларны да шигырьләр, мөнәҗәтләр язарга рухландырган. Шундыйларның берсе – Шөгер бистәсендә яшәгән Кашшафетдин Нуретдинов. Ул 1958 елда «Нефте бәреп чыккан көн (Нефте мөнәҗәте)» дигән шигъри әсәр яза. Анда республикада нефть сәнәгате барлыкка килүгә татар халкының шатлануы чагылыш таба, вакыйгалар бары уңай яктан гына бәяләнә. Әлбәттә, ул әле нефть чыгаруның экологиягә зарар да китерәчәген, җир астыннан бәреп чыккан нефтьнең саксызлык аркасында елгаларга да агып төшәчәген, анда коенучы казларның кап-кара нефтькә буялып кайтачакларын, аларны тазарта-тазарта җәфа чигүләрне күз алдына да китерә алмагандыр.

Мөнәҗәт текстын Кашшафетдин агайдан Шөгер төбәгендәге фольклор әсәрләрен җыючы Хәлимә Ишбулдина-Мияссәрова 1970 елда күчереп алган. Бу әсәр Шөгердән килеп Алабуга пединститутында укучы студент аша минем кулга да килеп керде. Бүгенге көндә әлеге әсәр инде әдәби мирас булып санала ала. Шуңа күрә мин аны журнал укучыларына да тәкъдим итәм.

Нефте бәреп чыккан көн

(Нефте мөнәҗәте)

Дүрт класслык белем белән каләм алдым кулыма,
Шигырь язып калдырамын кызларым-улларыма.
И, Шөгерем, туган илем! Алтындыр балчыкларың;
Бездән табып алдылар бит девонның ачкычларын.
И, Шөгерем, туган ягым! Уйсуларың, тауларың,
Бакчадагы мәкләр кебек ата алсу таңнарың!
И, Шөгерем, таң алдыннан кычкыра гудокларың,
Шатланып эшкә йөгерә улларым, оныкларым.
Фидакяр көчләрен салып эшлиләр, салынмыйлар,
Башкортстан якларыннан бертотам калышмыйлар.
Бүгенгедәй истә әле нефть бәреп чыккан көн!
Капиталист илләрен дә артка бәреп еккан көн!
Нефть бәреп чыккан көнне бергәләп бәйрәм иттек,
Нефть тапкан геройларны кадерләп аштa йөрттек.
Шул көнне үк хәбәр иттек юлбашчы Сталинга,
Юлбашчы орденнар бирде нефтьче геройларга.
Начальнигы Шмаринны депутатка сайладык,
Наказларыбызны бирдек, чит илләрдән калма, дип.
Тирә-якны кинәндерде нефте-бензин, газына;
Безнең җир астынан чыга мәңге бетмәс хәзинә.
Шушындый бай җирләрдә дә ярлы яшәгән халык,
Тамагын да туйдыралмаган, эшләп тә арып-талып.
Ничә йөз ел хуҗа булып Романовлар яшәгән,
Халыкның бөтен байлыгын алар сатып ашаган.
Хәзер халык яхшы яши – оҗмах мисалларында,
Илем зур уңыш казанды минем күз алларымда.
Без хәзер яхшы яшибез, тормышыбыз җайланды,
Авыл-шәһәр аралары асфальт белән ялганды.
И, Шөгерем, туган илем! Хәзинәле гүзәл җир!
Булыр микән моның кебек хәзинәләр биргән җир!

Шигъри әсәр шул урында тәмам. Текстның башына Хәлимә Ижбулдина болай дип язып куйган: «Кашшафетдин Нуретдинов иҗат иткән 1948-1949 нчы елда, Шөгердә иң беренче нефть табу көннәрендә, 70 яшендә». Ахыргы юллары мондый: «Кашшаф абзыйдан күчереп алдым, фольклор материаллары җыючы Хәлимә Ижбулдина, 1970 елда».

***Редакциядән:** Танылган әдәбият галиме, тәнкыйтьче һәм журналыбызның даими авторы **Әнвәр Мәгъдәнур улы Шәрипов**ка 9 октябрьдә 80 яшь тула. Аны юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек белән хәерле озын гомер, уңышлар теләп калабыз!* ■

Безнең мирас №10 октябрь 2021

Сарманның бәхетле Фатыймасы

Дания Кәшипова*

Ф.Сираева (уңнан икенче) колхозчылар конференциясендә. 1969 ел

Бөек Ватан сугышы елларында авыл хуҗалыгы тулысынча хатын-кызлар җилкәсенә калды, дип әйтергә була. «Тылда – фронттагы кебек үк!» дигән девиз халыкның патриотик бурычны яхшы аңлавын күрсәтә. Республикабызның дистәләгән мең хезмәт кешесе аңа тугры булып кала. Шулар арасында мәкаләбезнең герое – 1924 елның 20 июлендә Чаллы кантонының Рангазар авылында туган Фатыйма Сираҗетдин кызы Сираева да бар.

Сугыш чорында һәм сугыштан соңгы елларда халык хуҗалыгын торгызудагы фидакяр хезмәтләре өчен Фатыйма апа 2 мәртәбә Ленин ордены белән бүләкләнә. Аның язмышы күпләргә үрнәк булырлык. Кечкенәдән әтисе Сираҗетдин һәм абыйсы Хөснетдингә ияреп беренче тырма эзе артыннан йомырка тәгәрәткән кызга җир эше, җир сулышы аеруча якын була. Рангазар авылы җирләрен сөрергә килгән беренче «Фордзон» тракторын күрү, районга беренче трактор алып кайтып, шуның белән яңа күмәк хуҗалык җирләрен сөрүче Рәүф абый да кечкенә Фатыйма күңелендә тракторчы булу теләген ныгыта.

Рангазар җидееллык мәктәбен тәмамлагач, укуга зирәк кызны хисапчылар әзерли торган курска җибәрәләр. Ләкин күңеле туган якларга тартыла Фатыйманың.

---

* Дания Кәшипова – Бөек Ватан сугышы һәм туган якны өйрәнү музееның директоры.

Әтисе Сираҗетдин түзми: күкрәгенә капланып елаган кызын алып кайтып китә. Кайткач, Фатыйма канатланып-дәртләнеп күмәк хуҗалыкның балалар бакчасында эшли башлый. Ләкин бер уй, бер теләк һаман тынгы бирми аңа: басуда трактор гөрелтесе ишетелү, урамнан дөбер-шатыр машина узып китү белән, йөрәге сулкылдап куя. Тимер атны иярләгәнче язмыш әле аны тагын бер кат сыный. 1939 елда Минзәлә педагогия училищесына укырга керә ул. Тик сугыш тормышка үз төзәтмәләрен кертә. Ир-атлар сугышка киткәч, бар авырлык карт-коры, хатын-кыз, бала-чага өстенә төшә. Шундый авыр көннәрнең берсендә Фатыйманы идарәгә чакыртып, дус кызлары белән бергә, Сарман МТСына тракторчылар әзерләү курсына җибәрәчәкләре турында хәбәр итәләр. Балачактан трактор йөртү турында хыялланган кызның күңелендә әллә нинди өермәле хисләр туа: булдыра алырмынмы дип уйлана ул, курсларны өч ай эчендә тәмамлап, күмәк хуҗалыкка кайтып эшлисе дә бар бит әле… Укытучылар тәҗрибәле, күбесе өлкән яшьтә була, дәресләр кыскартылган программа белән алып барыла. Шунда укыганда Фатыйма мәхәббәте Әхмәтзыяны очрата. Алар һәр кичне диярлек Сарманның озын урамнары буйлап йөри.

Курсны тәмамлап, тракторчы таныклыгын алгач, Фатыйманы Карамалы МТСына җибәрәләр. Бер курста укыган ахирәте Саҗидә белән икесенә бер трактор иярләп, ярыша-ярыша көнне төнгә ялгап эшли алар. Озак та үтми, Әхмәтзыяны сугышка алалар. Яшьләр, вәгъдәләр бирешеп, кавышырга өметләнеп аерылышалар. Әхмәтзыя хатларны еш яза. Фатыйма аларның берсен дә җавапсыз калдырмый.

Журналист Хәниф Хәйруллин якташыбыз Фатыйма Сираева турында «Фатыйманың бәхете» дип аталган документаль повесть язды, шуннан өзек китерәм: *«1943 елның кышында Чаллы механизаторлар училищесында өч ай укыды. Һәй, андагы интегүләр. Бер кабым ризык өчен тилмерүләр. Өйдән әллә ни арттырып булмый.*

Ф.Сираева (уңнан беренче) курсташы белән уку практикасында. Чаллы. 1954-1955 нче еллар

Ф.Сираева (беренче рәттә, уртада) XXXII район партия конференциясенең хөрмәтле кунагы. 1985 ел

Эләксә, бәрәңге белән чөгендер эләгә. Атасы сырхаулап китте. Өйдә энесе, тагын өч сеңлесе бар. Эшләп алган ипиенең дә яртысын фронт файдасына бирде. Өйдән сынык алу авыр тоелды Фатыймага. Әмма ничек итсә итте, очын-очка ялгады, башкалар белән бергә, алты айлык курсны өч айда тәмамлап кайтты. Аны тагын Карамалы МТСы карамагына җибәрделәр.

«Сиңа, Фатыйма, таякның авыр башы эләгә бу юлы, – диде аңа МТС директоры Биктимер Хисамов. – Кулыңнан эш килә. Берәр кеше бирербез, юллар бик өзелгәнче, көзен Ләшәү Тамак басуында ватылып калган тракторны алып кайтырга, шуның белән эшләргә туры килер», – диде. Шакмак ягып эшли торган бу тракторны хәзер кемнәр генә хәтерли икән?!

Пар ат җигеп, Каимә исемле кыз белән язгы көннәрнең берсендә алар әнә шул тракторны алып кайтырга дип чыгып киттеләр. Каимәнең, мескеннең, бер кабым ризыгы юк. Ярый Фатыйма бәрәңге алган иде. Мең бәлаләр белән тәүлек тулганда гына Ләшәү Тамакка килеп җиттеләр. Тракторның кайдарак калганын белештеләр. Сугыштан яраланып кайткан элекке ике механизаторны иярттеләр. Дүртәүләшеп, шәрә басуда чабата белән су ярып, бер атна иза чикте алар. Ашарларына бетте. Каимә, эскерт төпләрендә калган кибәкне җилгәреп, арыш җыйды, аны шунда ук трактор янында калайда куырып ашадылар.

Сарайлы урманыннан, 1941 елның әче салкыннарында өшеп корыган имәннәрне кисеп, шакмак әзерләделәр. Көн буе генераторны кыздыра алмый җәфаландылар. Кичкә таба гына тракторга җан керде. Соң булса да кайтырга ниятләделәр...

Күл буеннан 50-60 адым китмәделәр, трактор шарт-шорт килде дә тынып калды... ягулык беткән иде. Ул-бу булса дип, кабина өстенә шакмак тутырылган капчык салып бәйләгәннәр иде. Шуны алып, бункерга тутырдылар да кызып яна башлауны көттеләр. Тракторда кайтканда мотор җылысы белән җан иңгән аяклар шакмак салганда тагын бозлы су эчендә йөзделәр. Хәзер икесенең дә аяклары тоймас булды.

Каимә, чабатасын салып, кабинадан үрелеп, аларны бункер капкачы өстенә куйды, тула оекларын салып сыкты, аягын, башындагы шәлен алып, төреп утырды... Теше тешкә тими дерелдәгән Фатыйма чабата киндерәләрен кочка чиште. Ул да аяк киемнәрен киптерергә куйды. Арттан, бункер корпусыннан, кабинага җылы бәрә башлады. Фатыйма, өстен салып, җылы кермәс аякларын сырмасы белән төрде...»

Ләкин сынаулар әле бетмәгән була. 1944 елда яралы, билдән түбән гипсланган Әхмәтзыяны туган авылы Яхшы Каранга кайтаралар. Көчле рухлы Фатыйма сынатмый, көнне-төнгә ялгап эшли, атна дәвамында, төнлә булса да, ике-өч тапкыр Әхмәтзыя янына бара. Ләкин аларга кавышырга язмаган була, күп тә үтми, яралы егет күзләрен мәңгелеккә йома. Фатыйма өчен дөньяның чите кителә, бөтен кайгы-хәсрәтен эченә йотып, алны-ялны белми эшли дә эшли ул. Атна буе трактордан төшмичә, берүзе ике кеше өчен хезмә итә. Аннан соң гына тракторын алмашчыга тапшыра.

Еллар үтү белән күңел яралары тарала төшсә дә, Әхмәтзыяны алыштырырлык кеше очратмый Фатыйма. Әтисенә биргән вәгъдәсенә тугры калып, энесе Соббух, сеңелләре Мөһәллилә, Кәримә һәм Хөршидәне укыта. Аларны кеше итү өчен бөтен барлыгы белән тырыша.

Сугыштан соң күмәк хуҗалыкларны күтәрү эшен дә Фатыйма апа Сираева кебек тырыш механизаторлар башкарып чыга.

1950 ел аның күңелендә якты хатирә калдыра. СССР Югары Советы Президиумы Указы нигезендә Ленин ордены белән бүләкләнә ул. Илнең иң олы бүләгенә лаек булган Фатыйма бөтен барлыгы белән эшкә бирелә, һәр елны алдынгылар сафында була: Мактау грамоталары белән бүләкләнә, район авыл хуҗалыгы күргәзмәләрендә катнашып, җиңүче таныклыгы ала. 1951 елда аны ТАССР Югары Советы депутаты итеп сайлыйлар. Үзенең белемен арттыру өстендә дә эшли: Чаллы механизация мәктәбендә трактор бригадасы бригадирлары хәзерләү курсында укый һәм аны бары тик бик яхшы билгеләргә генә тәмамлый.

1959 елда Фатыйма җитәкләгән тракторчылар бригадасы районда иң югары уңыш үстерә. Ул янә район авыл хуҗалыгы күргәзмәсе таныклыгы һәм КПСС райкомы, Район Советы Башкарма комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

Күп тә үтми, күмәк хуҗалыклар эреләндерелә. «Җиңүче» күмәк хуҗалыгына Рантамак һәм Балтамак авыллары кушыла, комплекслы бригадалар төзелә. Техника җене кагылган Фатыйма апа Рангазар авылындагы комплекслы бригаданың техника буенча бригадир ярдәмчесе итеп билгеләнә, уңыш даулау бәйгесендә күмәк хуҗалык буенча да, район буенча да күп еллар беренчелекне бирми.

«Шулай итеп, Фатыйма Сираева Татарстанда хатын-кыз механизаторлар арасында бердәнбер ике Ленин ордены иясе була.

Истәлекле 1966 ел. Фатыйма Сираеваны партиянең XXIII съезды делегаты итеп сайлыйлар. Шул ук елда аның күкрәгендә икенче Ленин ордены балкый башлый. Шулай итеп, Фатыйма Сираева Татарстанда хатын-кыз механизаторлар арасында бердәнбер ике Ленин ордены иясе була.

1970 елда аңа «Татарстанның атказанган механизаторы» исеме бирелә. Күпме дәвамчылар үстереп, Сарман игенчеләренең берничә буынын тәрбияләгән Фатыйма апаны, механизаторлар һәм җитәкчеләр гомере буе олылап: «Безнең остазыбыз», – дип йөрткәннәр. ■

Сарманның атлы казаклары

Васил Ихсанов*

Сарманда табылган сөңге очлыгы һәм ук очы

Сарман районы авылларында «Атлы казак кебек төзгә басып торма» яки «Атлы казак кебек җан өстендә басып торма» дигән әйтемнәрне балачактан ук (1960 нчы еллар башында) әбиләрдән еш ишетә идек. Китаплар укый башлагач та: «Каян килгән безнең якка казаклар?» – дигән сорау туды. Төбәгебездә казаклар катнашында сугыш та булмаган, аларны халык чуалышларын бастыруда да файдаланмаганнар. Сарманнан берничә дистә чакрым ераклыкта Казаклар дигән авыл бар. Бу авыл атамасының тарихы да безне кызыксындырган сорау белән бәйле булып чыкты.

«Атлы казак кебек басып торма» әйтеменең килеп чыгышы белән кызыксынып, татар теленең диалектологик, этимологик һәм фразеологик сүзлекләрен карап чыктым. Аларда «турыга катып», «төзгә басып» яки, урысчалап әйтсәк, «смирно»га басып дип язылган. Әйтемнең килеп чыгышы тарих белән бәйләп аңлатылмый. Казак гаскәре регуляр гаскәр рәтенә керми һәм анда стройда йөрү кагыйдәләре бик кирәк булмаган. Ә менә «Атлы казак кебек җан өстендә торма» варианты бер китапта да телгә алынмый. Татарстан тарихы буенча югары уку йортлары һәм мәктәп дәреслекләрендә көнчыгыш районнарның тарихы чамалы гына яктыртыла, чөнки алар, ТАССР төзелгәнче, Казан губернасына карамаганнар. Сарман районы Минзәлә өязе составында башта – Оренбург, аннан соң Уфа губернасына кергән.

Минзәлә өязенә кергән Сарман һәм күрше-тирә районнарда яшәгән татарлар башкорт сословиесенә язылырга тырышкан. Чөнки башкорт булып язылганнар шактый өстенлекләргә ия булган. Аларны мәҗбүри чукындырмаганнар һәм рекрутлыктан азат иткәннәр. Башкорт булып язылганнарга армия хезмәте казаклык

---

* Васил Ихсанов – Сарман урта мәктәбенең тарих укытучысы.

хезмәте белән алмаштырылган. Казаклыкка ул милләттәшләре белән бер команда булып барган. Татар рекрут булып китсә, аңа башка тел мохитенә күчү һәм мәҗбүри чукындырылу янаган. Минзәлә өязе һәм Сарман төбәгендә байтак санлы керәшен татарларына армиядә дини проблема булмаган диярлек. Әмма аларның фольклорында да армиягә кагылышлы халык җырлары, мөселман татарларындагы кебек үк, тирән сагыш, кайгы белән сугарылган. Рекрутлыкка китмәс өчен алар качу, үз-үзен имгәтүгә кадәр барганнар. Хөкүмәт тә чаралар күргән. 1798 ел апрелендә Сенат, рекрутларның качуын булдырмас өчен, аларның һәр 50 кешелек төркемен сакларга 10 солдат, 2-3 унтер-офицер һәм бер обер-офицердан торган конвой булдыруны таләп иткән. Урысларда «забрить лоб» дигән әйтем нәкъ менә рекрутларга карый. Маңгай чәче кырылган православный динендәге качкын, бинага кергәч тә, баш киемен салып, түрдәге иконага карап чукынырга тиеш бит. Кыскасы, рекрутларның хәле бик мөшкел булган.

1799 елда патша Павел I фәрманы нигезендә, Сенат указ чыгара. Аның буенча Оренбург казак гаскәренә губернада яшәгән татар, мордва һәм чуашларны да язарга мөмкин була. Моңа сәбәп булып Урта Азия аша Иранга җибәрелүче казак гаскәренең санын арттыру ихтыяҗы торган. Шулай итеп, Оренбург һәм Уфа губерналары татар-башкорт авылларын кантон һәм юртларга, 20-50 яшьлек ир-атларны командаларга бүлә башлыйлар. Сарман һәм якын-тирә авыллар 11 нче кантонга караган.

Казаклыкта хезмәт итү ревизия сказкаларында күренеп тора. Авыллар буенча мәгълүматларны караганда, «казаклыкка китте» яки «казак хезмәтеннән кайтты» дигән юлларны еш очратабыз.

«Хезмәткә китүче казак, өйдән-өйгә йөреп, үзенә тиешле суммадагы акчаны һәм ризык-фураж өчен ашлыкны сорап басып торган. Болай да хәерче яшәгән халыкта нәкъ менә шул вакытта «Атлы казак кебек җан өстендә торма» дигән әйтем барлыкка килгән дә инде.

Безнең фикеребезчә, әйтемнең «Атлы казак кебек җан өстендә торма» варианты дөреслеккә күбрәк туры килә кебек. Чөнки казак хезмәтенә китүче үз хисабына сугыш аты, хәрби кием, корал, үзенә җитәрлек ризык, атына фураж табуны кайгыртырга тиеш булган. Ул хезмәткә киткәч, аның гаиләсе дә көн күрергә тиеш бит әле. Хәрби хезмәткә киткән казак ярты елдан алып берничә елгача өеннән, хатыныннан, балаларыннан аерылып читтә йөргән. Хөкүмәт казаклыкка китүчеләр турында да кайгырткан. Сенат указында, казакның чыгымнарын авыл халкы арасында бүләргә, диелә. Хезмәткә китүче казак, өйдән-өйгә йөреп, үзенә тиешле суммадагы акчаны һәм ризык-фураж өчен ашлыкны сорап басып торган. Болай да хәерче яшәгән халыкта нәкъ менә шул вакытта «Атлы казак кебек җан өстендә торма» дигән әйтем барлыкка килгән дә инде. Казак хезмәткә киткәч, чәчү, урып-җыю чорында авыл халкы аның гаиләсенә дә ярдәм итәргә тиеш булган. Кантон һәм юрт башлыклары да хәрби хезмәткә китүче казаклар өчен авыл халкыннан акчалата, ат һәм фуражлата, төрлечә алдап, мал җыйган. Урлау очраклары да булмый калмагандыр. Бу хакта күп шикаятьләр явуга карамастан, әлеге явызлыкны бетерә алмаганнар.

Сарман ягында мөселман татарлары казак хезмәтенә алына башлагач та, керәшен татарларында рекрут бирү дәвам итә. 1970 нче елларда районда нәшер

Карашай-Саклау мәктәбе музеенда сакланучы кылыч

origin ителүче «Ленинчы» газетасы журналисты Петр Алексеев керәшен фольклоры белән кызыксына һәм алардан бик күп ядкярләр язып ала. Безгә рекрут озатканда җырланган җыруның текстын газетада гомер буе эшләгән һәм районда беренче радиотапшыруларны оештырган Равил абый Гыймадиев бирде:

«Биек тауның башларында
Мики Пауаллары бау ишә.
Керәшен егетен алмасаң,
Беткәнмени сиңа татар, падиша!»

Тексттан аңлашылганча, керәшеннәр мөселман татарларның рекрутлыктан берникадәр җиңелрәк булган казаклык тормышыннан көнләшкәннәр, шундый җыру ярдәмендә, патшага үзләренең моң-зарларын белдергәннәр.

2016 елда Башкортстан архивында сакланган материалларга нигезләнеп, безнең як авыллары тарихын бәян иткән саллы китап чыкты. «История башкирских родов. Байлар» дип атала ул. Анда һәр авылда яшәгән казакларның исемлеге, яше, кайчан һәм кайдагы сугышларда катнашуы, хәрби дәрәҗәсе хакында бай мәгълүмат бирелә. Китапта татарларның 1803-1847 нче елларда күпләп казаклык хезмәтенә алынуы әйтелә. 1812 елгы Ватан сугышына баручыларның да саны аз түгел. 1813-1814 нче елларда Европаны Наполеоннан азат итү походларында да Сарман казаклары күпләп катнаша. 1979 елда безгә Чукмарлы авылыннан 10 класс укучысы ерак бабаларыннан калган, көмештән коелган «За взятие Парижа. 19 марта 1814» медален күрсәткән иде.

Сарман казакларын күп очракта Оренбург губернасы чикләрен кыргыз-кайсаклар (хәзеге казахлар) һөҗүмнәреннән саклау өчен җибәргәннәр. Бу аңлашыла да, чөнки алар шундагы халык телен, гореф-гадәтләрен бик яхшы белгән. Хәзерге Казакъстан җирләре Россия империясенә кушылгач, казакларга ихтыяҗ калмый. 1859 елгы ревизия материалларыннан күренгәнчә, 1853-1856 елгы Кырым сугышына районның урыс авыллары крестьяннарын гына алганнар. Мисалга, Языково исемле урыс авылыннан бу чорда биш крестьян рекрутлыкка киткән. Бу гадәти чордан күбрәк сан.

1874 елда гомуми хәрби йөкләмә кертелгәч, җирле халык казаклык хезмәтеннән азат ителә. Бабаларының кайчандыр казак булып йөргәнен хәзерге буын бөтенләй белми. Бу хакта ярты гасыр элек яшәгән картларның да искә алганы булмады. Бәлки, кызыксынучы кеше булмагандыр, сорамасаң, кем сөйләсен?! ■

Сарманлылар Беренче бөтендөнья сугышында

Гөлнара Нуретдинова*

Беренче бөтендөнья сугышы дүрт елга сузылып, миллионлаган кешенең гомерен өзә һәм көчле империяләрнең таркалуына китерә. Сугышта ул вакыттагы 59 мөстәкыйль дәүләтнең 38е катнаша. Сугыш 1914 елның 28 июлендә башланып китә, ә инде Германия 1 августта сугыш игълан иткәннән соң, аңа Россия дә кушыла. Илебез ике миллионнан артык сугышчысын югалта. Анда беренче мәртәбә кешеләрне күпләп үтерә торган кораллар, хәрби техника кулланыла: танклар, су асты көймәләре, самолетлар, агулаучы газлар һ.б. Коры җирдә сугышта төп рольне уйнаган иң эре ике континенталь дәүләт – Россия белән Германия – аеруча зур үзгәрешләр кичерде.

Төрле чыганаклар буенча, Беренче бөтендөнья сугышында миллионнан артык татар солдаты катнаша. Сугыш башлану белән илдә солдатларны мобилизацияләргә тотыналар. Уфа губернасының Минзәлә өязеннән сугышка киткән якташларыбыз сугышта зур батырлыклар күрсәтеп, дәүләтнең югары бүләкләрен алалар. Георгий хачы (Георгиевский крест, Георгий тәресе) – солдат даны ордены. Күпләр әлеге дәрәҗәле бүләкне, батырлык символы буларак, горур йөртә алмады. Белгәнегезчә, совет чорында әлеге сугышка һәм аның батырларына бик үк уңай караш булмады. gwar.mil.ru сайтында («Памяти героев Великой Войны» (1914-1918)) әлеге мәртәбәле бүләккә лаек булган якташларыбыз хакында менә мондый мәгълүматлар бар:

Гайнетдинов Мөхәммәтзакир – IV дәрәҗә Георгий тәресе ордены белән бүләкләнгән. Туган җире: Уфа губернасының Минзәлә өязендәге Әлмәтмулла волостеның Мортыш-Тамак авылы. Хезмәт иткән урыны: 49 нчы Себер укчылар полкы, рядовой. 1916 елның 20 мартында Рига шәһәрендә яралана. Сул аягы юк, бот сөягенең өчтән бере ампутацияләнгән.

Гобәйдуллин Кәрамулла – IV дәрәҗә Георгий тәресе белән бүләкләнгән. Туган җире: Уфа губернасының Минзәлә өязендәге Язекәү волосте. Хезмәт иткән урыны: Яңа Георгий крепостной артиллериясе, рядовой.

Минибаев Тимербай – IV дәрәҗә Георгий тәресе белән бүләкләнгән. Туган җире: Уфа губернасының Минзәлә өязендәге Әлмәтмулла волосте. Хезмәт иткән җире: 6 нчы Финляндия укчылар полкы, кече унтер-офицер.

Сәлахетдин Абдул-Касыйм – IV дәрәҗә Георгий тәресе белән бүләкләнгән. Туган җире: Уфа губернасының Минзәлә өязендәге Александровка-Карамалы волосте. Хезмәт иткән җире: 11 нче пехота, Псков полкы, рядовой.

Шәрифуллин Мөхәммәт – IV дәрәҗә Георгий тәресе белән бүләкләнгән. Туган урыны: Уфа губернасының Минзәлә өязендәге Нөркәй волосте. Хезмәт иткән урыны: 21 нче Төркестан укчылар полкы, укчы, вакыйга вакыты: 23.08.1916.

---

* Гөлнара Нуретдинова - Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге Башкарма комитеты сәркатибе.

Беренче бөтендөнья сугышында Сарман ягыннан киткән солдатлар да күпләп катнашкан.











1/ Мухаметъ Шарифулинъ
2/ стрѣлокъ
3/ срока службы 1912 года
4/ изъ крестьянъ Уфимской губ. Мензелинскаго уѣзда Мурковской волости.
5/ подъ судомъ и штрафомъ не былъ

За то, что въ бою 23 Августа 1916 года у высоты Люза Гура, подъ сильнымъ огнемъ противника установилъ утраченную связь съ сосѣдними наступающими частями чѣмъ содѣйствовалъ успѣху боя. п 19 ст67 Георг. Ст

Не и

***gwar.mil.ru* сайтында Сарманнан киткән фронтовикларның документлары тәкъдим ителгән.**



Беренче бөтендөнья сугышы фотолары. Араларында татар солдатлары да күп.

Сабелов Хаирнас Сабелович – IV дәрәҗә Георгий тәресе белән бүләкләнгән. Туган урыны: Уфа губернасының Минзәлә өязендәге Нөркәй волостеның Имән авылы. Хезмәт иткән урыны: 93 нче пехота, Иркутск полкы, рядовой, вакыйга вакыты: 05.03.1916-12.03.1916.

Шәңгәрәев Харрас – IV дәрәҗә Георгий тәресе белән бүләкләнгән. Туган урыны: Уфа губернасының Минзәлә өязендәге Сарман волостеның Катыш-Каран авылы. Хезмәт иткән урыны: 204 нче пехота, Ардагано-Михайловск полкы, рядовой.

Туганнарының истәлеге буенча, 1892 елда Уфа губернасына караган Минзәлә өязенең Әлмәтмулла волостендагы Сарман авылында туган Садретдинов Могыйн да Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Ул 1915 елда каты яралана һәм шул елны IV дәрәҗә Георгий тәресе белән бүләкләнә, сугыштан 1917 елда кайта. Бөек Ватан сугышы башланып 1 ел узганнан соң, 1942 елда Казан шәһәренә хәрби авиация заводына эшкә җибәрелә. 1950 елда вафат була.

***

Беренче бөтендөнья сугышы тәмамлануга йөз елдан артык вакыт үтте, бу сугышта катнашучылар күптәннән юк инде. Йөз ел элек барган сугыш, солдатларның батырлыгы турындагы белемнәрне киләчәк буынга бөртекләп җиткерү бик мөһим. Без бу дәһшәтле сугыш турында белергә, Ватанына чиксез мәхәббәтен сүз белән түгел, ә гамәле белән исбатлаган кешеләрнең исемнәрен һәрвакыт истә тотарга һәм хөрмәт итәргә тиешбез. ■

Безнең мирас №10 октябрь 2021

Сарман сәяси репрессия еллары шаукымында

Фәнүзә Салихова*

Үткән гасырның 30 нчы еллары уртасындагы сәяси хәлләр илебезнең тарихында аерым бер урын алып тора. Законнар гаять кырыслана, суд һәм судтан тыш хөкем органнары системасы киңәйтелә, алар «икелекләр» һәм «өчлекләр» белән тулыландырыла.

Социалистик милекне талаган өчен атып үтерү яки мал-мөлкәтен тартып алып, 10 елга төрмәгә ябу; Ватанга хыянәт иткән өчен, атып үтерү җәзасы карала. «Хыянәтче»нең гаилә әгъзалары, туганнары биш елга төрмәгә утыртыла яки сөргенгә сөрелә.

1935 елның языннан 12 яшьтән узган балаларга да Җинаять кодексының барлык маддәләре, шул исәптән атып үтерү турындагылары да кагыла. Туганнарга бер-берсе өстеннән әләкләү мәҗбүри бурыч итеп куела. Халык арасыннан дошманнар табу буенча өлкәләргә, районнарга план җиткерелә.

Татарстанда 1935 елда гына да хөкем ителгәннәрнең саны 2 мең кешедән артып китә, шуларның 11е атып үтерелә. 1937 елда хөкем ителгән кешеләр саны 6 меңгә диярлек җитә, аларның 2 меңнән күбрәген атарга хөкем итәләр. Ватанга хыянәт итүчеләрнең хатыннарын, балаларын кулга алу башлана һәм бу эш тиз башкарыла. Кулга алынучылар арасында рухи хезмәт өлкәсендә эшләүчеләр, колхозчылар, дин әһелләре, хәрбиләр күп була. Гаепләрен таныту өчен, кыйнаулар, имгәтүләр, хәтта кул-аякларын сындыру ысуллары да киң кулланыла. «Советка каршы», «колхозларга каршы» агитацияләр алып баруда гаепләүләр дә киң тарала. Алар буенча, кагыйдә буларак, үлем карарлары чыгарыла.

Татарстан Республикасында 1917-1987 нче елларда хөкем ителгән 50 меңнән артык сәяси, административ репрессия корбаннары һәм аларның гаилә әгъзаларының исемнәре Казан Кремле Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы җитәкчесе, сәяси тоткыннар хакындагы «эш»ләрне өйрәнүче Михаил Черепанов җитәкчелегендә әзерләнеп бастырылган Республика Хәтер китапларында мәңгеләштерелгән. Алар 27 томнан тора. Кулга алынганнарның 4696сы югары җәзага хөкем ителгән, 10 409 кеше тоткынлыкта вафат булган. Бу «эш»ләр РФ һәм ТР Дәүләт, ТР ФСБ һәм МВД архивларында һәм башка регионнарның архивларында сакланган.

Безнең районнан 639 якташыбызның исеме «Хәтер китабы» томнарында мәңгеләштерелгән, шуларның 597се – ир-атлар, 42се – хатын-кызлар. Репрессия дулкынына иң күп эләгүчеләр татар милләтеннән. Барлыгы 582 татар. Алардан кала руслар – 50, керәшеннәр – 6 һәм 1 грек милләтеннән булган кеше. 639

* Фәнүзә Салихова – Сарман районындагы Бөек Ватан сугышы һәм туган якны өйрәнү музееның фәнни хезмәткәре.

Репрессияләнгән хатын-кызларыбыз урман кисү хезмәтен башкарган.

кешенең 431е Сарман төбәгендә туган һәм туган җирләрендә яшәүчеләр. 54 якташыбыз туган авылыннан районыбызның башка авылына күченеп яшәгән һәм яшәү урыныннан репрессияләнгән. 127 сарманлы читтә яшәгән җирләрендә репрессиягә эләккән. Читтә туып, Сарман төбәгендә яшәгән һәм хезмәт куйган 27 кеше кулга алынган. 639 кешенең 86сы – үлем җәзасына, 126сы – концлагерьга, 124е – хезмәт белән төзәтү лагерена, 129ы ирегеннән мәхрүм ителүгә (ягъни төрмәгә) хөкем ителгән, 39ы төньякка сөргенгә сөрелгән, бер кеше Бөек Ватан сугышына җибәрелгән. Психиатрия бүлегенә дәвалануга – 2, эш белән төзәтүгә – 1, шартлы рәвештә җәза срогы алуга 15 кеше хөкем ителгән. 2 кешедән китмәү хакында имзанамә алынган. 13 кешегә хөкем карары бөтенләй кабул ителмәгән. 101 кешенең эше туктатылып, акланганнар. 32 кеше җәза срогы үтәгәндә вафат булган. 15 якташыбыз сугыш кырларында кулга алынып, хөкем ителгәннәр. Аларның күбесе Ватанына хыянәт итүдә гаепләнгән. Бу сугышчыларның үзләре генә түгел, гаилә әгъзалары да кулга алынып, хөкемгә тарыганнар. Репрессияләнүчеләрнең күбесе гади авыл кешеләре, гомер-гомергә крестьян-колхозчы булып хезмәт куючылар. Шулай ук хөкемгә тартылучылар арасында дин әһелләре дә күп. Барлыгы 55 мулла һәм 1 изге атакай.

Репрессияләнүчеләр төрле елларда акланганнар, ләкин 8 кешегә аклау хакында карар кабул ителмәгән. Алда тәкъдим ителгән актка күз салыйк: *«8 июня 1956 г. комиссия Прокуратуры СССР составила акт: на 1 июля 1956 г. из 413 находившихся в Казанской тюремной психбольнице 270 человек осуждены по*

НКВД төрмәләрендә җәзаланса да, атылуга хөкем ителсә дә, халкына һәм диненә хыянәт итмәгән Сарман кешеләре күп булган.

статье 58 УК РСФСР; некоторые из них томились в больнице с первого года ее основания – 1939-го, другие - в среднем по 10 лет».

1941-1945 нче еллардагы Бөек Ватан сугышы чорында миллионлаган совет кешеләренең гомере фронтта гына түгел, тылда да өзелгән. Кесәсенә бер уч башак уып, өендәге ач балаларына алып кайтучылар да, әрнеп ялгыш сүз ычкындыручылар да хөкем ителгәннәр.

Зөя утравындагы 5 нче хезмәт белән төзәтү лагере һәм төрмәсендә, Казан төрмәсенең психиатрия хастаханәсендә вафат булган тоткыннар арасында безнең Сарман районыннан да якташларыбыз шактый.

1873 елның 4 августында Мортыштамакта мулла гаиләсендә туган **Газизов Харис Габделгазиз улы**н (Мөхәммәтгазизов Мөхәммәтхарис Габделгазиз улы) язмыш Башкортстанның Чакмагыш районындагы Норлат бистәсенә урнаштыра. Көне-төне имана җиреннән кайтып кермәүче гади крестьян булып гомер сөрә ул, сәүдә итеп ала. Хатыны Нурлыбанат белән корган гаиләдә Галимә, Мөгаллимә, Мәүлиәзимә, Сәкинә, Разия, Салиха, Җәннәтеләсма, Закирә, Бәдригөлфүзә исемле кызлары һәм уллары Мөхәммәтсабир үсеп килә. Шушы зур гаилә 1930 елда Сарман РБКсы тарафыннан йорт-җиреннән һәм башка мөлкәтеннән мәхрүм ителгән. 1936 елның 23 сентябрендә Харис кабат кулга алынып, шул елның 2 декабрендә 58-10(16) маддәсе буенча хөкем ителгән. Хөкем карары җиңелләрдән булмый: 2 елга хокуклары чикләнә һәм 5 елга хезмәт белән төзәтү өчен Зөя утравындагы 5 нче колониягә озатыла. Шундагы авыр шартлардан 1941 елның 18 августында Харис агай вафат була. Ул 1991 елның 22 маенда гына аклана. Аның исеме «Хәтер китабы»ның 3 нче һәм 26 нчы томнарында мәңгеләштерелгән.

1895 елда Яңа Әхмәт авылында туган крестьян-колхозчы **Ибәтуллин Әшрәфулла**ның 5 баласы булган. ТАССР ГПУсы Өчлеге тарафыннан 1930 елның

30 гыйнварында 58-11, 58-10 маддәләре буенча хөкем ителгән. Ул икенче тапкыр 1937 елның 18 декабрендә кулга алына һәм 31 декабрьдә 10 елга хезмәт белән төзәтү лагерена җибәрелә. 1942 елның 24 декабрендә вафат була. 1989 елның 30 маенда аклана.

Кәлимуллин Габдулла Кәлимулла улы 1894 елда Бикәсаз авылында туган, Әлмәт районының Нариман поселогында яшәгән. Гаиләсе зур, 6 баласы булган. Бик җаваплы эштә – «Нариман-2» колхозы рәисе булып эшләгән. 1942 елның 11 ноябрендә кулга алынган. 1943 елның 11 февралендә ҖК 58-14 маддәсе буенча хөкем ителеп, 10 елга хезмәт белән төзәтү лагерена озатыла, мөлкәте конфискацияләнгән, 5 елга хокуклары чикләнгән. 1943 елның 20 маенда Зөя утравындагы 5 нче колониядә вафат булган. 1993 елның 20 маенда акланган.

1901 елда Сарман районының Драгун-Бикмәт авылында туган **Ксенофонтов Григорий Иванович** 1941 елның ноябрендә хөкем срогын үтәгәндә вафат булса, 1908 елда Иске Кәшер авылында туган Локманова Бәзи 1945 елның 7 гыйнварында бакый дөньяга күчә.

1905 елда Ләке авылында туып, Тукай районының Авлаш авылында яшәгән гади колхозчы **Миронов Иван Миронович** 1941 елның 10 февралендә 58 маддә буенча ТАССР Югары Суды тарафыннан 8 елга хөкем ителгән. Ул 1942 елның 13 апрелендә вафат була. 1992 елның 13 ноябрендә акланган.

1885 елда Татар Карамалысы авылында туган, гаиләсендә 3 баласы булган **Садыйков Һади Садыйк улы** аерым хуҗалыклы крестьян булып гомер итә, аннары «Мәдәният» колхозына керә. 1943 елның 11 июнендә 58 маддә буенча ОС НКВД тарафыннан 8 елга хезмәт белән төзәтү лагерена җибәрелә һәм 1943 елның 19 августында, хөкем срогын үтәгәндә, вафат була. Ул 1990 елның 8 июнендә генә акланган.

1883 елда Рантамак авылында туган, гаиләсендә 4 баласы үсеп килгән гади колхозчы **Шәрәфетдинов Камалетдин Шәрәфетдин улы** 1940 елның 18 июлендә 58 маддә буенча ТАССР Югары Суды тарафыннан 5 елга хөкем ителгән. Аның да гомере 1941 елның 30 ноябрендә хөкем срогын үтәгәндә өзелгән. 1992 елның 6 июлендә генә акланган.

1901 елда Шыгай авылында туып, Тукай районының Кызыл-Байрак поселогында яшәгән, «Дон» колхозында хезмәт куйган **Йосыпов Нургали Йосыф улы** 1943 елның 26 июнендә 58 маддә буенча ТАССР Югары Суды тарафыннан 10 елга хөкем ителә, мөлкәте конфискацияләнә. Ике кызының яраткан әтисе Нургали Йосыпов яңадан гаиләсен күрә алмый, 1944 елның 2 гыйнварында төрмәдә вафат була. Исеме 1993 елның 18 гыйнварында акланган.

Репрессия дулкыны хатын-кызларны да аямый. 1906 елда Минзәләбаш авылында туган, ике бала анасы **Тукришина Салиха Нуретдин кызы** 1941 елның 27 октябрендә 58 маддә буенча ТАССР Югары Суды тарафыннан 10 елга хөкем ителә һәм 1943 елның 16 мартында вафат була. 1903 елда Сарман авылында туган **Асылова Мәүгидә Гайсә кызы** исә 1944 елның 26 февралендә дөнья куя. 1907 елда Сарман районының Чукмарлы авылында туган **Сафиуллина Мәүҗидә Хисаметдин кызы** 1943 елның 21 июлендә вафат. 1897 елда Минзәләбаш авылында туган **Төхбәтуллина Сәрбикамал** 1943 елның апрелендә хөкем срогын үтәгәндә үлә. Тукришина Салиха Нуретдин кызы 1993 елның 24 маенда акланган. Ә башка хатын-кызларга аклау хакында карар кабул ителмәгән. Бу вафат булган якташларыбызның каберләре Успенск монастыре капкасы алдында.

Менә шундый аянычлы язмышлар... ■

Безнең мирас №10 октябрь 2021

Сарман һәм Мөслим районнарының уртак тарих чорлары: 1963-1965 нче еллар

Язгы ташуны күзәтү. 1969 ел

Совет Социалистик Республикалар Союзының административ-территориаль бүленешен үзгәртеп кору 1962-1963 нче елларда, СССР Министрлар Советы рәисе Н.С.Хрущев инициативасы буенча, халык хуҗалыгы белән идарә итү системасын реформалаштыру кысаларында үткәрелә. Реформа барышында Советлар Союзы составында барлыкка килгән сәнәгать һәм авыл районнары – административ берәмлекләр шактый эреләндерелгән (узган чорда – 1962 ел азагы-1963 ел башы – 3421дән 1711гә кадәр кимегән) кайбер республика, край һәм өлкәләрдә сәнәгать районнары (122) барлыкка килгән. КПССның җирле органнары һәм Хезмәт Ияләре Депутатлары Советлары икътисади районнар белән идарә итү өчен сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы районнарына бүленгән, бу партия-совет идарәсенең җирле органнары санын икеләтә арттыруга китергән.

РСФСР Югары Советы Президиумының 1963 елның 1 февралендәге Указы белән автономияле республикаларда, крайларда һәм өлкәләрдә районнар эреләндерелә һәм шуңа бәйле рәвештә кайбер районнар бетерелә.

Татарстан АССР

46 район һәм республика карамагындагы 6 шәһәр урынына 17 авыл районы, 1 сәнәгать районы һәм 8 республика карамагындагы шәһәр булдырылган.

«ТАССРның партия һәм Совет органнарын үзгәртеп кору турында»гы РСФСР ҮК бюросының 1963 елның 25 гыйнварындагы карары нигезендә, гамәлдәге 46

райком урынына 17 партия, колхоз-совхоз идарәләре, 3 партия комитеты, 17 авыл һәм 3 сәнәгать районы барлыкка килү сәбәпле, 3 партия комитеты төзелә. 1964 елда өстәмә рәвештә 3 авыл районы барлыкка килә.

Илкүләм алып барылган эреләндерү сәясәте Сарман һәм Мөслим районнарына да нык кагылып, аларның үсеш тарихына йогынты ясый. ТАССР административ берәмлекләрен эреләндерү нәтиҗәсендә, 1963 елның 1 февралендә Мөслим районы бетерелә, аның биләмәләре Минзәлә һәм Сарман районнарына тапшырыла. Гомумән алганда, бу чорларда районнарның административ бүленеше тотрыклы булмый һәм чикләр әледән-әле үзгәреп тора.

1935 елны Мөслим районы җирләренең бер өлеше шул ук елны барлыкка килгән Калинин районына кушыла һәм районның мәйданы 1261 км^2 тәшкил итә. 28 Авыл Советына 77 авыл керә, аларда барлыгы 36 мең кеше исәпләнә. 1959 елның 12 октябрендә район тормышына тагын үзгәреш кертелә. Ул да булса, Калинин районы бетерелә һәм бер өлеш Авыл Советлары Мөслим районына кушылып, районның мәйданы 1593,3 км^{2}га җитә. 19 Авыл Советы 96 торак пунктны берләштерә.

Эреләндерү сәясәте Сарман һәм Мөслим районнарының байтак авылларын мәңгелеккә югалтуга китерә.

50 кешедән кимрәк халык яшәгән торак пунктларны исемлектән сызганнар яки эрерәк авыл белән берләштергәннәр. Бу чорда колхозлар саны да ике мәртәбә кимегән. Хәттә уртакул авыллар да күченгән.

Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты тарафыннан 2016 елда бастырылган «Исчезнувшие населенные пункты Республики Татарстан» дип аталган белешмәлектә узган гасырның 60 нчы еллары башында Сарман һәм Мөслим районнарына караган юкка чыккан авыллар турында мондый мәгълүмат бар:

АЮПОВО (Аюп), поселок.

Находился на территории современного Сармановского района Республики Татарстан, в 120 км от железнодорожной станции Бугульма, в 51 км от пристани Набережные Челны. С 1930 в составе Юлтимировского сельсовета, с 1948 – Янурусовского сельсовета Сармановского района. Население – 78 чел. (1930, татары), 75 чел. (1939, татары), 86 чел. (1963, татары). В справочных изданиях после 1963 года не упоминается.

ИРЕКЛЕ, поселок.

Находился на территории современного Муслюмовского района Республики Татарстан, в 122 км от железнодорожной станции Бугульма, в 88 км от пристани Набережные Челны. С 1944 в составе Варяш-Башского сельсовета Муслюмовского района, с 1963 – Муслюмовского сельсовета Сармановского района. В справочных изданиях после 1963 года не упоминается.

КИТЫСОВО (Китыс), поселок.

Находился на территории современного Сармановского района Республики Татарстан, в 73 км от железнодорожной станции Бугульма, в 84 км от пристани Набережные Челны. С 1930 в составе Яхшикаранского, с 1948 – Рантамакского, с 1963 – Александровского сельсоветов Сармановского района. Население – 71 чел. (1930, татары). В справочных изданиях после 1963 года не упоминается.

КУЛЬТУРА, поселок.

Находился на территории современного Сармановского района Республики Татарстан, в 87 км от железнодорожной станции Бугульма, в 79 км от пристани Набережные Челны. С 1930 в составе Александровского сельсовета Сармановского

района. Население – 41 чел. (1930, русские), 82 чел. (1939, русские). В справочных изданиях после 1963 года не упоминается.

РАССВЕТ, деревня.

Находилась на территории современного Муслюмовского района Республики Татарстан, в 121 км от железнодорожной станции Бугульма, в 110 км от пристани Набережные Челны. С 1930 в составе Ново-Усинского сельсовета, с 1956 – Горбуновского сельсовета Муслюмовского района, с 1963 – Новоусинского сельсовета Сармановского района. Население – 164 чел. (1939, русские), 76 чел. (1963, русские).

СПАССКИЙ, поселок.

Находился на территории современного Сармановского района Республики Татарстан, в 133 км от железнодорожной станции Бугульма, в 83 км от пристани Набережные Челны. С 1930 в составе Богдаровского, с 1948 – Рантамакского сельсоветов Сармановского района. Население – 151 чел. (1930, русские). В справочных изданиях после 1963 года не упоминается[1].

Сарман районы архивында эреләндерү политикасына кагылышлы документлар саклаган. (Документ үзгәртелмичә бирелә)[2].

Решение

Исполкома Сармановского районного Совета депутатов трудящихся Татарской АССР №361

с.Муслюмово 14 сентября 1964 года

Об исключении из списка административно-территориального деления некоторых населенных пунктов Сармановского района Татарской АССР.

Исключить из списка административно-территориального деления:

1. Поселок Мугез-Елга Старо-Дрюшевского сельского Совета Сармановского района в связи с переселением жителей в другие населенные пункты.

2. Поселок Урняк Верхне-Чершилинского сельского Совета Сармановского района в связи со слиянием границ с населенным пунктом Усаево и впредь именовать населенный пункт Усаево.

3. Исключить из списка административно-территориального деления поселок Александровка, поселок Совхоза и Муслюмовский /поселок центральная/, деревня Элемтэ Михайловского сельского Совета, в связи со слиянием границ с населенным пунктом Михайловка и впредь именовать населенный пункт Михайловка.

4. Исключить из списка административно-территориального деления Удельный Суранчак Ниже-Табынского сельского Совета в связи со слиянием границ с населенным пунктом Верхний Суранчак и впредь именовать населенный пункт Верхний Суранчак.

5. Просить Президиума Верховного Совета Татарской АССР утвердить настоящее решение.

[1] Исчезнувшие населенные пункты Республики Татарстан: справочник / под ред. Р.В.Шайдуллина. – Казань: ОП «Институт татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ», 2016. – 320 с.

[2] Сарман районы архивы, ф.1, оп.1, ед.хр.№161, лист 180.

Председатель исполкома Сармановского райсовета /А.Валеев/

Секретарь исполкома Сармановского райсовета /А.Зарипова/

Димәк, ике районның да байтак авыллары, кызганыч ки, яшәүдән туктый. Ә бу, үз чиратында, шул авылда яшәгән кешеләрнең нәсел җепләре өзелүгә, милләтнең дә рухи һәм мәдәни тамырлары югалуга китерә.

Икътисади һәм социаль яктан үсеш алган ике районны берләштерү ансат кына узмый. Оешмалар, авыллар тормышын бер тәртипкә салу, ике тапкыр диярлек арткан мәйдан һәм халык белән яңача идарә итәргә өйрәнү район җитәкчеләренең төп мәсьәләсенә әйләнә. Сарман район Башкарма комитетының 154 нче карары нигезендә, Мөслим районы азык комбинатын Мөслим азык комбинаты итеп калдыралар. (Сарман район архивы, 1 нче фонд, 1 нче опись, саклау берәмлеге №1, 94 бит.) Мондый үзгәрешләр барлык оешмаларга да кагыла.

Сарман районы архивында 1963-1965 нче елларга караган бик күп кызыклы документлар сакланган. Шул документларга карап, ике районның кушылып торган чордагы тормышын күзәтергә була. Ул чорда берләштерелгән район 34 Авыл Советына бүленә.

Биредә район Советының 9 нчы чакырылыш 1 нче сессиясенә килгән Авыл Советы рәисләренең исемлеге тәкъдим ителә (1963 ел): Сарман (М.М.Моратов), Янурыс (Локманов Ф.Л.), Петровка (Мортазин), Чукмарлы (Вахитов), Кәшер (Гарифуллин), Имән (Һадиева), Мортыш Тамак (Исмәгыйлев), Ләшәү Тамак (Каюмова М.), Минзәләбаш (Мирханова), Александровка (Җәмилова), Рангазар (Нуриәхмәтов), Кәүҗияк (Юнысов), Сармашбаш (Мифтахов), Иске Дөреш (Фәррахов), Чыршылы (Высоцкий), Карашай Саклау (Закиров), Нөркәй (Газетдинова), Саклаубаш (Әхтәмова), Түбән Табын (Хәйруллин Н.), Мәллә Тамак (Хәмидуллин), Михайловка (Солтанов), Мөслим (Искәндәров), Салауз Мухан (Нуриәхмәтов), Түбән Усы (Смылов), Иске Карамалы (Хафизов А.), Бәек (Шәгалиев), Октябрь (Теләнче) (Рахмаев), Төйгелде (Шәмсетдинов), Баланлы (Гарифуллин Н.), Керәш Шуран (Мәрдисламов), Шуган (Костина М.), Әмәкәй (Галиев), Исәнсеф (Хафизов), Уразмәт (Хәбибрахманов)[3].

Чор үзгәрешләре әби-бабаларыбыз тормышында чагылыш таба. Тормыш үзгәргән саен, яшәү рәвешенә яңалыклар өстәлә. Такыр юллар күтәртелә, ә күп урыннарда асфальт түшәлгән юллар салына. 1963 елда кабул ителгән бюджетта төзекләндерү (юлларны тәртиптә тоту) өчен 40 мең сум акча карала.[4] Планга Мөслим-Төйгелде ягына 3 км юл салу турында пункт кертелә.[5]

ТАССР Хезмәт Ияләре Депутатларының Сарман районы Советы Башкарма комитетының 1963 елның 20 февралендә кабул ителгән карары нигезендә, Мөслим авылында Колхозара картлар йорты ачыла. Аның директоры итеп Тимербай Миргарифан улы Галиев билгеләнә[6]. Картлар йорты өчен элеккеге Мөслим районы Башкарма комитеты урнашкан бинаны сайлыйлар[7].

Искергән мәктәп биналарын төзекләндерү эше актив җәелдерелә. Түбән Табын сигезьеллык мәктәбе каршында 50 урынлык интернат ачыла. Мәллә Тамак,

[3] Сарман районы архивы, ф.1, оп.1, ед.хр.№161, стр. 52.
[4] Сарман районы архивы, ф.1, оп.1, ед.хр.№161, стр. 117.
[5] Сарман районы архивы, ф.1, оп.1, ед.хр.№161, стр. 115.
[6] Сарман районы архивы, ф.1, оп.1, ед.хр.№154, лист 86, стр. 187.
[7] Сарман районы архивы, ф.1, оп.1, ед.хр.№161, стр. 258.



Кичү

Ләшәү Тамак, Михайловка, Симәк авылларында күмәк хуҗалыклар, колхозчылар ярдәмендә 320 урынга исәпләнгән мәктәпләр төзелә. Мөслим урта мәктәбендә пионервожатыйлар әзерли торган төркем ачыла.[8]

ТАССР Хезмәт Ияләре Депутатларының Сарман район Советы Башкарма комитеты һәм парткомы Бюросы белән берлектә үткәрелгән утырышта кабул ителгән карардан өзек (2 июль, 1964 ел):

«Мәгариф отличнигы дигән мактаулы исемгә тәкъдим ителгән укытучылар:

• Хакова Фәрхенур – Мөслим авылы мәктәбенең тарих укытучысы;

• Исламова Әлфинур Ислам кызы – Зур Чакмак сигезьеллык мәктәбенең биология укытучысы;

• Устеряков Петр Афанасьевич – Шуган мәктәбенең немец теле укытучысы».

1963 елның ноябрь аеннан Сарман мәгариф бүлеген 1931 елда Мәллә Тамак авылында туган Тәлгать Миңнехан улы Миңнеханов җитәкли.

Районның мәйданы бик зур булу сәбәпле, аны Сарман һәм Мөслим зоналарына бүләләр. Һәр зонага җаваплы кешеләр билгеләнә. Коммуналь предприятиеләр һәм төзекләндерү оешмасына Сарман зонасы буенча 1924 елда туган Җәүдәт Гайнетдин улы Гайнетдинов, Мөслим зонасы буенча 1926 елда туган Мансур Сәләхетдин улы Сабиров билгеләнә. Район белән 1917 елда туган Михаил Константинович Мамаков җитәкчелек итә.

Бу чорларда авылларны төзекләндерүгә, юллар салуга, яңа объектлар төзүгә зур игътибар бирелә. ТАССР хезмәт ияләре депутатларының Сарман район Советы Башкарма комитетының 1963 елның 18 февралендә кабул ителгән 66 нчы карары нигезендә Мөслим авылында урам утлары үткәрү өчен бюджеттан 1200 сум акча бүленә[9].

Башкарма комитет балансында булган мөлкәтне мохтаҗ оешмаларга таратталар. Документтан өзек[10]:

«1. Район Советы башкарма комитеты балансында булган 1000 (бер мең сум) сумлык күк айгырны, тулы комплект ат сбруен һәм бер данә кошовканы Мөслим коммуналь хуҗалык бүлегенә тапшырырга.

2. Район Советы башкарма комитеты балансындагы 400 (дүрт йөз) сумлык туры бияне, тулы комплект ат сбруен һәм бер данә кошовканы Мөслим Авыл Советына тапшырырга».

Сәламәтлек саклау системасында да үзгәрешләр була. Иске, салам түбәле ФАП (фельдшер-акушерлык пункты) биналары урынына яңаларын төзү проблемасы көнүзәк мәсьәләгә әйләнә. 1963 елда Сарманда, Александровкада, Теләнче Тамак-

[8] Сарман районы архивы, ф.1, оп.1, ед.хр.№156, лист 22, стр. 22.
[9] Сарман районы архивы, ф.1, оп.1, ед.хр.№161, стр. 93.
[10] Сарман районы архивы, ф.1, оп.1, ед.хр.№161, стр. 189.

та, Останковода, Сарсаз-Тәкермәндә, Мөслимдә, Карамалыда, Совхозда, Яңа Спаста участок хастаханәләре була. ФАПлар саны – 100гә, фельдшерлык-сәламәтлек пунктлары – 4кә, балалар ясленәре – 8гә, күмәк хуҗалык бала тудыру йортлары 2гә җитә.

1964 елның декабрь аенда Мөслим хастаханәсенә баш табиб итеп аңа кадәр Сарман район хастаханәсенең баш табибы вазыйфасын башкарган Хәбибуллин И.А. билгеләнә. Аның ярдәмчесе Шәйдуллин Хәниф Исмәгыйль улы була.

Советлар Союзы чорында, декрет ялыннан соң эшкә чыккан хатын-кызларның хәлен җиңеләйтү максатыннан, 1937 елда барлыкка килгән балалар ясленәре дәүләт сәламәтлек саклау системасына карый. Бала туганнан соң әни кешегә бары 8 атна ял бирелгән, димәк, яслегә китерелгән сабыйларга нибары 8 атна булган.

Ясле дә балалар яшь буенча 4 төркемгә бүленгән: күкрәк балалары (9 айга кадәр), «ползунковая» (9-14 ай), урта (14-24 ай) һәм зурлар (2-3 яшь). Һәр төркемдә тиешле режим сакланган, табиб күзәтүе билгеләнгән.

Мөслим авылында – 45 (мөдире – Суфия Әгъләм кызы Әгъләмова), «Мөслим» совхозында – 20 (мөдире – Рәмзия Бикмөхәммәт кызы Хафизова), Ташлыяр авылында 20 урынлык (мөдире – Нәсиха Нуретдин кызы Нуретдинова), шулай ук Төйгелде һәм Баланлы авылларында да ясленәр эшләп килә.

1964 елда ТАССР Югары Советы Мактау Грамотасы белән бүләкләнүгә тәкъдим ителгән медицина хезмәткәрләре:

- Нурия Гайсә кызы Гайсина – Мөслим хастаханәсе шәфкать туташы;
- Банат Нури кызы Шәрифуллина – Мөслим хастаханәсе шәфкать туташы;
- Ольга Ивановна Кунакова – Мөслим хастаханәсе акушеркасы.

Үзгәрешләр тормышның барлык өлкәләренә дә үтеп керә. Район матур күрсәткечләргә ирешә. Мәгариф, сәламәтлек саклау, төзекләндерү эшләре гөрләп бара.

Язгы чәчү, көзге урак вакытларында төрле өлкәләрдә эшләүчеләр, агитбригадаларга берләшеп, кыр хезмәткәрләре өчен концертлар оештыралар.

ТАССР Хезмәт Ияләре Депутатларының Сарман район Советы
Башкарма комитеты[11] карары №159

Сарман авылы 16 апрель, 1963 ел

1963 елның язгы чәчү чорында культура хезмәте күрсәтү өчен район учреждениеләре хезмәткәрләрен вакытлыча агитбригадага җибәрү турында.

Быелгы язгы чәчү чорында авыл халкына культура хезмәте күрсәтү максатыннан чыгып, агитбригадалар оештырырга. Агитбригада составына район учреждениеләреннән вакытлыча хезмәткәрләр җибәрергә.

Район Советы Башкарма комитеты карар бирә:

Язгы чәчү чорында авыл халкына культура хезмәте күрсәтү максатыннан чыгып, агитбригадалар оештырырга. Агитбригада составына район учреждениеләреннән түбәндәге иптәшләрне алырга:

1. Миргалимов Илгизәр – Тл.Тамак урта мәктәбе;
2. Исхаков Фәиз – Таулык авыл клубы мөдире;
3. Мөхәммәтҗанов Шамил;

[11] Сарман районы архивы, ф.1, оп.1, ед.хр.№154, лист 104, стр. 297.

4. Фәйзуллина Рәмзия – Райсобес;
5. Исламов Мостафа – Алга авыл клубы мөдире;
6. Гайнетдинова Роза – Мөслим больницасы;
7. Әхмәтвәлиев – Мөслим пионерлар йорты.

Агитбригадада йөрү вакытында хезмәт хакларын эшләгән эш урыннарында түләргә.

Район Советы Башкарма комитеты председателе /А.Вәлиев/
Район Советы Башкарма комитеты секретаре /А.Зарипова/

Ике район аркылы өч зур, мул сулы елга ага. Минзәлә, Мәллә һәм Ык елгалары ел саен язгы ташу вакытында ярларына сыеша алмыйча агалар, бәләкәй, тотрыксыз күперләрне су ташкыны бар дип тә белмичә агызып китә. Бу вакытларда елганы кичү бары көймә, паром ярдәмендә генә мөмкин була.

Мөслим авылында агач күпер 1934-1935 нче елларда күмәк хуҗалык көче белән төзелә, 1947 елда ул язгы ташу вакытында агып китә.

Фикрәт Табеев 1968 елда КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретарена сайланганда сайлаучылар күпер төзүне аңа наказ итеп җиткерәләр. Төзелешне проектлау, башкару Бөтенсоюз дәүләт «Гидромонтаж» трестының Зәй монтажлау участогына йөкләнә. (Җитәкчесе – В.И.Гонцов, баш инженер – В.А.Маслаков, проект авторы – В.С.Макаров.) 1970 елның 22 августында В.И.Ленинның тууына – 100, ТАССР оешуга – 50, Мөслим районының 40 еллыгына 222 м озынлыктагы күпер кулланышка тапшырыла.

Сарман авылындагы Минзәлә елгасы аша салынган 74 метрлык күпер 1940 елны халык көче белән төзелә, 1965 елда аны яңарталар.

Шул чордагы тагын ике кызыклы документка күз салыйк.

Решение Исполкома Сармановского райсовета депутатов трудящихся Татарской АССР №108, с. Сарманы 30 марта 1964 г.

О закреплении парома переправочных и моста строительных работ на реке Ик колхозу им.Кирова.

В целях улучшения переправочных работ на реке Ик во время весенних распутиц и учитывая письменную просьбу членов правления колхоза им.Кирова от 21 марта 1964 г. №57, Исполком районного Совета решает:

1. Предложить дорожному отделу Исполкома райсовета временно на сезон передать колхозу им.Кирова, паром /двух паромных лодок/ и двух малых деревянных лодок с 4мя веслами по акту.

2. Разрешить колхозу им.Кирова пользоваться переправочными средствами с продажей билетов за услуги согласно установленного расценка Исполкомом райсовета.

3. Для организации ремонта переправочных средств и строительства временного моста выделить одного работника из Сармановского РДО и 65 м.куб. лесоматериала из Муслюмовского лесничества.

4. Предупредить председателя правления колхоза им.Кирова тов. Мусина о том, что вся ответственность за своевременное обеспечение организации паромной переправы и строительства моста через реку Ик возлагается лично на него и в случае срыва этой работы, по отношению его будут приняты самые строгие меры.

5. Контроль за выполнением настоящего решения возложить на тов. Закирова М. и обязать его не позднее 28 марта с.г. доложить Исполкому райсовета о выполнении настоящего решения.

Председатель Исполкома Сармановского райсовета /А.Валеев/
Секретарь Исполкома Сармановского райсовета /А.Зарипова/

Решение Исполкома Сармановского райсовета депутатов трудящихся Татарской АССР №108, с. Сарманы, 3 апреля 1963 г.

О размере платы за поромные и лодочные переправы через реку Ик в 1963 году
Исполком райсовета решает:
Разрешить дорожному отделу Исполкома райсовета взимание на паромные и лодочные переправы через реку Ик в 1963 году в следующих размерах:

1. От пешеходов в один конец 10 коп.;
2. От подводов порожных, одно конных в один конец 30 коп.;
3. От подводов с грузом одноконных в один конец 50 коп.;
4. От подводов порожных парных лошадей в один конец 50 коп.;
5. От подводов с грузом парных лошадей в один конец 70 коп.;
6. От автомашин ГАЗ-51 без груза в один конец 2 руб.;
7. От автомашин ГАЗ-51 с грузом в один конец 3 руб.;
8. От автомашин ЗИС без груза в один конец 2 руб. 50 коп.;
9. От автомашин ЗИС с грузом в один конец 3 руб. 50 коп.;
10. От тракторов С-80 в один конец 6 руб.;
11. От автомашин в один конец 1 руб. 50 коп.;
12. От мотоциклов в один конец б/коляски 30 коп.;
13. От мотоциклов в один конец с коляской 50 коп.;
14. От разных сельхозмашин 2 руб.;
15. От крупно рогатых скотов на 1 голову – 50 коп.;
16. От мельких скотов на 1 голову 10 коп.;
17. От грузов I категории на 1 тонну 70 коп.;
18. От грузов II категории на 1 тонну 1 руб.

Председатель Исполкома Сармановского райсовета /А.Валеев/
Секретарь Исполкома Сармановского райсовета /А. Зарипова/

1963-1965 нче елларда үткәрелгән административ берәмлекләрен эреләндерү реформасы үзенең нәтиҗәсез булуын бик тиз күрсәтә. Нәтиҗәдә, 1963 ел ахырында бетерелгән районнарны торгызу процессы башлана: 1964 елда – Әгерҗе, Алексеевск, Әлки һәм Апас районнары, 1965 елның 12 гыйнварыннан, башка районнар белән берлектә, Мөслим районы да торгызыла.

Сарман һәм Мөслим районнарының 1963-1965 нче еллардагы уртак тарихы сакланган. Чор сәясәтенә уралган вакыйгалар никадәр генә күп булмасын, аларның тарихи бөтенлеген, эзлеклелеген саклау – безнең бурычыбыз.

Регина Шәфигуллина,
Сарман муниципаль районының Бөек Ватан сугышы һәм туган якны өйрәнү музее фәнни хезмәткәре ■

ДРАМАТУРГ МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИНЕҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

«Ай, авылда булырга!»[1]

Мирхәйдәр Фәйзи

Казан пристане

Казан. 1923, сентябрь-октябрь

Самарадан тиз кузгалдык. Теплоход кетер-кетер итеп су үренә йөзәргә тотынды. Кош кебек бик очып китә алмый малаең. Харис абзый аркасында расходым җиңеләйде. Пароходта көн аларның азыгы белән генә үтә. Алма, бөрлегән пироглары, каз итләре, итләр – бар да бар. Бик һәйбәт тозланган каз ите бик кадерле хатирә булып калды.

Нурвисал апай миннән һич качмый инде. Бергә сөйләшеп, туганлашып барабыз. Шәфкать белән генә карап торган хатын-туганның ардагы *(кадер-хөрмәте)* астында бару җанга бик кадерле нәрсә.

8ендә Волганың ягасындагы агачлыкларның, күкле-яшелле-кызыллы-сарылы булып, егерме төрле төскә кергән рәвешенә сокланып, матурлыгына хәйран булып барабыз. Көн бик һәйбәт. Теплоход күкрәгендә тибрәлеп, тирәне карап барулар чиксез күңелле.

Ташкенттан Нижнийга бара торган карт сартның укучы сыйныфыннан булган җегет угылы Сәгыйтьбәк Корбангалиев белән дә таныштым. Әдәбият һәм язучылар белән таныш бу үзбәк баласы белән дә адреслар алыштык. Хатирә дәфтәренә дә яздырып алды. **«Беренче үзбәк танышыма»**, – дип яздым. Үзбәкчә журналлар биреп укытты. Ямьле әсәр калдырды.

---

[1] Көндәлекләрдән кыскартып бирелә. – **Ред.**

Мирхәйдәр Фәйзинең олы абыйсы – тәнкыйтьче, мөхәррир, тәрҗемәче Харис Мөхәммәтзариф улы Фәйзи (1871-1933) гаиләсе. Сулдан уңга: хатыны Әсма Әхмәт кызы кечкенә улы Әкрам (5 яшендә үлә) белән, Мидхәт (уртада), Шәүкәт (утырган), Харис Фәйзи һәм аның янәшәсендә булачак бөек композитор Җәүдәт Фәйзи, артта – бала караучы ханым. Оренбург, 1915 ел

Мин йоклап уянганда, Казанга җиткән идек. Сәгать 2 нче иде. Пристаньга төшеп урнаштык. Мин Хәдичә ханымнарга барачак булдым.

9ында без сәгать 8 булганны көтеп, берәр кисәк нәрсәбезне сакларга калдырып, трамвай белән Казанга бардык. Хәдичә ханымнарга барып төштек. Алар Сәмигулла Сәлимовлар белән бер ишегалдында, бер йортта торалар икән. Шулай итеп, Хәдичә ханым мине нумерга төшү расходыннан коткарды.

Наркомземга барып Мәсгуд Фәйзине күрдем. Харис абзыйлар нумерына барып, Нурвисал апай янында утырып чыктым. Комбинатка кереп чыктым. Нәгъләтләр, пьесаларымны әле матбагага бирмәгәннәр.

10сында Әхәт белән Һади Такташка бардык. Байтак утырып чыктык. Дәүләт театрына барып, Рәфгатьне күрдем. Әпсәләмов, Тинчурин, Тарханов, Колмәмәтләр белән күрештем. Сәмигулла абзыйларга кердем, чәй эчтем.

11ендә Наркомпроска бардым. Байтак кешеләр күрдем. Комбинатка барып, Ибраһим Кулиев белән Зәбирине күрдем. Сөйләштем, урыннар сораштым.

Обедта сөйкемле җегет Мөхәммәт Кулиев белән сөйләшеп утырдым. Ул миңа ягымлы тоела. «Фәрештә»не укып чыккан икән. «Ул уйналса, халыкның авызында шул гына булыр», – ди. Үзе бик яраткан. Ярый, бер татар җегете ярата торсын әле.

Мәркәз көтепханәгә барып, Суфия Таһирова туташны күрдем. Урын сорадым. Эшчеләр арасында булырга теләп, Бишбалта, Яңа Бистәләрдән урын табып бирүләрен үтендем.

12сендә, чакыруы буенча, Әхмәт Гомәровка бардым. Озак утырып, яхшы сүзләрен ишеттем. Кайдан теләсәм, шуннан урын табып бирергә булды. Үзе язган пьесаларны күрсәтте, укыды, киңәште.

Урда[2] җегетләре янына бардым. «Болгар»га төшкәннәр икән. Алмалар, баллар, печеньеләр белән чәй эчерделәр. Бергә Державин бакчасына бардык.

Хәдичә ханым бик яхшы карый, кунак итә. Урнашканчы тор, авырсынмыйм, ди. Рәхмәт яхшы сүзенә. Разыя исемле тагы бер сеңлесе килде. Бик күңелле булды. Карталар уйнадык, алмалар ашадык.

Кич Сәмигулла абзыйларга кердем. Әхмәт исемле авылдан килгән энеләре белән таныштым. Харис абзый да килде. Алма бәлешләре, вареньелар белән тәфсилләп чәй эчтек. Аннан Зөһрә ханым белән көтепханәгә бардык. Суфия туташ белән миңа урын хакында сөйләшеп кайттык.

14ендә. Ашау-эчүне мөмкин кадәр читтә үткәрергә карыйм. Столовойда обедать итәм. Шулай да Хәдичә ханым үз хисабына тамакланырга да мәҗбүр иткәли.

Садри Җәләл фатирына барып, «Сәрвиназ» дигән хикәямне карарга калдырдым. Хатыны белән таныштым.

15ендә Большой Проломныйда Хәким Сәлимҗанов белән очраштым. Бишбалта көтепханәсен карарга бардым. Шәһәрдән аерымрак, җыраграк, әлбәттә. Трамвай белән бардым һәм кайттым. Үзе, һавасы, көтепханәсе – бар да ошады. Торырга ярый икән дип уйладым. Минем өчен муафыйк җир төсле күренде. Тынрак, рәхәтрәк, мин теләгәнчәрәк ул.

Зөһрә ханым чакырып чәй эчерде. Үзебезгә кереп ашап йөр, тартынма, теләгән вакытыңда сорап аша, ди. Шөкер, сыенып урыннар бар. Ул да бәхет.

Көненә бер-ике кадак алма ашап торам.

16сында көтепханәләрнең «Районный комитет политпросвет»лары белән сөйләшер өчен Пороховойга киттем. Дамбаны, вагонга утырмый, җәяү үттем. Сахрадан, тирәкләр арасыннан бару үзе бер хозур булды. Бишбалтадан Ягодный Бистәгә, аннан Пороховойга чыктым. Ягодный белән ике араны аерган Казанка суын күрдем.

Пороховойда заводлар, фабрикалар күп кенә, халык та йөреп кенә тора. Райкомга кереп сораштым. Заведующийлары урыс икән. Пороховойдамы, Татар эшчеләре клубындамы калдыру дәртенә төште. Мин Бишбалта көтепханәсен кайгыртып килгән идем. Шулай да Пороховойда эшче халык күбрәклеген уйлап, күңелем бу якка да тартылып куелды. Пороховойны да яратып кайттым. Ләкин Казанның үзе белән араның җыраграгы аптыраткалый.

Бүгенге сәяхәтемдә трамвайга утырмадым. Көнне 15 сумлык алма белән генә уздырдым. Арып кайттым да кайтышлый ук Проломныйдагы бер столовойга кереп жаркой ашадым.

---

[2] Хәзерге Казакъстанның Бүкәй Урдасы. – **Р.Ш.**

17сендә Толчокка чыгып йөрдем. Халык кырылып сәүдә итә. Күмәч, булки, алмалар алдым. Әллә ничә җирдә гармун уйныйлар. Һәммәсе дә татарлар. Бөтен дөньямны онытып тыңлап тордым. Җанланып, рәхәтләнеп киттем. Авылга барасым килеп, Казаннан бизеп куйдым. Их, авыл, авыл! Авылда бүгенге кебек ком бураннары да булмас иде бит.

Күземә күренәме дип торам, Тәүфикъны очраттым. Тәүфикъны – Уфада торганда көннәремне ямьли торган сөйкемле малайны, яшь кенә дустымны очраттым. Ул сельхозтехникумда укый икән. Күп сөйләшеп тордык. Күңелләнеп, аны күрү белән бәхетләләнеп калдым.

Көтепханәгә барып, Суфия туташ белән сөйләштем. Урыннар барын, булачагын белдем. Тик 15 көнсез рәсми урнашырга гына мөмкин түгел. Яңа Бистәдә дә урын булачак, аны да барып кара, дигәч, кесәмә бер кадак юл азыгы тутырдым да, анда киттем. Ул да җырак кына икән. Җиттем. Бер авыл кебек кенә җир икән. Сабын заводы янындагы көтепханәгә кердем. Һәйбәт бинада. Ул яктан ярыйсы. Заведующие Ваһапов белән дә сөйләштем. Ләкин һич як белән Бишбалта, Пороховой тәэсирләрен бирә алмады. Күңелемне тартып калмады. Татар хатыннарының таныш рәвешләре, гел татарлар очравы беркадәр вәгъдәләр биреп торса да, әллә нәрсәкәйләре генә гайрәтемне чигерде.

«
Татар хатыннарының таныш рәвешләре, гел татарлар очравы беркадәр вәгъдәләр биреп торса да, әллә нәрсәкәйләре генә гайрәтемне чигерде.

Өйгә кайтканымда Фатыйма туташ язып утырадыр иде. Кып-кызыл алма бирдем. «Алма» алманы ашады.

18ендә Наркомпроска бардым. Садри Җәләл «Сәрвиназ»ымны яратмый кайтарып бирде. Марксизм идеологиясенә хилафтыр шул. Ләкин матурлыгын кем инкарь итәр. Шул ук Садри, вәгъдәсе буенча, главполитпросвет мөдире Хафиз Сәйфигә алып кереп таныштырды. Көтепханәләрдән урын бирүне сорады. Ул, вәгъдә биреп, иртәгә райком башлыгын чакыртып сөйләшергә булды. Миңа килергә кушты. Теләгән урының бирелер, диде.

Кич Хәдичә ханым, Фатыйма, Рәхимәләргә «Ак калфак»ны укыдым. Аларга ошады, мактадылар.

19ында. Көзнең шушы көннәрендә, ай, авылда булырга! Юлыкның урман араларында Вафалар, Вәлиләр, Саматлар, Гәрәйләр, Хөсәеннәр, Миңлегали Манаповлар, Шәрәфетдиннәр, Әхмәтләр, Бәхти Габдуллалары, Гарифулла Фәйзуллиннар, Мөхәммәтгалиләр белән гармун уйнап-җырлап, әйттереп утырсаң икән.

Главполитпросветка бардым. Сәйфи үзе үк күреп, чакырып алды. Райком политпросвет мөдире – урыс та бар. Тагы бер татар җегете. Минем белән сөйләштеләр, сораштылар. Кайдан урын телисең, диләр. Үзләре Пороховойга татар эшчеләре клубына куярга телиләр. Көтепханә мөдире, труппа руководителе исеме белән ике жалунияле ике урын тәкъдим итәләр. Квартир мәсьәләсе хәл ителсә, мин кунәчәк булдым. Теге урыс белән дә озак сөйләшеп утырдым. Эшләү юлларын өйрәтте. Бик ипле, сөйкемле яшь кенә җегет ул. Эш вакытында да булышлык итәрмен, ди. Кызыктырды, фатирны да кайгыртырмын, диде. Нәтиҗә бер-ике көннән беленәчәк булды. Тугрысы гына, мине урын белән тәэмин итүдә вәгъдәләр даусыз булмады. Һәммәсе тырыштылар. Эш үземнән генә калды. Булмый калса да, үземнән генә булачак.

Самолеттан Казан кремле күренеше.
1937 ел. *С.Фридлянд фотосы*

«Сөембикә манарасын карарга бардым. Моңарчы янына ук барып караганым юк иде. Крепостьның эченә кереп, янына бардым, капкасыннан үтеп йөрдем. Кулларымны тигездем.

Бер кондитерскийга кереп, бер стакан сөт белән бер булки ашадым. Бер алма пирогы ашадым. Өйдә Хәдичә ханым бәрәңге куырып ашатты. Никадәр үземнән ашарга тырышсам да, муаффәкъ булып бетми.

Сөембикә манарасын карарга бардым. Моңарчы янына ук барып караганым юк иде. Крепостьның эченә кереп, янына бардым, капкасыннан үтеп йөрдем. Кулларымны тигездем. Бер якка янтайган кебек булып тора. Тирәләрендә йөреп, Сөембикәләр баскан җирләргә басып, аларның да күзе караган Казанка суларын, җырактагы түбәләрне күреп йөрдем. Шулай да милли хискә артык бирелмәдем. Манара да, чын Сөембикәнекелектән чыгып, кирпеч белән чорналып алынган. Ул чактагы хәлләр белән әсәрләнеп түгел, хәзерге күренешләр белән зәвыкланып кырларны, суларны, бистәләрне тамаша итеп җуандым. Далаларны күреп куандым.

Кич Зөһрә ханымларга кердем. Уллары Һашим бүген генә Мәскәү выставкасыннан кайткан. Нәҗип Сәйфи дигән җегет белән таныштым. Бергәләп чәй эчтек. Бик тәмле ботка ашадык. Һашим Мәскәү күренешләрен сөйләде. Бик озак утырдым. Зөһрә ханым үзенең «Мәктәпкә кадәр тәрбия эше» дигән әсәрен биргән иде. Шуны бергәләп тә тикшереп чыктык. Үзе, балалары белән бергәләп, һәммә җырларны, биюләрне, пластинкаларны гамәли күрсәтә барды. Соңынтын Һашим пианино уйнап, Рәисә белән парлап җырладылар. Рәисә уйнап, «Бүз җегет» арияләре белән таныштырды. Бик күңелле, җанлы узды вакыт.

20сендә иртә чәйне Хәдичә ханым коймак белән эчерде. Зөһрә ханымның китабын карап, шигырьләрен төзәтеп, кайсыларын яңадан язып, төшкә кадәр утырдым.

Галимҗан Ибраһимовка бардым. Берәүләр белән чыгып бара икән. «Кайдан килеп чыктың? Миңа килдеңме, әйдә, керик! Юк, алайса син миңа иртәгә кил инде. Иртәгә, булдымы?» – дип, кул бирде. Ярый, дип киттем. Электрик утлары белән ялт иткән Большой Проломныйда байтак йөрдем. Утка чолганып беткән трамвайлар уза, магазиннар, халык... Күңелле шунда да...

25ендә. Эт эчәгесе кебек тик йөри бу минем Пороховойга урнашуым. Һаман өзелми әле. Бүген Главполитпросветка барып, Пороховой белән телефонда да сөйләштереп бетердем. Була, була, диләр.

Кич Зөһрә ханымнарга кергән идем, хуҗалардан берсе дә өйдә юк. Сәидә ханым, Нәҗип Сәйфи, Җөвәирә туташлар белән чәй эчтек. Алма бәлеше белән сыйландым.

26сында Тукай урамы белән барып, Мулланур Вахитов һәйкәле янында, бакчада озак утырдым.

Кич Галимҗан Ибраһимовка бардым. Янында байтак утырдым. Урыннар хакында аңлаштым. Керергә киңәш бирде. Укы да, ди. Арада үзе дә киңәш сорап куя. Кергән кешеләргә мине: «Менә «Галиябану», танышыгыз!» – дип кенә таныштыра. Әллә кемнәр белән таныштырган иде, онытып бетердем инде. Миңа нигә кирәк соң алар.

28ендә. Театр әсәрләре конгрессы гамәлгә куелып ята. Укый башлаганнар.

Башкнига белән килешүнең срогы тулды. Ә пьесамның басылуыннан нәшан *(рәсми җавап)* юк. Бүген китабымны кире сорап, штрафлар даулап, хат яздым. Иң уңмаган урын икән мәгариф тирәсе.

Ну алма да ашала!..

Хәдичә ханымнарда ята бирәм. Алар кумый, мин китмим. Эшләр рәтләнмәгәч, китеп кая барыйм. Кесәдә ике миллиард кына акча калды инде. Мөхәррир Гали Рәхимне эзләп өйләренә бардым. Күрдем, таныштым, сөйләштем. Ул балалар әдәбияты төзүгә саяләнүле булганга, балалар пьесаларымны тәкъдим итеп чыктым. Үзе аерып язарлык бер тәэсир калдырмады.

Урамда Фатих Әмирханны күрдем. Кечкенә арбага утырган да, бер малай артыннан этеп йөртә. Туктап карап калдым.

Көтепханәгә барып «Яшь юксыл»ларны укыдым. Минем «Кәкре каен» уйналган икән.

29ында Наркомпрос бүлегенең заведующие Семеновка алып кереп таныштырды. Ул, телефон белән сөйләшеп, 15еннән (яңача) Пороховой татар эшчеләре клубы янындагы көтепханәгә назир итеп билгеләнәчәгемне белдерде. Эш азрак юлга керде.

30ында кичә алган язу белән Пороховойга – райкомга бардым. Кич, Зөһрә ханымның бала тәрбиясе хакындагы китабын тагы бер тикшерер өчен аулак урын эзләп, аның сеңелләре Суфия туташ Таһироваларга бардык. Суфия туташ, тагы бер сеңлесе, Фаикъ исемле җегет энесе өйдәләр иде. Чәй эчә-эчә китапны төзәттек. Зөһрә ханым зур ук әһәмиятле бер әсәр мәйданга чыгарган.

Кич Зөһрә ханымнарга кердем. Орның Зариф мулла да аларда. Аның белән сөйләшеп утырдым. Аш ашадык, бик тәмле пешкән төйгән ит бәлеше ашадык. Аштан соң залга чыгып утырдык. Сәмигулла абзый бер баласын рояльгә утыртты, ике кызын чакырып җырларга куйды. Берәм-берәм татарча, башкортча, казакъча, чирмешчә, малорусча, русча җырлар җырлап бер кечкенә концерт рәвешен бирделәр. Һашим уйнаган хәлдә кушылып өчәүләп җырладылар. Ике кызының берсен – урыс көенә, берсен татар көенә биетте. Ифрат күңелле булды. Уен-җыр вакытларында рухан зур бәйрәм иттем. Күңелемнән күп нәрсәләр кичте. Зариф мулла да рәхәтләнеп утырды, балаларын тәрбияли белгән атага рәхмәтләр әйтте.

Алма бәлеше белән чәй эчтек. Бик озак утырдык. Һашим белән аерым да утырдым.

Суфия туташ миңа тагы бер урын тәкъдим итте. Моңарчы йоклабрак торган балалар көтепханәсе гамәлгә куелырга булган да, мине шуңа көтепханәчелеккә чакыра. Көтепханәне чыгып карап, ифрат яраттым. Зиннәтле, матур ике зур гына бүлмә, ыштураларына кадәр бар. Кызыгып, күңелем икегә бүленеп китте. Бу кала эчендәге урын язу эшләремә, операларга-театрларга йөрүләремә, кеше белән катышуыма имкян бирә. Ләкин фатир юк, жалуние расходка җитәрлек түгел. Ә Пороховойда жалуние артыграк, фатир буш булулар өстенә, эшчеләр арасында буласым килә иде. Ул минем идеямә дә, күңелемә дә үзрәк иде. Менә шулай итеп, ике уртада сайланыбрак, кайсын сайларга аптырабрак калдым. Балаларны да, эшчеләрне дә яратам.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Фәрит Хөснуллин: «Үткәнебез – горурланырлык, киләчәгебез – өметле»

*(Сарман муниципаль районы башлыгы **Фәрит Мөнәвир улы Хөснуллин** белән **Ләбиб Лерон** әңгәмәсе)*

– Күп кешенең тормыш юлында, шәхес булып формалашуында гаилә зур роль уйный. Сез нинди гаиләдә тәрбияләндегез?

– Әтием Мөнәвир озак еллар Сарман таш карьерын һәм Муса Җәлил исемендәге колхозны җитәкләде. 1982 елдан лаеклы ялга чыкканчы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе булып эшләде, районның авыл хуҗалыгы өлкәсен үстерүгә зур өлеш кертте. Ул – Татарстанның атказанган агрономы. Миңа җитәкче сыйфатлары аннан күчкәндер дип уйлыйм. Кызганыч, әтием вафат инде. Безнең өчен бүген дә намуслылык һәм тугрылык үрнәге ул.

Әниебез Сөмбел, Аллага шөкер, исән-сау. Яше сиксәннән өстә булса да, бик актив, намазын калдырмый, бакчасын чәчкә итеп тота, тәмле ризыклар пешерә. Күз тимәсен! Һәрвакыт илһам бирүчем, ихтыяр көче, сабырлык чыганагым да, уңышка рухландыручым да ул минем. Әниемә сәламәтлек, озын гомер насыйп булсын иде дип телим.

Гаиләдә 3 бала үстек. Әти белән әни безнең өчен һәрчак үрнәк булды. Безгә яшьтән үк туган җирне һәм нигезне ярату, намус белән яшәү, әйткән сүзеңә тугры булу, кешеләргә карата хөрмәт, гаилә кыйммәтләре кебек асыл төшенчәләрне тирән сеңдерделәр.

– Хәзерге икътисади шартларда Сарман ни хәлдә? Соңгы елларда нинди үзгәрешләр булды?

– Районыбыз икътисадында нефть һәм газ чыгару өлкәсе зур урын тота. «Татнефть»нең «Җәлилнефть» идарәсе – районның бюджетын формалаштыручы предприятиеләренең берсе. Нефтьчеләр белән беррәттән, районның җитештерү потенциалын үстерүгә авыл хуҗалыгы өлкәсе лаеклы өлешен кертә. «Агрокөч» холдингына караган «Сарман», «Нөркәй», «Җәлил» агрофирмалары һәм «Чаллы икмәге» инвесторының «Туган як» агрофирмасы авыл хуҗалыгы җирләренең 92 процентын били.

Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү белән 9 мең 227 шәхси хуҗалык, 80 крестьян-фермер хуҗалыгы да шөгыльләнә. Фермерлар дәүләт ярдәме программаларында актив катнаша. Шунысы куанычлы: төрле грантлар алып, тормышларын җанландырып, авылда үз эшен башлап җибәрүчеләр арасында инициативалы яшьләр күп. Яшьләр авылга күбрәк кайтса, туган җирдә төпләнеп калсалар, тагын да яхшырак булыр иде. Үзебез дә авыл хезмәтчәннәренә кызыксындыру чаралары кулланабыз. 2015 елдан башлап муниципаль программа кысаларында биш һәм аннан да күбрәк сыер асраучы шәхси хуҗалыкларга сыер саву аппаратлары тапшырабыз.

Дөрес, быелгы һава шартлары авыл хуҗалыгы өлкәсендәге планнарыбызны һәм өметләребезне тулысынча акламады. Булганына шөкер, дияргә туры килде.

Сарман елдан-ел матурлана. Хәзерге көндә авылда яшәү шартларының шәһәрнекеннән әллә ни аермасы юк. Өстәвенә, авылда чиста һава, матур табигать. Район үзәгендә генә түгел, авыл җирлекләрендә дә зур эшләр башкарыла. Соңгы 5-6 елда 4 күпкатлы торак йорт салынды, 400дән артык шәхси йорт төзелде, 14 фельдшер-акушерлык пункты, 1 врач амбулаториясе, 1 балалар бакчасы, 2 клуб, 11 спорт мәйданчыгы, 1 универсаль спорт залы, участок полиция хезмәткәрләре өчен 2 хезмәт торагы салынды, 4 кибет файдалануга тапшырылды. 3 спорт объекты, 4 авыл советы бинасы, 6 балалар бакчасы, 7 мәктәп, 10 мәдәният учреждениесе, 100ләп күпкатлы торак йорт капиталь төзекләндерелде. Президент программасы нигезендә 21 ишегалды рәтләнде, иҗтимагый киңлекләр булдырылды, урам утлары, сууткәргечләр ремонтланды. Шуларга өстәп, юллар салу, төзекләндерү дәвам итә. Бөтен эшләр район халкының яшәү шартларын җайлы, уңайлы итү өчен башкарыла. Бу уңайдан Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнехановка рәхмәт әйтәсем килә.

– Сарман нәрсә белән данлыклы? Аның үзенчәлеге нидә?

– Сарман районы гербында икмәк, нефть һәм сандугач сурәтләнгән. Бу юкка гына түгел. Сарман ягы таңнарда өздереп сайраган сандугачлары, туган төбәген данлап яшәүче тырыш халкы белән данлыклы. Үзе сандугачка тиң Илһам Шакировы белән, Зөһрәләре, Алинәләре белән шөһрәтле ул. Туган җир куенынннан кара алтын чыгаручы, кырларында икмәк игүче фидакярләре, әдәбият-мәдәнияттә, фән һәм башка өлкәләрдә үз сүзе, үз урыны булган зур шәхесләре белән дә дан казанды Сарман төбәге.

Сарман ягыннан чыккан күренекле шәхесләребез белән чиксез горурланабыз. 2019 елда, татар халкының бөек улы, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты,

Муса Җәлил һәйкәле

Илһам Шакиров бюсты

Сармандагы Бөек Ватан сугышы һәм туган якны өйрәнү музее күренешләре

Сарманым

Миргасим ГАСКӘРОВ сүзләре,
Рафис УРАЗАЕВ көе

Җырлап иген иккән,
Җырлап гомер иткән
Сарман ягы элек-электән.
Туган ягым – җырны,
Җыр Сарманны
Үзенеке иткән, үз иткән.

Җырлап яуга киткән
Синең егетләрең,
Үлгәндә дә җырлап егылган.
Үткәннәрең моңлы синең,
Сарманым,
Киләчәгең матур җыр сыман.

Халкың горур синең,
Туып-үскән җирем,
Яклый, даулый белә ил данын.
Илһамланып тыңла,
Горурланып тыңла,
Җырыбызны тыңла, Ватаным.
Җырыбызны тыңла, Сарманым.

Сарман күренешләре

мәшһүр якташыбыз Илһам ага Шакировның якты истәлеген мәңгеләштереп, район үзәгендә һәйкәл ачтык. Сарман сәнгать мәктәбе аның исемен йөртә. Ел саен якташыбыз, эшмәкәр Илдар Өнип улы Гамировның ярдәме белән Сарманда «Илһам чишмәсе» җыр бәйгесе уздырып киләбез. Бәйге бик күп талантлы балаларны җыя, яшьләрне барлауга, аларның сәләтләрен ачып, үстерүгә ярдәм итә. Илһам аганың репертуарыннан алынган җыр башкару – конкурсның төп шарты булуы да зур әһәмияткә ия.

ТАССРның 100 еллыгын билгеләп үткән 2020 елда, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреатлары булган якташларыбызның исемен мәңгеләштерү максатыннан, Сарманда стела ачтык. Илһам ага Шакиров, тагын бер олпат шәхесебез булган – Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев, талантлы журналист, публицист Марсель Зарипов, композитор һәм җырчы Роберт Андреев, язучы, романнар авторы Мәдинә Маликова, шагыйрә һәм драматург Гөлшат Зәйнәшева, шагыйрә Клара Булатова портретлары шушы стелада урын алды. Күренекле якташларыбыз район белән элемтәне өзми. Үзебез дә аларны бәйрәмнәргә, төрле очрашуларга чакырып торабыз.

– Шәхесләрнең тормыш юлларын, иҗатларын өйрәнү юнәлешендә нинди эшләр башкарасыз?

– Быел Клара Булатованың – 85 яшьлек, Әзһәр ага Габидинең 95 еллык юбилейларын матур кичәләр белән билгеләп үттек. Район җирлегендә ел саен үтүче «Шушы яктан, шушы туфрактан без» дип аталган республикакүләм фәнни-гамәли конференция шулай ук алар иҗатына багышланды. Узган ел бу конференциядә катнашучылар Мәдинә Маликова иҗатын өйрәнде. Районыбызның тагын бер уникаль шәхесе – Дамир Гарифуллинның күпкырлы эшчәнлеге, язучы Аяз Гыйләҗев, язучы һәм журналист Хәниф Хәйруллин, шагыйрь һәм прозаик, филология фәннәре докторы Фәрит Яхинның иҗатлары да конференциядә катнашучыларга фәнни өйрәнү өчен тәкъдим ителде.

Гарәп дөньясында атаклы, ләкин исеме озак вакытка татар тарихыннан сызып ташланылган күренекле мәгърифәтче һәм ислам галиме, тарихчы Морад Рәмзинең исемен илгә кайтару, аның бай иҗади һәм фәнни мирасын өйрәнү буенча республикада соңгы елларда зур эш алып барыла. Без мондый бөек шәхеснең районыбызның Әлмәт авылыннан булуы белән горурланабыз. Әлмәт авылы мәчете аның исемен йөртә. Авыл мәктәбенә дә күптән түгел Морад Рәмзи исеме бирелде. Дөньяның төрле якларына таралган нәсел-нәсәбе белән дә элемтәбез бар. Алар зыялы ата-бабаларының туган җирендә еш кунак була.

Быел май аенда, Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы чаралары кысаларында, мәктәп укучылары арасында «Мин татарча укыйм» дип исемләнгән зур әдәби фестиваль үткәрелде. Төрле мәктәпләрдән җыелган командаларның ярышын, жюри әгъзалары буларак, күренекле якташларыбыз бәяләде.

Районда якташлар очрашулары үткәрү матур традициягә әверелде. Сарманның үзендә башланып китеп, төрле елларда Дүсем, Буралы Чишмә авылыннан чыккан якташлар бергә җыелды. Быел Балтамак авылында да шундый очрашу зурлап үткәрелде. Халык бик сагынган, сусаган мондый күрешүләргә. Киләсе җәйләрдә районның башка авылларында да очрашулар оештырырга ниятләр бар.

– Бай мәгълүматлы әңгәмә өчен рәхмәт Сезгә, Фәрит Мөнәвирович! Күркәм башлангычларыгызда, игелекле гамәлләрегездә уңышлар насыйп булсын дигән теләктә калабыз. ■

Безнен мирас №10 октябрь 2021

Җәфалый торган җанисәп

Фоат Уразай

Бөтенрусия халык санын алуда 2020 елның октябренә билгеләнгән чираттагысы шактый ук мәшәкатьле булып чыкты. Хикмәт монда аның, коронавирус пандемиясен сылтау итеп, ике мәртәбә (башта – 2021 елның апреленә, ә быел инде – октябрь аена ук та) күчерелүендә генә дә түгел. Асылы белән гадәти чара булса да, четерекле яклары бу юлы шактый. Чираттагы җанисәпнең төп үзенчәлеге – аның электрон форматта үткәрелүе. Шул максатларда ул цифрлаштырылган, ә интернет-җанисәп технологияләре 2018 елда ук сынау узган һәм кулланучыларның 95 процентында яклау да тапкан. Халык санын алудагы бүгенге үзгәрешләр, әлбәттә инде, аны гадиләштерү һәм ышанычлылыгын арттыру теләге белән аңлатыла. Әмма алар артында теләк-ниятләрнең башкалары да булырга мөмкин. Искәртеп үтик, алга таба җанисәп өчен мәгълүмат җыю ысулы нык үзгәрәчәк: үзең һәм гаилә әгъзаларың өчен бланкларны хәзер дәүләт хезмәтенең онлайн порталында тутыру мөмкин булачак. Теләгән кешеләргә әлеге процедураны гадәти ысул белән, санаучылар өйдән-өйгә йөргәндә яисә стационар пунктларда да башкарырга мөмкин. Шул ук вакытта хәтта бланклары электрон ысул белән тутырылган гражданнар да санаучы белән очрашырга һәм үзен теркәтергә тиеш булачак. Моның өчен, санаучы килгәч, аңа планшет яки смартфон экраныннан QR-кодны күрсәтү яисә цифрлы кодны әйтү

дә җитә. Санаучылар исә программасы илдә төзелгән планшетлар белән тәэмин ителәчәк. Ә кәгазь бланклар хәзер резерв варианты буларак кына кулланылачак икән. Әлбәттә, болар һәммәсе дә – вак мәшәкатьләр һәм, нигездә, оештыру өлкәсенә карый. Шуның белән бергә, чираттагы халык санын алу һәм аның нәтиҗәләре шактый гына четерекле мәсьәләләргә дә кагыла.

Гомумән алганда, җанисәп ул – билгеле бер вакытка илдә яшәгән халыкның саны һәм составы турында мәгълүмат туплау, гомумиләштерү, анализ ясау, бәяләү һәм, шулар нигезендә, демографик, икътисади һәм социаль күрсәткечләрне бастырып чыгару буенча фәнни яктан оештырылып үткәрелә торган операция. Ә халык санын алу тарихы Русиядә тамырлары белән тирәнгә китә. Аңа нигез Җүчи Олысы чорында ясак җыюны тәртипкә китерү ниятендә салына. Җанисәп тарихы төрле чорларны үз эченә ала һәм максатлары белән дә аерыла, нигездә, салым җыюны тәртипкә салу ниятендә үткәрелә. XVII гасырда, әйтик, салым җыю берәмлеге булып хуҗалык (двор) саналган һәм сан алулар да хуҗалыклар буенча үткәрелгән. Ә 1718 елдан Петр I указы нигезендә инде ул өчешәр елга сузылган җанисәп рәвешендә үткәрелә башлый һәм «ревизия податного населения» дип атала. «Крепостное право» бетерелгәнчегә кадәр шундый 10 «ревизия» үткәрелә (соңгысы – 1857-1860 нчы елларда). Русия империясендә исә беренче һәм бердәнбер илкүләм җанисәп 1897 елда, танылган галим Петр Семенов-Тян-Шанский инициативасы буенча уздырыла. Ул XIX гасыр ахырында Русиядә халыкның саны һәм составы буенча бердәнбер ышанычлы чыганак булып санала. Ихтимал, мондый төгәллек бәгъзеләргә XX гасыр башында Урталык җирләрендә булачак геосәяси үзгәрешләрне реаль һәм максатчанрак планлаштыру өчен дә таләп ителгәндер. Нәтиҗәдә, Русиядә 124 миллион 640 мең кеше яшәве ачыклана. Беренче бөтендөнья һәм Ватандашлар (Гражданнар) сугышы чорларында, кайбер саннарга караганда, аның 11 миллионга якыны һәлак була («туп азыгы»на әйләнә).

Совет чорында исә халык санын алулар әүвәл өлешчә 1920 һәм 1923 нче елларда үткәрелә. Ә ил күләмендә һәм фәнни нигездә тәүге җанисәп 1926 елда уза. Ул чакта анда 147 миллион кеше яшәве ачыклана. Шуннан соң халык санын алуның чираттагысы инде 1937 елның гыйнварында, мәгълүм вакыйгалар башлангач үткәрелә. Аның нәтиҗәләре элеккеләреннән шактый аерыла. Шуңа күрә аны үткәрүчеләр «халык дошманы» дип игълан ителә һәм репрессиягә эләгә. Ә чираттагы җанисәп инде, контроль бланклар кулланып, 1939 елның гыйнварында (Бөек Ватан сугышы алдыннан) үткәрелә. Ул чакта илдә халыкның гомуми саны 190,7 миллион кеше булган. Гомумән алганда, аңлашыла ки, дөнья тотучылар ил халкын ул чакта да үз максатларында (дөньяны яңача үзгәртеп коруда «сәясәт коралы» һәм «туп азыгы» итеп) кулланган. Хәтта рәсми мәгълүматлар буенча да бу чорда аның 27 миллионнан артыгы һәлак булган. Сугыштан соң инде халык санын алу 1959 елның гыйнварында гына үткәрелә. Ул чакта СССРда яшәүчеләрнең гомуми саны 208,8 миллион булуы турында әйтелә. Илдә халык санын алуның нәүбәттәгеләре инде 1970 һәм 1979 нчы елларга туры килә. Соңгы җанисәп исә чираттагы геосәяси тетрәнүләр алдыннан, 1989 елның гыйнварында үткәрелде. Аның нәтиҗәләре буенча, илдә 286,7 миллион кеше (шулардан шәһәрдә – 66%, авылда – 34%) яшәве мәгълүм булды.

СССР җимерелгәч, Русиядә халык санын алуның тәүгесе 2002 елның октябрендә генә оештырылды. Аның нәтиҗәләре Русиядә 145,2 миллион кеше (шулардан шәһәрдә – 73%, авыл җирлегендә – 27%) яшәвен күрсәтте. Әмма бу җанисәпнең хәрәмләшүләргә корылганлыгы да ачыкланды, соңгы нәтиҗәләре 2005 елда гына

игълан ителде. Аннан күренгәнчә, Башкортстанда, әйтик, башкортлар саны 22дән 30%ка кадәр күтәрелгән (1989 елда 864 мең булса, 2002 елда инде – 1,121 миллион кеше), ә татарлар анда, киресенчә, 28дән 24% кына булып калган (1,121 миллион кешедән 2002 елда 990 меңе генә калган). Күрәләтә кылынган мондый хәрәмләшүләрне экспертлар да таныды, алар 2002 елгы җанисәп вакытында Башкортстанда 200 меңнән артык татарны «башкорт» итеп язулары турында белдерде. Ә мондый гамәлләр инде РФ Конституциясенең 26 нчы маддәсен турыдан-туры бозу булып тора. Соңгы җанисәп исә Русиядә 2010 елның октябрендә үткәрелде. Аның нәтиҗәләреннән илдә 142,86 миллион кеше яшәгәнлеге ачыкланды. Әгәр бу санны 2002 елда үткән җанисәп белән чагыштырсак, 8 ел эчендә илдә халык санының 3 миллион кешегә диярлек кимегәнлеге күренә. Бу чорда инде анда татарлар гына түгел (2002 елдагы 5,55 миллион кешедән 2010 елда инде 5,31 миллионы гына калган), башка халыклар (шул исәптән башкортлар) да кимегән булып чыга.

Кызганыч ки, титул милләтне татарлар хисабына арттыру теләге Башкортстанда бүген дә яши. Этник яктан кимсенүле бериш башкорт милләтчеләре (хәер, аларны «милләтче» дип санап та булмыйдыр, чөнки бу төшенчә үз милләтеңне, димәк, тугандаш халыкларны да ихластан яратуны, аларның ышанычлы киләчәге өчен үз-үзеңне аямыйча көрәшүне аңлата. Шуңа күрә боларын, шартлыча, «башкорт бичаралары» дисәк, дөресрәк булыр. Шартлыча, чөнки араларында татар чыгышлылары һәм хәтта фәнни дәрәҗәләргә ия булганнары да бар. Сәяси заказ үтәпме, башка сәбәп беләнме, татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә (шул исәптән хәтта Татарстан районнарында да), анда яшәгән байтак кына татарларның бабалары патша заманында махсус кертелгән «башкорт» сословиесендә торырга мәҗбүр булуын исәпкә алып, аларның нәсел-ыруын «башкорт»ка чыгара һәм алдагы җанисәп вакытында «башкорт» булып язылырга кодалый; татар районнары чигенә ясалма «башкорт ырулары» яшәвен күрсәткән баганалар урнаштыра. Шул рәвешле, алар башкортның санын «арттырмакчы», ә үзләрен рухи бичаралыктан арындырмакчы була.

Тик, хактыр ки, мондый юлның киләчәге юк. Чөнки ул хакыйкатькә каршы килә. Җөмләдән, шәхсән үземнең борын заманнарда бүгенге Сарман районы биләмәсендә яшәгән бабаларым җир хуҗалары булган һәм патша чорында «башкорт» сословиесендә торган. Әмма аларның нәсел-нәсәбе борынгы татар кабиләләренә карый һәм бу күп кенә тарихи чыганак һәм архив документлары белән генә түгел, нәсел тамгалары белән дә раслана. Әлбәттә, татарлар һәм башкортлар – ике тугандаш халык һәм ул кардәшлек аларның күп гасырлык уртак язмышлары, тел, җыр, моң, дин, рух һәм гореф-гадәтләр уртаклыгы белән дә билгеләнә. Алар бер асыл кошның ике канатын хәтерләтә, ә ул фидаи кош ике канаты да сау-сәламәт булганда гына оча алачак.

Хәлбуки, татар-башкорт мөнәсәбәтләренең уйланырга мәҗбүр итә торган битләре дә җитәрлек. Тик, ни кызганыч, тарих безләрне бернәрсәгә дә өйрәтми. Үзара аңлаша алмау, чамадан тыш (хәтта ахмаклык дәрәҗәсендәге!) мин-минлек, караш тарлыгы, геосәяси дәрәҗәдә фикер йөртә алмау, илаһи яшәешнең асылын һәм киләчәкне аңламау, сабыйларга хас көнчелек, бер-береңә юл куя белмәү – болар һәммәсе дә, аякка эленгән авыр гер булып, гасырлар дәвамында безне аска тарта. XX гасыр башы безләр өчен уникаль мөмкинлекләр ачкан иде. Йә, кем отты? Татармы? Башкортмы? Җавап гади: югарырак категорияләрдә фикер йөртә белүчеләр отты. Ни гаҗәп, XX гасыр ахыры яңа мөмкинлекләр белән елмайды. Ә бу юлы кайсыбыз отты? Ой! Әллә бу юлы да отучылар юкмы? Бар, әлбәттә! Ләкин без түгел. Нәрсә, алга таба да шулай дәвам итәбезме? Юкса өлешчә инде килеп

тә җиттек кебек: хокуксыз, милли мәгарифсез, милексез калдык, инде җирсез һәм телсез дә калып барабыз шикелле. Мәгәр, кәгазьдәге дәүләтчелегебезне югалтырга да күп калмады кебек, эшләр алга таба да шулай дәвам итсә, тиздән аны эзе дә калмаслык итеп чистартырга мөмкиннәр. Әмма бичараларны бу гына туктата алмый. Алар һаман татарны башкорт итеп яздырып бәхетле булмакчы. Йа, Хода! Күрәсең, бу инде – тумыштан алынган ниндидер авыр рухи травма нәтиҗәседер.

Ә каршылыкларны куерту дәвам итә: әлеге «эшем ияләре» татарның күренекле шәхесләреннән «башкорт» ясый, аның тарихи ядкярләренә кул суза һәм рухи мирасын да үзләштерергә омтыла. Чик-чаманы белми торган беришләре инде соңгы вакытларда татар телен башкорт теленең төньяк-көнбатыш диалекты дип игълан итүгә кадәр дә барып җитте. Әлбәттә, халык исеменнән болай эш итү тугандаш башкорт халкын тулаем да кыен хәлгә куя, аның мәгърур исеменә тап төшерә. Әйе, татар һәм башкорт бүген, Җир белән Ай кебек, бер-береннән башка яши алмый. Ә яшәеш, мәгълүм булганча, бөтен җиһанда илаһият кануннары буенча корылган. Шулай булгач, Җир Ай тирәсендә әйләнмәгән кебек, татар теле дә башкорт теленең диалекты була алмый.

Хәлбуки, Мәскәүнең җанисәпкә үз исәпләре дә бар кебек. Миңа калса, аның өчен ул инде күптәннән, демографик, социаль яки икътисади мәсьәләләрне җайга салу чарасы гына булудан туктап (чөнки паспортлар һәм башка документлар гына түгел, бөтен яшәеш һәм хәтта адәми зат үзе дә цифрлаштырылган бу дөньяда мәгълүмат туплау, зур проблема түгел), үзенчәлекле сәясәт механизмына да әверелеп бара. Ә дөнья тотучыларны Урталык җирләрен «Зур Аурупа» проектына әзерләү һәм мәҗбүри глобальләштерү проблемалары күбрәк тә борчый. Шуңа күрә алар буенча мәгълүмат туплауда яисә бу җирлектә бара торган процессларны кайтма мәгълүмат белән тәэмин итүдә җанисәп механизмы бик тә файдалы булырга мөмкин. Әйтик, 2012 елдан бирле гамәлгә ашырыла торган Милли сәясәт стратегиясенә халыкның реакциясе нинди? Җанисәпкә чыгарылган сораулыкларга ватандашларның туган телләрен белү-белмәүләре турында гына түгел, аны көнкүрештә куллану-кулланмавы турындагы сорауларның да кертелүе, күрәсең, милли күптөрлелекне бетерү сәясәтенең барышын бәяләү, ул сүлпән барган очракта, өстәмә чаралар күрү өчен дә кирәк.

Инде алда торган халык санын алуга кагылышлы рәсми фикерләргә игътибар итик. Русия Президенты В.Путин, әйтик, җанисәп вакытында ватандашлар үзенең милләтен билгеләгәндә, аларның моны ирекле башкару хокукы һичшиксез үтәлергә, ә аңа басым ясау омтылышлары кискен төстә туктатылырга тиешлеге турында әйтте. Ватандашларның этник үзбилгеләнүе һәм милли состав динамикасы халык санын алганда өйрәнеләчәк мөһим мәсьәләләр булачагы турында Казанда да искәрттеләр. Ә үзтәңгәллек мәсьәләсе, чыннан да – һәркемнең шәхси эше һәм аңа беркем дә тыкшынырга җыенмый кебек. Шуның белән бергә, соңгы җанисәп вакытында, татар милләтен вак субэтносларга бүлеп, аның гомуми санын киметеп күрсәтү омтылышлары да булмады түгел. Мәгълүм этнолог, РАНның Этнология институты фәнни җитәкчесе В.Тишков бу мәсьәләдә аеруча үҗәтлек күрсәтә. Җанисәптә ике катлы этник тәңгәллек кертү, милләтләр исемлеген киңәйтү кебек тәкъдимнәре бу юлы да булды. Сорау туа: татар милләтен төрле юллар белән киметеп күрсәтү кемгә һәм ни өчен кирәк соң?

Бу проблема, күрәсең, татарларның Русиядә сан ягыннан икенче урындагы милләт булуы һәм ил тарихында аерым роль уйнавы белән дә аңлатыладыр. Татар теле Урталык җирләрендә кайчандыр күп гасырлар дәвамында милләтара аралашу

теле булып хезмәт иткән. Ә халыкара хокук нормалары буенча бүген дә халкының саны илдә 5 проценттан арткан милләтләр үз теленә «дәүләт теле» статусы дәгъвалый ала. Биредә мисалга Финляндияне китерергә була: фин теле белән тигез дәрәҗәдә «дәүләт теле» статусына анда швед теле дә ия. Ә Финляндиядә яшәүче шведларның гомуми саны илдәге халыкның нибары 5,6 процентын (290 мең кеше) тәшкил итә. Русиядә исә татарларның реаль саны күпме булуын Алла Үзе генә белә. Милләтнең шактый өлешендә (катнаш никахта, чит мохиттә тәрбияләнгәннәрдә һ.б.) милли аң дәрәҗәсе түбән булу сәбәпле (ә бу – аңа карата күп гасырлар дәвамында үткәрелгән шовинистик сәясәт нәтиҗәсе), алар үзләрен башка этнос белән тәңгәлләштерә. Мәгълүм булганча, монда әле бериш «этнолог»лар да ярдәм итә. Миңа калса, бәгъзеләрнең Русиядә татарның гомуми санын гел киметеп күрсәтү теләге шуның белән дә аңлатыла. Кызганыч ки, теле төрки-татар нигезле башка халыкларның да статус юнәлешендәге омтылышына әлегә бик исәп тотып булмый. Бу урында инде мин янә башкорт «милләтче»ләрен искә төшерәм: «башкорт теленең төньяк-көнбатыш диалекты»на Русиядә икенче «дәүләт теле» статусы даулау юлында, бәлки, алар инициатива күрсәтер? Тик ай-һай! Моңа аларның бичаралыклары комачаулар кебек.

Чираттагы җанисәп инде кат-кат күчерелсә дә, аны үткәрү вакыты барыбер якынлаша. Әйткәнебезчә, анда тәгаенләнгән процедураларны бу юлы электрон вариантта, дәүләт хезмәтенең онлайн порталында да үтеп була. Шуңа күрә, илдә үзебезнең күпме икәнлегебезне белү өчен генә булса да, мондый мөмкинлектән файдаланып каласы иде. Ә киләчәккә ышаныч белән яшәгән милләт өчен бу инде бигрәк тә мөһим.

Язмабызны йомгаклап, игътибарны җанисәпкә бәйле тагын бер җитди мәсьәләгә юнәлтәсе килә: әлегә илдә үз саныбызның күпме икәнлеген дә төгәл белмәгән халык буларак, без дөнья буйлап сибелгән татарның да гомуми санын белә алмыйбыз һәм ниндидер түрәнең чама белән, фәлән миллионнан артык дип әйткәненә биһуш булып яши бирәбез. Юкса читтә яшәгән татарларга рухи ярдәм күрсәтү бурычы бит Татарстанның Төп Законында беркетелгән. Ә моның өчен кайсы илдә һәм күпме татар яшәгәнлеген дә белү кирәк. Бу юнәлештә инде эшкә, мөгаен, Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан бүлеге дә алынырга тиештер: татарлар күпләп яшәгән илләрдәге рәсми мәгълүматлар буенча бу җәһәттән мәгълүмат туплау һәм гомуми картинаны күзаллау бүген әллә ни зур проблема булмас кебек. Ә төрле төбәкләрдә тупланып гомер иткән татарлар үзләре турында һаман белдереп тора. Монда мисалга Әфганстанда яшәгән миллионнан артык татарны, Төркиядә һ.б. илләрдә яшәгән Кырым татарларын, башкаларны китерергә була. Пакыстан якларында «кара татарлар» дип йөртелгән халык яшәве дә мәгълүм…

Дөньяда татарларның гомуми санын белүнең тагын бер мөһим ягы бар: без – дөнья тарихында тирән эз калдырган халык. Милләтебезгә мөһим миссияләрне дә шактый гына башкарырга туры килгән: борын заманнарда тәңречелекне җәелдерү, ислам динен кабул иткәч, тирә-як халыкларга ислам тәгълиматын аңлату, Урта Азиядә гыйлем тарату һ.б. Бүген инде милләт алдында аңа Күкләр тарафыннан тәкъдир ителгән төп миссияне үтәү бурычы да тора: илаһи исламны җәелдерүдә һәм илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүдә әйдәп баручы көч булу. Моның өчен аңа метасәясәт (илаһият кануннары буенча яшәүгә күчү сәясәте) югарылыгында да эш итәргә туры киләчәк. Шул максатларда Хак Тәгалә аны, гаять катлаулы сынаулар аша үткәреп, меңьеллыклар дәвамында әзерләгән һәм бөтен дөнья буйлап таратып урнаштырган. Димәк, бүген татар өчен төп проблема – аның инде бу җәһәттән дә үзтәңгәлләшүе. ■

Безнең мирас №10 октябрь 2021

Атлар, этләр һәм кешеләр

Рифат Җамал

Адәм баласы гомере буе өйрәнә, ләкин тормыш юлында аунап яткан «тырма»ларның берсенә генә дә басмыйча финишка барып җиткән кеше, мөгаен, юктыр.

Үз гомер юлымда да тормыш миңа бер генә дәрес бирмәгәндер, ләкин әллә ул укытучы кебек тукып тормагангамы, әллә минем яшь, егәрле чак булгангамы, безнең өчен һәммә ишекләр ачык, дип йөргәнгәме, бу дәресләрнең күбесе хәтеремә сеңеп калмаган. Еллар узып, шактый гына «тырма»ларга басып, маңгайга ук булмаса да, җанга шактый гына җәрәхәтләр алганнан соң гына, бу дәресләр искә төшә башлый.

Институтны бетергәч, мине Югары Ослан районына эшкә җибәрделәр. Җибәрделәр дию бик үк дөрес булмас, чөнки мин бу районны үзем сайлап алдым. XX гасырның җитмешенче елларында, ягъни хәзер инде сүгүдән тетмәсе тетелеп беткән Совет вакытында яшь белгечләрне эшкә билгеләгәндә «блат» дигән нәрсә, минем белүемчә, юк иде. Иң яхшы укучылар алданрак кереп үзләренә ошаган урыннарны сайлыйлар, башкаларга, укуына карап, бүтәннәрдән калганы.

Институт бик абруйлы булганга, аны бетергән белгечләргә ихтыяҗ бөтен Союз буенча иде. Минем белән укыган кайбер егетләр, Чукоткага болан асраучы

хуҗалыкларга барып, акча эшләп кайтырга булдылар. Мин дә яшь чакта дөнья күреп калырга кирәк дигән фикергә килеп, авылга кайтып, әти-әни белән киңәшергә булдым. Ләкин Бөек Ватан сугышында катнашкан, үз фикерен кистереп әйтә торган әни (бу холык миңа аннан йоккан, күрәсең): «Татарлар Татарстанда яши!» – дип, әлеге сорауга нокта куйды.

Татарстанда кая барырга? Үзебезнең Арча районында мал табибларына бөтенләй кытлык юк. Каян килсен ул?! Үзе Казанның Арча башына урнашкан институтта арчалылар көтүләре белән укыйлар. Күрше Хәсәншәех авылыннан гына да 15-20 кеше белем ала. Хәтта минем белән бергә укыган, Арча райисполкомының рәисе, атаклы Борһанов малае Хафиз да эшкә Орел өлкәсенә китте.

Алайга киткәч, Казан тирәсендәге берәр районга урнашырга. Сәбәбе бер: Казанда икенче курстан бирле йөргән кыз яши. Кем әйтмешли, дүрт ел буе бер кыз белән йөрү уен-муен эш түгел. Исәпләр зурдан. Бабай булырга тиеш кеше шактый кырыс булса да, кызның әнисе, минем зур кеше буласыма ианып (югары уку йортында укыйм бит!), миңа, кияү, дип кенә тора. Башта кызаргаласам да, аннары күнегелде. Билгеле, һәрбер ананың иң изге теләге – кыз баланы мөмкин кадәр яхшырак урнаштыру.

Биектауда урын юк. Лаешның үзеннән укыган егетләр бар, шуңа кеше өлешенә керү килешми. Эзли торгач, Югары Ослан районының «Свияга» совхозына баш ветеринария табибы кирәклеге ачыкланды. Ләкин Югары Ослан үзе Казаннан күренеп торса да, совхоз үзәге булган Татар Борнашы авылына Осланнан басу юллары буйлап шактый барасы икән. Автобус йөрми. Казанга көн саен түгел, хәтта атнага бер кайту мөмкинлеге дә чамалы. Хәзер генә ул Татар Борнашы Мәскәү-Казан юлы өстендә кала. Ә узган гасырның җитмешенче елларында Идел аркылы яңа күпер төзиячәкләр икән дигән имеш-мимешләр йөри генә башлаган иде әле. Күңел төшеп торганда шунысы билгеле булды: Казаннан «Свияга» совхозының бер бүлекчәсе булган Гаврилковога көнгә ике тапкыр «Омик» теплоходы йөри икән. Монысы куандырды.

Хәзер ул тирәләрдә шактый кызу төзелеш бара. Таудан шуу комплексы үзе генә дә ни тора! Гаврилковода күп коттеджлар корылган. Ә җитмешенче еллар уртасында бу җирләр дөньяның тын гына бер җәннәт почмагы иде. Һәрхәлдә, миңа, шактый коры Арча районыннан килгән малайга, бу шулай тоелды. Бигрәк тә үземнең туган авылым Мирҗәмнең тирә-юнендә хәтта чалгы тотып печән чабарлык урыннар да юк иде. Үсмер елларның һәр җәе малларга печән хәзерләр өчен «уфалла арбасы» тартып, бәрәңге, кукуруз басуларыннан берәмтекләп чүп үләне җыеп, аны киптереп үтте.

Ә монда! Өч якта өч елга: Идел, Зөя, Сулица. Биредә безнең кебек ташбаш тотмыйлар, хәтта аның бар икәнен дә белмиләр. Мондагы балыкларны мин белмим, чөнки күргәнем юк, чуртан белән җәенне генә чамалыйм. Ләкин биредәге балык шулпасының тәмен, билгеле инде, безнең институт ашханәсендәге балык ашы белән һич тә чагыштырып булмый иде. Әле хәзергә кадәр хәтердә: кунак киләсе булса, егетләр, сезонга игътибар итеп тормыйча, мылтык алып Идел буена төшеп менәргә дә чирканмыйлар иде.

Бу якларда арба тартып, чүп үләне җыеп йөрүне белмиләр. Болында печән билдән биек. Чалгыны бер селтәсәң, ярты капчыклык печән була. Ләкин монда капчыклап, җилкәгә күтәреп печән ташымыйлар. Машина, трактор, атлысы – арба белән. Мине иң гаҗәпләндергәне шул булды: биредәге иске печәнне кыш көне олавы белән Идел бозы өстенә ташлыйлар икән. Минем, берәмтекләп үлән җыйган малайның, ничекугаланганын күрсәгез… Шундый байлыкны чыгарып ташла әле!

***Редакциядән:** Танылган шагыйрь, күренекле фән эшлеклесе һәм мөгаллим **Рифат Җамалетдин улы Корбанов**ка (Рифат Җамалга) 1 октябрьдә 70 яшь тулды. Аны гомер бәйрәме белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары теләп калабыз!*

Җиләк-җимеш дигәндә, Ослан ул – Татарстанның Кавказы. Совхоз җирлегендә мин белгәне генә дә өч бакча бар иде. Берсе күптән түгел генә утыртылган. Ләкин бөтенесе дә хуҗасыз. Кайвакытта юл уңаенда кереп, туйганчы җиләк-җимеш ашап чыгарга була иде.

Бу яклардагы табигатьнең матурлыгын һәм байлыгын тасвирлау өчен тагын бик озак сөйләргә туры килер иде. Ләкин хикәямнең бурычы үзгә булганга, бу турыда сүземне кыскарак тотам. Шулай да әйтмичә булмый. Казанны алгач, татарларны юкка гына зур елга буйларыннан кумаганнар икән. Башка сәбәпләрне исәпкә алмаганда да, әйтергә кирәк, зур елга буенда яшәү җиңелрәк. Елга туендыра да. Балыгын, кош-кортын әйтеп тә торасы юк. Зур елганың болыннары үзе ни тора! Болын булса, печән була, ә печән булганда, терлек асрау күпкә җиңелрәк.

Совхозның баш белгече буларак, миңа торыр өчен урын да, йөрер өчен «служебный» транспорт та бирделәр. Әле берне генә түгел, берничәне. Башта яшьләрчә, әрсезләнеп, әрҗәсез «Иж» мотокциклы белән йөреп алдым. Ләкин ул тиз туйдырды. Чөнки һава торышы коры торганда басу юлларын тузан баскан була. Берәр авылга барып кайтсаң, өстең-башың, йөзең, чәчең тузанга бата. Ә яңгырдан соң мотоцикл белән йөрсәң, бөтенләй карарлыгың калмый. Ә минем мунча түгел, душ та юк. Шулай итеп, матайдан гайрәт чикте.

Бераз вакыттан минем карамакта әле тагын әрҗәле мотороллер да булырга тиешлеге ачыкланды. Аны миңа кадәр совхозның баш мал табибы булып эшләгән Җевсиев дигән абзый «кысып калган» икән. «Кысып калган» икән дип әйтү дә бик дөрес булмас. Җевсиев абзыйны, бик еш салып эшкә чыга алмау сәбәпле, урыныннан алган булганнар. Мин килгәндә дә әле ул шул халәтендә булып, минем белән очра-

ша алмады. Ләкин миңа «изгелек теләүчеләр» бик тиз мотороллерның Җевсиев ишек алдында торуын җиткерделәр. Мин, матди яктан җаваплы кеше буларак, Җевсиевны чакырып, мотороллерны китереп куярга куштым. Ләкин Җевсиев абзый, илле яшьләргә инде хәйран гына тормыш тәҗрибәсе туплаган кеше буларак, мотороллер ватык, кабынмый, кирәк булса, үзегез килеп алыгыз, диебрәк җавап бирде. Мин, яшьлек белән аның сүзенә ышанып, мотороллер төзәтергә кеше эзли башладым. Ул арада «изгелек теләүчеләр» Җевсиевның мотороллер белән җилдереп печән ташыганын әйтеп җиткерделәр. Билгеле инде, Җевсиевның мине кәкре каенга терәтүе миңа бер дә ошамады. Мин янәдән Җевсиевны чакыртып, бик кырыс төс белән, мотороллерны «немедленно» китереп куярга куштым. Җевсиев та ут белән уйнаганын аңлады кебек. Чөнки мин үзем совхоз директорына, кешене эшсез калдырмыйк, Татар Борнашы фермасына мал табибы итеп урнаштырыйк, дигән тәкъдим белән кергән идем. Имеш, тагын бер мал табибы артык булмас. Җевсиев мыштым гына, ярар, дип чыгып китте.

Икенче көнне эшкә килсәм, халык гөжли. Зур фаҗига. Җевсиев белән Савино фермасы ветсанитары Шурик, мотороллер белән капланып, хастаханәгә эләккән. Шурик дигәннәре шулай ук илле яшьләрдәге мәхлук кына бер адәм. Карусыз, тырыш, ябага аттай ябык, өч-дүрт көн кырынмаган (кем уйлаган ул вакытта өч-дүрт көн кырынмау модага кереп, хәтта дәүләт җитәкчеләре дә шулай йөрер дип), һавадан йолдыз тотмаса да, эшен җиренә җиткереп эшли. Хатын белән нәчәлствога каршы сүз әйтү аның өчен күз алдына китерә торган әйбер түгел. Беренче күргәндә мин аңа әтисенең исемен дә кушып дәшкәч, Александр аптырады, каушады, кызарды, аннары, кулларын болгый-болгый, үзенең Шурик икәнен аңлата башлады. Шулай да мин аны Саша дип йөрдем. Саша эшләгәндә мин Савино фермасы өчен тыныч идем.

Сөйләүләренә караганда, Җевсиев, миннән чыккач, әллә йөрәк ярсуына түзә алмыйча, әллә инде бер саубуллашып әйләним дип, үзе өчен бик якын һәм кирәкле булган мотороллерга утырып, Савинога китә. Билгеле инде, элеккеге баш табиб буларак, ул йөрәк ярсуын баса торган «дару»ның Шурикта булырга тиешлеген бик яхшы белә. Шурикны эш урынында тотып, моң-зарларын җиткерә, теге «яшь әтәч»нең мотороллерны тартып алырга маташуын күз яшьләре белән сөйли. Бу инде аның юл уңаенда берәрсенә кереп чыгуын тәгаенли. Билгеле инде, Шурик хәлгә керә. Бергәләп, дөньядан зарланышып, каптан гына глюкоза капкалап, булган запасны төгәллиләр. Җитми. «Ни өчен медикларның кызыл хач билгесе кызыл төстә, ә ветеринарларныкы зәңгәр?» – дигән сорауга: «Адәм табиблары кызарганчы, мал табиблары зәңгәрләнгәнче эчә», – дигән гыйбарә бу очракка туры килә, күрәсең. Җитмәгән дозаны эзләп, мотороллерга утырып китәләр болар. Әллә Савинода берәү дә хәлгә керми, әллә күңел киңлегеннән, Борнашка барырга булалар. Билгеле инде, турыдан. Исереккә диңгез тубыктан, диләр бит. Ә боларга шактый текә тау да, күрәсең, сөзәк булып күренгән. Ләкин тау төшкәндә гөнаһ шомлыгына каршы көпчәк астына таш эләгә (бәлки, күренгәндер генә). Мотороллер әйләнеп каплана. Җевсиевның сикерерлек рәте булмый. Ә Мәкәрҗәдән кайтучы купец кебек әрҗәдә кырын ятып хозурланып баручы Шурик (бәлки, әле ул үзен хан кызы кочагындагы Степан Разин урынында тойгандыр, доза әйбәт бит) аңга килергә дә өлгерми, мотороллер астында кала. Нәтиҗәдә, Җевсиевның башы тишелә, ә Шурикның кулы сына.

Сәрхушне кеше итәм, тагын бер белгечле булам дигән яшь баш табиб, киресенчә, янә бер белгеченнән дә коры кала. Мотороллер да эштән чыга.

Савино фермасына тиз генә белгеч табып булмаганлыктан, минем үземә анда ешрак баргаларга туры килде. Бу вакытта инде мин транспорт мәсьәләсендә «служебный» атка тукталдым. Миңа бик матур, озын торыклы алмачуар бия бирделәр. Шуңа өстәп, сыгылмалы тарантас. Ассызыклап әйтергә кирәк, сыгылмалы. Хәзер тарантас ясый белмиләр. Мин күргәннәренең колгалары кыска һәм каты. Шуңа күрә хәзерге тарантаслар арба кебек дыңгырдап бара, ә чын, сыгылмалы тарантас исә келтерәп. Менә шул тарантаста тибрәлеп кенә, уйларга чумып, бүген-иртәгә ниләр эшлисен планлаштырып, ә кайчагында хыялларга ияреп, тарантастан да өстәрәк бару минем кебек хисле кешегә күпкә ошабрак китте. Мотоциклда йөргәндә юлны бит үзең карап барырга кирәк. Аз гына хыялланып китеп, игътибарыңны югалтсаң, юл читенә барып мәтәлүең дә бар. Ә ат бит ул акыллы хайван, дөресрәк итеп әйткәндә, малкай (хайван сүзе кайбер кешеләргә турырак килә) юлны үзе карап бара. Әле каядыр барганда дилбегәне уңга-сулга тарткаларга туры килсә дә, кайту ягына аны өйрәтәсе юк. Шул акыллы малкайлар аркасында күпме салмыш ир-ат күз ачкысыз бураннарда да өенә кайтып җитә алган. Юкка гына: «Эт – кешенең дусты, ат – кешенең иптәше», – дип әйтмәгәннәр бит. Ат корыда тузан күтәрми, пычракта батмый.

Бу атның бер-ике айлык тае да бар. Менә шушы тай белән бәйле хәл хәзер еш кына искә төшә. Әйткәнемчә, Савинога көнара барып йөрергә туры килде. Шунда бер өй яныннан узганда капка астыннан аклы-каралы йонлач әнчек тәгәрәп чыгып, чәң-чәң килеп, тай өстенә ташлана торган булды. «Эт үз оясында көчле» дигән сүз дөрестер, бу минем бик ачуланып: «Пшол!» – дип кычкыруыма да игътибар итми. Тай, мескен, моннан куркып, кисәк кенә чабып китә. Эт, бераз куып баргач, кирәкле эшен эшләгән кешедәй, бик эре кыяфәт белән яңадан капка астына кереп югала. Бу хәл Савинога барган саен кабатлана торган булды. Инде мин дә: «Эт өрә, кәрван бара!» – дип, моңа игътибар итми башладым. Тай да күнекте кебек. Тай белән эт арасы вакыт узу белән кыскара барды. Шулай көннәрдән беркөнне теге эт янәдән тәгәрәп чыкты. Мин, моңа исем китмичә, үз уйларыма батып баруымны дәвам иттем. Мине уйларымнан әнчекнең җан ачысы белән чинаган тавышының җирдән өскә таба күтәрелүе уятып җибәрде. Мин сискәнеп башымны күтәргәндә, эт җирдән бер метр чамасы югарылыктагы траектория буенча очып бара иде. Ул арада бичара лап итеп барып төште дә тынсыз калды. Мин атны туктатып аның янына йөгердем. Исәп – хәлен белеп, ярдәм күрсәтергә. Мин килеп җитәм дигәндә генә, эт ялт кына торып капка астына кереп шылды.

Эшнең нәрсәдә икәнен Борнашка кайткач кына аңладым. Тайның бераз аксавына игътибар итеп, тотып, аягын тикшереп карасам, канаган урыны барлыгы беленде. Теге эт, тайның һаман чабып китүен, җавап бирмәвен куркуга санап, торган саен оятсызланып, якынрак килә барып, соңгы чиктә тешләп карарга булган, күрәсең. Ләкин һәрнәрсәнең чиге бар. Тай әллә куркудан, әллә авыртудан, үз мөмкинлекләреннән чыгып, моңа кушаяклап җавап биргән.

Әлеге очрактан соң теге әнчек без узганда, тынын да чыгармыйча, күзләрен елтыратып капка астыннан гына карап кала торган булды.

Гомер юлында очраган кайбер кешеләрне күргәч, шушы эт искә төшә иде.

Бу хәлләрдән соң озак та үтмәде, мине армия хезмәтенә алдылар. Калганы инде сезнең күз алдында булган хәлләр, җәмәгать!.. ■

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – галимнәр, язучылар, журналистлар, дин һәм сәнгать әһелләре октябрь аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Менә алар:

1 октябрь – журналист, галим, филология фәннәре докторы (1999), профессор (2000) **Васил Заһит улы Гарифуллин**га 60 яшь (1961);

10 октябрь – рәссам-нәкышчы, педагог **Гөлназ Равил кызы Әдһәмова**га 50 яшь (1971);

5 октябрь – артист, Татарстан Республикасының халык артисты (1997) **Нуретдин Гыйльмихан улы Нәҗмиев**кә 75 яшь (1946);

20 октябрь – шагыйрь, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы **Фәнәвис Әбеләис улы Дәүләтбаев**ка 70 яшь (1951);

8 октябрь – шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1995), ТРның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (2006), Татарстанның халык язучысы **Марсель Баян улы Галиев**кә 75 яшь (1946);

21 октябрь – режиссер, Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Илдус Нәсыйх улы Зиннуров**ка 75 яшь (1946);

24 октябрь – композитор, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1989) **София Әсхәт кызы Гобәйдуллина**га 90 яшь (1931).

Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз! ■

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Тензинның Нантайзи мәхәлләсе мәдрәсәсендәге китапларны да күрәсем килде. Шәкертләрнең берсеннән: «Нинди китапларыгыз бар?» – дип сорадым. Шәкерт китапларның барысын да алып килеп, алдыма куйды. Боларның да күбесе кулъязма китап иде. Фикъһ (хокук), нәху (җөмлә төзелеше) һәм сарыф (сүз төркемнәре) китаплары бар иде. Гакаид-и Нәсәфи, Мохтасарүл-мәгани, Дәсукый[1] бар. Фикъһ китапларының кайберләре кытай телендә язылган. Дәрес китапларының исә барысы да гарәпчә. Дини гыйлемнәр барысы да гарәп телендә була, боларның һәммәсе дә кагыйдәләре белән өйрәтелмәсә һәм өйрәнелмәсә, ул ничек була инде? Голәмә исемен йөрткән кешеләр ничек инде, һич булмаса, әйтергә теләгән фикерен әйтә алырлык кына да сөйләшә алмыйлар? Болар берничек тә акылыма сыймый. Безнең голәмәбездә дә бар бу хәл. Шулай булса да, безнең голәмәбез әйтергә теләгән фикерен генә булса да әйтә ала. Белмиләр, дисәк тә, азмы-күпме белүчеләр дә очрап куя.

Әйе, биредә, Нантайзи мәхәлләсендә ахун җәнаплары «МәшаАллаһ!» дип әйтерлек дәрәҗәдә белә. Унөч мең мөселманы булган шәһәргә бер кеше. Башка мәчетләрдә исә бөтенләй дә юк. Бу җәһәттән, Коръән уку тәртибе ягыннан караганда, мөселман кытайлар бик сәер һәм бик бичара хәлдә калган халык. Ләкин шул ук вакытта, мәдрәсәләр бик күркәм, төзек. Кытайда, безнең Русия мөселманнарында булган кебек, мәдрәсәләр мәчетнең малы булып санала. Тагын шунысы да мөһим: мәчет янында тәһарәтләнү өчен аерым урын бар һәм биредә тәһарәт өчен дә, госел[2] өчен дә җылы су һәрвакыт була. Бөтен мәхәллә халкы тәһарәт һәм госел өчен мәчеткә килә, гел мәчеттә булалар. Тензин мәчетләрендәге арулык, тәртип бик югары дәрәҗәдә. Бу эшләр белән идарә итүнең чыгымнарын хәер әһелләре күтәрә икән. Шул рәвешле, Кытай мөселманнарында дөньяның бер генә җирендә дә күреп булмый торган хәлләр бар. Мин Тензин әйләнә-тирәсендә дә бераз йөрдем. Биредәге мөселманнар белән мәҗүсиләр арасында бер-берсен өнәмәү бик аз, янәшә шактый яхшы яшиләр. Сәбәбен күпчелекнең мөселман булуы белән аңлаттылар. Кытай илендә, гомумән, мөселманы күп булган төбәкләрдә иҗтимагый тәртип һәрвакыт яхшы була икән. Мәҗүсиләре күп булган төбәкләр исә бер дә тыныч яшәмиләр, тәртипсезлекләр гел булып тора икән. Мин моны үзем дә сынадым, чыннан да, шулай иде.

Мәҗүсиләр мөселманнарга гел дошманлык күрсәтәләр. Соңгы вакытларда хөкүмәт тулысынча мәҗүсиләр кулында булганга, мөселманнарның кешелек хокуклары гел аяк астына салына килгән. Бичара мөселманнар, үзләрен мәҗүсиләрнең явызлыгыннан саклау өчен, берара динне яшерен тотарга мәҗбүр булганнар. Шул сәбәпле, мәҗүсилек гадәтләрен кабул итеп, чәчләрен, тырнакларын мәҗүсиләр кебек йөрткәннәр, мәҗүси киемнәрен кигәннәр. Хәзерге вакытта да мөселман кытайны

[1] Гакаид-и Нәсәфи – Нәҗмүддин әбү Хафс Өмәр бин Мөхәммәд ән-Нәсәфинең (үлеме 1143 елда) иман турында язылган әсәре; Мохтасарүл-мәгани – Әс-Сәккакыйның гарәп грамматикасына Әл-Казвини тарафыннан язылган өстәмәләр китабына Саадәтдин әт-Тәфтазани (үлеме 1390 елда) язган шәрехләр китабы; Дәсукый – Мисырда яшәгән бөек ислам галиме Борһанеддин Ибраһим бин Әбил-Мәжд Абделазиз әд-Дәсукыйның (үлеме 1277 елда) әсәре турында сүз бара *(тәрж.иск.)*.
[2] Госел – гәүдәнең аерым өлешләрен генә түгел, бөтенләй юып арулану *(тәрж.иск.)*.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

күренештә мәҗүси кытайдан берничек тә аерып булмый. Читтән килгән кеше генә түгел, үзләре дә карап торышка кемнең мөселман, кемнең мәҗүси икәнен әйтә алмыйлар.

Мондый дөньяви гадәтләрдә генә түгел, гыйбадәт кылуда да ияргә мәҗбүр булганнар. Мәчетләр дә тышкы күренешләре белән мәҗүси гыйбадәтханәләреннән берни белән дә аерылып тормый. Мәчет биналарының өстендәге сурәтләр барысы да мәҗүсилек белән бәйле. Җеназа чыгару рәвеше һәм ак төстәге матәм киемнәре – барысы да мәҗүсиләрнең гадәте. Җеназаны озатканда кулларына таяк тоту гадәте дә мәҗүсиләрдә бар. Җеназа вакытында таяк тоту Бохара голәмәсендә дә киң таралган. Аларда да мәҗүсиләргә ияреп килеп чыккандыр дип уйлыйм. Моннан тыш, җеназаны зур чатыр белән чыгаралар. Бу да Кытайдан кала башка һичбер мәмләкәттә юк.

Ниһаять, Тензин шәһәреннән киттем һәм Кытайның башкаласы Пекин шәһәренә юл тоттым. Пекин белән Тензин арасы дүрт сәгатьлек юл, бу ике шәһәр арасында көндә берничә поезд килеп-китеп йөри. 28 июнь көнне кичке сәгать 8дә мин Кытайның башкаласы Пекинга килеп җиттем.

Пекин

Дөньяның иң борынгы шәһәрләренең берсе булган Пекин мәдәнилекнең, ягъни цивилизациянең дә иң борынгы үрнәкләренең берсе булып тора. Бөек Кытай дәүләтенең пайтәхете булган Пекин – бөтен дөньяга танылган бөек шәһәр.

Мин биредә дә, бар нәрсәдән элек, әлбәттә, мөселман кардәшләребез турында сүз алып барачакмын. Монда мин мөселман мәхәлләсендә, Ван-Куан исемле ахунның мәдрәсәсендә кунак булып яшим. Бу кеше – Пекин голәмәсе арасындагы бөек шәхесләрнең берсе. Гарәпчә исеме – Абдуррахман, ләкин бу исемне белүчеләр бик аз. Ван-Куан дисәң, мөселманы, мәҗүсие – барысы да белә. Пекинда менә шул мөхтәрәм зат яшәгән мәхәлләгә Нуҗе диләр. Биредәге мәчет Пекин мәчетләре арасында иң зурысы һәм иң борынгысы икән. Моннан 634 ел элек төзелгән. Бу дата кытайча ташка чокып язылган.



Пекин шәһәре. XX гасыр башы

Биредә Ван-Куан җәнаплары мине олы ихтирам белән каршы алды, аерым бер бүлмә бирде, шунда яшәячәкмен. Монда килеп урнашкач, ястү намазы вакыты да җитте, шунда катнаштым. Бер яшь кеше азан әйтте, азаннары шактый тәэсирле, Истанбул аһәңен хәтерләтә иде. Бик сөендем.

Өч ихлас сүрәсеннән соң каамәт[3] укылды, бу да бик күркәм иде. Болар һәммәсе миңа олы өметләр вәгъдә итә иде. Шуннан соң намаз укый башладык. «Фатиха» сүрәсе укылды. Нәрсә дип әйтим: имамга ярдем инде. Аллам кичерә күрсен! Монда исламият никадәр кызганыч хәлдә: «Фатиха» сүрәсе шундый «Фатиха» сүрәсе ки, чәчләр үрә торырлык. Ул мөбарәк «Фатиха» сүрәсе сулкылдап елый иде...

Шулай итеп, әлеге көнне инде болай да бик арыган булганга, тирән уйларда булсам да, яткач та йоклап киткәнмен. Күргән төшләрем дә шул мөбарәк «Фатиха» сүрәсе турында иде. Ах, бичара исламият! Ниләр генә күрмәгәнсең! Миллионнарча мөселман нинди хәлләргә төшкән! Болар турында уйлаган кеше тыныч кына йоклый аламы соң?!

Иртәгесе көнне иртүк уянып тордым да мәчеткә киттем. Әле караңгы иде. Бу юлы инде бераз хәзерлекле булдым. Мулла әфәнде алга чыгуымны сорап миңа ишарә ясауга, шунда ук михрабка таба үттем, иртәнге намазны кылдырдым.

Кытайда намаз

Маньчжуриядә һәм көньяк-көнчыгыш Кытайда, Си-Чуан (Сычуань) төбәкләреннән Тонкинларга кадәр, иң аз дигәндә, 35-40 миллион мөселман арасында намаз – тойгының тойгысына гына бәйле гыйбадәт. Бары тик голәмә һәм мәдрәсә әһеле генә намаз кыла. Болардан тыш, мәмләкәтнең дәрәҗәле һәм алдынгы кешеләре арасында биш вакыт намаз кылучы кеше бик аз, бик сирәк очрый. Җомга намазы исә бар җирдә дә диярлек укыла.

Намаз кылу тәртибе, нигездә, Хәнәфи мәзһәбе буенча. Тәһарәт һәм арулыкка да игътибар зур. Тик мәчетләр күбесенчә бик үк ару булмый. Мәчетнең эче, гадәттә, мәчет кебек: намазлыклар-фәләннәр була, михраб тирәләре дә Истанбул мәчетләрен хәтерләтә. Михраб янында шәмаил-фәлән дә эленгән була. Аеруча Нуҗе мәчетенең михраб тирәләре кайчандыр бик бизәкле булган: куфи язуы һәм алтын буяу белән аятьләр, пәйгамбәрләрнең хәдисләре язылган булган. Әмма мәчет бик тузган, искергән. Бик гаҗәп: шундый матур шәмаилләр бар, такта өстен уеп, сөлөс, куфи, тәгълик[4] язулары белән гаять сәнгати һәм гаять мәгънәле җөмләләр язылган. Болар барысы да борынгы әсәрләр һәм нәфис сәнгать үрнәкләре. Кытай язуы белән язылган такталар да эленгән. Боларга карап фикер йөртсәң, кайчандыр Кытайда дин гыйлеменең бик нык алга киткән булуы ачык аңлашыла. Андый шәмаилләрне, такталарны язган кешеләр җаһил була алмый, әлбәттә.

Намаз кылганда, кытайлар чалма урынына Бохара түбәтәенә охшаган бер төр башлык кияләр, озын чәчләрен шуның эченә җыеп кыстыралар. Бу башлыкларын бары тик мәчеттә генә кияләр. Башка вакытларда исә, бөтен кытайлар яланбаш йөри. Җәй көннәрендә баш киеме бөтенләй кимиләр, кыш айларында исә кытайларның барысы да бертөрле башлык кия. Чалманы бары тик голәмәнең башында гына күрергә мөмкин, алар да аны бары тик мәчет эчендә генә кияләр. Намаз кылу тәртипләре бер ягы белән дә бездәгедән аерылмый. Кытай мөселманнары барысы да Хәнәфи мәзһәбендә булганга, аерма була да

[3] Каамәт (а озын әйтелә) – намазны башлау ишарәте, намаз кылу өчен әйтелә торган азан *(тәрҗ.иск)*.
[4] Сөлөс, куфи, тәгълик – гарәп хәрефләре белән сәнгати язуның төрләре *(тәрҗ.иск.)*.

Кытайның Гуанчжоу (иске исеме Кантон) шәһәрендәге бер мәчет

алмый. Бары тик Коръән уку гыйлемнәре генә бөтен Кытай илендә бик нык артта калган. Ачыктан укыла торган фарыз намазларда «Фатиха» сүрәсен укыганда, бу сүрәне укыйлармы, башкасынмы – аңлый алмый азапланасың хәтта. Ул җәһәттән бик гаҗәп, бик сәер.

Тәганни һәм тәрәннүмнән[5] башка да хәрефләрне уку рәвешләре гарәпчә авазларга охшамый. «Иһдинас-сырат», мәсәлән, «иһдина насрат» дип укыла. Болай уку бөтен Кытай мөселманнарына да хас. Моннан тыш, мәчеткә керә торган җирдә бертөрле кызыл өстәл өстендә агачтан ясалган төрле-төрле тартмалар тора. Бу хөкүмәт тарафыннан бирелә икән. Нуҗе мәчетенең ишегеннән керүгә, теге кызыл төстәге өстәлдән башка әле тагын бик матур җәли язуы[6] белән язылган өстенлек таныклыгы да бар. Аны инде вафат булган императорлары биргән булган икән. Болардан башка, ташлар өстенә кытай язуы белән чокып язылганнары да очрый, барысы да мәчетнең тарихы белән бәйле, ди.

Нуҗе мәчетенең бик матур мәдрәсәсе дә бар. Мәдрәсә дә бик борынгы, мәчетнең әйләнә-тирәсендә төзек, ләкин сәер биналар да бик күп. Тик аларның нәрсә икәне аңлашылмый.

Читтән караганда, мәчет мәҗүсиләрнең гыйбадәтханәсеннән һич кенә дә аерылмый. Мәчет өстендәге сурәтләр бик сәер булып күзгә ташлана, ләкин нишләмәк кирәк, Кытай мөселманнары тарафыннан бик матур дип кабул ителә, диннең бер билгесе дәрәҗәсендә тотыла. (Җаһиллекнең чиге юк.)

Нуҗедә кырыклап мәдрәсә шәкерте бар икән, болардан башка мәктәп укучылары да бар, алары йөзгә якын икән.

Абдуррахман мөфти (Ван-Куан мөфти)

Биредәге мөфти Абдуррахман җәнаплары шактый фикерле кеше. Ул Кытай мөселманнарының бу хәлләренә бик борчыла һәм исламның күтәрелүен бик

[5] Тәганни (ялгышы) – Коръәнне мәкам белән укыганда дөрес булмаган авазлар чыгарып, сүзләрне бозу; тәрәннүм (ялгышы) – Коръәнне көйләп укыганда ясалган ялгышлар *(тәрҗ.иск.)*.

[6] Җәли язуы – гарәп язуының алты төп һәм соңрак барлыкка килгән биш, барлыгы унбер төре арасында аерым бер төр түгел, ә язуның бу төрләрдән берәрсе белән эре итеп язылганлыгын гына белдерә *(тәрҗ.иск.)*.

тели. Мин иртәгесе көнне бу кеше белән күрештем, бик озаклап сөйләштек. Кытай мөселманнарының үткәне һәм бүгенгесе турында бик күп нәрсә сорашып белдем. Ван-Куан ислам диненә бик нык бирелгән, гаять диндар кеше. Аның турында башка сүз сөйләп торуның кирәге юк. Нәсел-нәсәбенең Саад бин Әбе Ваккас хәзрәтләренә барып тоташуын әйтте, шәҗәрәсе-фәлән дә бар икән. Ул Кытай хөкүмәте тарафыннан да ихтирам ителә, танылган шәхес, алда телгә алынган мәчетнең мөтәвәллие, ягъни вакыф хезмәткәре һәм шул ук вакытта мәхәлләнең, әлбәлки, бөтен Пекин мөселманнарының иң могтабәр кешесе дә иде.

Бу мөхтәрәм зат турында мин биредә Кытай мөселманнарының карашыннан чыгып мәгълүмат бирәчәкмен. Бичара Ван-Куан дингә бик нык бирелгән кеше, тик безнең суфиларыбыз кебек милләт мәнфәгатен уйламаслык дәрәҗәдә түгел. Фәкыйрь генә кеше булса да, милләтнең киләчәген уйлап, моннан берничә ел элек Хиҗазга барган. Шул вакытта Истанбул аша үткәндә солтан Абдулхәмид Хан белән күрешкән. Үзе тел белми инде, әлбәттә, ул заманнарда кытай теленнән тәрҗемә итәрлек тәрҗемәче дә табып булмаган. Абдулхәмид Хан белән гарәпчә сөйләшкәннәр. Ул чакта әле гарәпчәсе начар булган, солтан Абдулхәмиднең дә гарәпчә белүе аныкыннан әллә ни артык булмагандыр дип уйлыйм. Шулай булуга да карамастан, Ван-Куан солтан Абдулхәмид хозурында әйтергә теләгән фикерен әйтә алган. Кытай мөселманнарында җаһиллек киң таралганын, әгәр хәлифәлек идарәсе тарафыннан ул якларга берничә генә булса да мөгаллим җибәрелмәсә, Аллаһ каршысында җавапны алар тотачакларын аңлаткан. Шуннан соң Дини эшләр идарәсе ике мөгаллим җибәрү турында карар чыгарган. Хезмәт хаклары падишаһның үз кеременнән түләнеп, Али Рыза һәм Хафыз Хасан исемле ике әфәнде шәйхелисламлык таныклыгы белән Пекинга килгәннәр, бер ел Коръән укырга өйрәткәннәр.

Бу һаман да шул Ван-Куан Абдуррахман мөфти җәнапларының милләтен кайгыртуының нәтиҗәсе булып тора. Шул рәвешле Ван-Куан, беренче булып, Пекин белән Дәрсәгадәт, ягъни Истанбул арасында дини бәйләнеш барлыкка китергән булып чыга. Ахун Ван-Куан җәнаплары бары тик бу тырышлыгы өчен генә дә Кытай мөселманнарына гаять зур хезмәт башкарган булып санала алыр иде.

Чынбарлыкта Ван-Куан моның белән генә дә чикләнмәгән. Нуҗеда яңа мәктәпләр ачкан, боларның идарәсен тәэмин итәр өчен хөкүмәттән рәсми рөхсәт алырга тора. Әлегә җирәбә ысулы белән акча җыя, һәр ай бер тапкыр җирәбә билетлары чыгара. Бу билетлар нәкъ бер ай буе сатыла, аннары җирәбә салалар. Бу җирәбә юлы белән мәктәп мәнфәгатенә аена 100 доллар акча җыела. Шулай җыелган акчалар белән әлегә мәктәпнең идарәсенә һәм мөгаллимнәргә хезмәт хакы түләү эше җайга салынган.

Мәктәпләрендә укыту ысулы кытайча һәм кытай хәрефләре белән. Шул ук вакытта гарәп теле һәм дини гыйлемнәр дә бар.

Әйе, алар кулланган җирәбә комар уены булып санала. Ван-Куан җәнаплары да моңа хәләл дими: «Нишлик, милләтебез фәкыйрь, шул юл белән булса да акча тапмасак, бөтенләй дә мәҗүси мәктәпләренә мохтаҗ булып калачакбыз. Аннары динебезне бөтенләй югалтачакбыз, мин ике начар арасыннан азрак начар булганын сайладым», – ди.

Әлбәттә, безнең Русия голәмәсе мондый хәлгә риза булмас, барысы бер авыздан «хәрәм» дияр иде. Ван-Куан да, хәрәм, ди, тик шулай булса да кабул иткән, бу эше изге ният өчен булгангадыр дип уйлыйм.

Олы яшьтә мөгаллимлек

Ван-Куан шул көннәрдә: «Монда булганда, безнең мәдрәсә шәкертләренә Коръән уку гыйлемен өйрәтсәгез иде. Бераз гарәп теле белән дә шөгыльләнсеннәр-фәлән», – дип, миңа да мөгаллимлек эше йөкләде. Кире кага алмадым, хәлләрен күреп, күнәргә мәҗбүр булдым. Ике айга якын шәкертләр укыттым.

Ван-Куан шул рәвешле гел милләтенең мәнфәгатен кайгырта иде. Бу кешенең кимчелекләре турында да әйтеп үтәргә телим. Аның кимчелекле сыйфатлары яхшы яклары турында сөйләүгә киртә булып тора алмый дип уйлыйм. Кеше гел яхшы гына да, гел яман гына да була алмый. Мөфти Абдуррахман милләте турында бик күп уйланган һәм хәзер дә уйлана. Тик кайчак яшьләр тәкъдим иткән яңалыкларны кабул итми, ул, асылында, кимчелек тә түгел. Зиһене кабул итмәгәнгә, аларны аңламый һәм аның өчен гаепләп тә булмый.

Пекин яки Печин

Кытайлар үзләре күбесенчә Печин диләр икән. Бу шәһәр борынгы күренешен саклаган: трамвай юк, күтәртмә юллар юк, электр юк, теге юк, бу юк, юк та юк. Шулай да Көнчыгышта «шәһәрләрнең анасы» дип аталырга лаеклы борынгы шәһәр булып санала. Биредә бер миллион кеше яши. Якынча уннан беренең мөселман булуы бик ихтимал. Мөселманнар яши торган 33 мәхәллә һәм мәчет бар.

Боларның иң зуры – Нуҗе, 1500 йортлы мәхәллә. Икенчесе – Час Хоти мәхәлләсе. Биредә дә меңнән артык йорт бар. Бу мәхәлләнең имамы Мулла Насреддин әфәнде дә бик яхшы кеше, саф күңелле мөселман. Мәхәлләнең мәчете әле яңа гына салынган. Тик бу мәчет бик төзек, искиткеч матур булса да, Нуҗе мәчетенә караганда кечерәк.

Мулла Насреддин бик тәкъва һәм диндар кеше. Мәдрәсәдә 5-10 шәкерткә дәрес бирә, тик башка берни белән дә шөгыльләнми. Мондагы шәкертләрнең берсе шактый яхшы төрекчә белә икән, Хафыз Хасан әфәнде өйрәткән. Бу да ара-тирә безнең эшебезгә ярады. Гомумән алганда, Кытай мөселманнарында укыту ысулы бик сәер.

Мәдрәсәләрдәге китапларның күбесе гарәп телендә, фарсы телендәгеләр аз. Тик болар, дәрес өйрәнгәндә, китапның гарәпчә гыйбарәсен һич кулланмыйлар, гарәп телендәге китапка карап, турыдан-туры аның кытайчага тәрҗемәсен укыйлар. Ерактан карап торсаң, кытайча ниндидер бер китап укыйлар, ахры, дип уйлыйсың хәтта. Китапның тәрҗемәсен шундый зур тизлек белән укуларына караганда, гарәп телен белүләре бик югары дәрәҗәдә булырга тиеш иде. Ләкин гарәпчәләре бөтенләй юк. Бу бөтенләй аңлашылмый торган хәл.

Биредә безнең мәмләкәтебездә һәм безнең мәдрәсәләребездә булган нәхү һәм фикъһ китапларының барысы да бар, шуның өстенә әле «Мохтасарул-мәгани» дә бар. Аларның бер өлеше хәтта кытай теленә тәрҗемә дә ителгән, мәдрәсәләрдә, шәкертләр арасында тәрҗемәләре дә кулланыла.

Боларның һәммәсе кайчандыр Кытайда голәмәнең булуына дәлил булып тора. Фикъһта гыйлемле булганнар бик күренмәсә дә, гарәп телен белүчеләр шактый булган дигән сүз, чөнки фикъһ һәм нәхү китапларының күбесен кытай теленә тәрҗемә иткәннәр. Бүгенге көндә исә Кытай голәмәсе моны башкара алыр иде дип уйламыйм, чөнки болар гарәп телен бөтенләй белмиләр.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

Безнең мирас №10 октябрь 2021

САБЫЙЛАР ӨЧЕН ДИНИ МИРАС

Дин дәресләре

Сөнгатулла Бикбулат

Дүртенче дәрес
Тәсмия (бисмилләһ) һәм хәмед (мактау)

Мөгаллим: Без шушы үзебез файдалана торган нәрсәләрне Аллаһы Тәгалә безгә бушлай биргән дигән идек. Беләсезме нәрсәне кемгә бушлай бирәләр? Менә сезгә ата-аналарыгыз һәр кирәк нәрсәләрегезне биреп торалар: сезне ашаталар, эчертәләр, киендерәләр, кадерлиләр. Алар нигә болай итәләр?

Шәкерт: Чөнки алар безне яраталар.

Мөгаллим: Шулай шул, алар сезне ятканга күрә шулай тәрбия итәләр. Сезгә берәү берәр нәрсә бушка бирсә, сезне яратканлыгы өчен бушка бирә, шулайдыр бит?

Шәкерт: Шулай, мөгаллим әфәнде.

Мөгаллим: Аннан соң син менә бер мескенне күрсәң, сәдака бирәсең. Беләсеңме, нигә бирәсең?

Шәкерт: Аны кызганып бирәмен.

Мөгаллим: Синең сәдака биргәнең бармы?

Шәкерт: Бар, әнкәй миннән гел мескеннәргә сәдака бирдерә.

Мөгаллим: Бик яхшы. Фәкыйрь һәм мескеннәрне шулай кызганырга, аларга сәдака бирергә кирәк. Алар да бит безнең кебек үк кеше. Менә Аллаһы Тәгалә дә, без зәгыйфь бәндәләрен яратканга һәм кызганганга күрә, безгә бик күп нәрсәләр биргән һәм һәрвакыт биреп тора. Безгә бушлай бирә. Үзенең рәхмәте белән бирә, шулай бит?

Шәкерт: Шулай, мөгаллим әфәнде.

Мөгаллим: Алай булгач, Аллаһы Тәгалә безне бик кызгана, бик ярата икән. Безне яраткан кешене без яратабызмы?

Шәкерт: Бик яратабыз.

Мөгаллим: Менә ата-аналарыгыз, мөгаллимнәрегез сезне бик яраталар, гел яхшылык телиләр. Сез дә аларны шулай яратасызмы?

Шәкерт: Бик яратабыз. Аларга гел яхшылык телибез.

Мөгаллим: Шулай, аларны яратырга, аларга яхшылык теләргә, аларны һәрвакыт истә тотарга кирәк. Менә минем атам-анам хәзер вафат, минем хәлфәм дә инде вафат. Мин һәрвакыт алар өчен дога кылам, аларны искә төшерәм. Әткәм-әнкәм мине мәктәпкә бирде. Хәлфәм мине тырышып укытты. Алар сәбәпле уку-язу белдем, динемне өйрәндем, Раббымны таныдым, димен. Алар өчен һәрвакыт Аллаһыга дога кылам. Сез дә шулай ата-ана, хәлфәләрегезне истә тотасыздыр бит?!

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2021) санында.

Шәкертләр: Һәрвакыт истә тотабыз.

Мөгаллим: Алай булгач, Аллаһы Тәгаләне дә һәрвакыт истә тотарга кирәк буламы?

Шәкерт: Һәрвакыт истә тотарга кирәк була.

Мөгаллим: Шулай шул, Аны бигрәк тә истә тотарга кирәк. Без үзебез дә бит Аныкы. Безгә кирәк бөтен нәрсәләр дә Аныкы. Шулай булгач, Ул бер дә истән чыкмаска тиеш. Нинди генә эшне башласак, нинди генә эшкә керешсәк тә, Аны искә төшерергә, Аның исемен искә алырга кирәк. Беләсезме: безгә яхшы эшләр эшләргә кирәкме, әллә начар эшләрме?

Шәкерт: Әлбәттә, яхшы эшләр эшләргә кирәк.

Мөгаллим: Шулай, яхшы эшләр генә эшләргә кирәк. Начар эш эшләгән кешене без үзебез дә яратмыйбыз, аны яманлыйбыз. «Ул начар кеше», – дибез. Аллаһы Тәгалә дә бәндәләренең гел яхшы эш эшләүләрен тели, яман эш эшләүләрен бер дә яратмый. Алайса безнең һәр эшебез яхшы, файдалы эш кенә булырга тиеш. Менә шул яхшы, файдалы эшләргә керешкәндә, без Аллаһы Тәгаләне искә төшерергә, Аның исемен йад итәргә, Аның безгә бик мәрхәмәтле булганлыгын искә төшерергә бурычлы. Шулаймы, шәкертләр?

Шәкертләр: Шулай-шулай. Һәр эшне башлаганда, Аллаһы Тәгаләнең исемен әйтергә кирәк.

Мөгаллим: Менә без укый башлыйбыз. Бу бит яхшы эш!

Шәкертләр: Бик яхшы эш.

Мөгаллим: Әгәр Аллаһы Тәгалә безгә күз, тел, колак бирмәгән булса, укый алыр идекме?

Шәкертләр: Юк, укый алмас идек.

Мөгаллим: Шулай шул, укый алмас идек. Аң бирмәгән булса, хәлфәләрнең сүзен дә аңлый алмас идек. Кул бирмәгән булса, яза да алмас идек. Боларның барысын да Аллаһы Тәгалә биргән. Без шул Аллаһы Тәгалә биргән әгъзаларыбыз белән укыйбыз, язабыз. Шулай булгач, безгә укырга-язарга керешкәндә нишләргә кирәк?

Шәкертләр: Аллаһы Тәгаләне искә төшерергә кирәк.

Мөгаллим: «Ий, рәхмәте киң Аллаһы, Синең исемең белән башлыйм. Бу эшне бетерергә Синнән ярдәм сорыйм», – дияргә кирәк, шулаймы?

Шәкертләр: Шулай, хәлфә, шулай.

Мөгаллим: Тик безгә моны гарәпчә сүзләр белән әйтергә кирәк. Беләсезме, ничек әйтергә кирәк? Белгән кешеләр кул күтәрсеннәр!

(Шәкертләр кул күтәрәләр.)

Мөгаллим: Йәле, Габдуллаһ, әйтеп кара әле!

Шәкерт: Бисмиллааһир-рахмәәнир-рахиииим.

Мөгаллим: Афәрин! Тик син азрак башкачарак әйтәсең. Менә мин әйткәнчә әйт: Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиииим.

Шәкерт: Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиииим.

Мөгаллим: Тагы бер кат әйт әле!

Шәкерт: Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиииим.

Мөгаллим: Йә, Кәрим, син дә әйт әле.

Шәкерт: Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиииим.

Мөгаллим: Шулай, афәрин. Яле, барыбыз бердән әйтик: Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиииим.

Сарман авылындагы Җәмигъ мәчет

Сарман районындагы Иске Минзәләбаш авылында элекке мәчет урыны һәм «Ихлас» мәчете (артта)

Мөгаллим: Алай булгач, без уку алдыннан гел Аллаһы Тәгаләне искә төшергәнбез икән.

Шәкерт: Әйе, гел искә төшереп киләбез.

Мөгаллим: Соң башка вакытларда шулай Аллаһы Тәгаләне искә төшерәсезме?

Шәкерт: Төшерәбез: ашарга утырганда, йокларга ятканда, киемнәрне кигәндә.

Мөгаллим: Афәрин, дөрес әйтәсең. Без Аллаһы Тәгаләне һәрвакыт шулай искә төшерәбез. Тик сез «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиииим»нең безнеңчә ни дигән сүз икәнлеген яхшы белмәдегез әле. Ул менә ни дигән сүз: «Бу эшне рәхмәте һәм мәрхәмәте чиксез Аллаһының исеме белән башлыйм».

Йә, әйтеп кара әле, Шәриф!

(Шәкерт әйтә.)

Мөгаллим: Йә, Гариф, син гарәпчә әйтеп кара!

Шәкерт: Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиииим.

Мөгаллим: Йәгез, барыгыз бердән әйтеп карагыз әле!

Шәкертләр: Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиииим.

Мөгаллим: Менә шулай һәр эшкә керешкәндә Аллаһы Тәгаләне искә төшерергә вә: «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиииим», – дип әйтергә кирәк безгә. Шулай ук бер эшне бетергәндә дә Аллаһыны искә төшерергә тиешбез. Безнең бар нәрсәләребез дә Аллаһы Тәгаләнеке. Ул безгә аларны файдаланырга биргән, бушка биргән, дигән идек. Берәү кешегә нәрсә дә булса бирсә, башкаларга ярдәм итсә, ул кешене нәрсә эшлиләр?

Шәкерт: Мактыйлар, яхшы кеше, диләр.

Мөгаллим: Шулай. Андый кешене һәрвакыт мактыйлар: «Габдуллаһ агай бик яхшы кеше. Ул халыкка файда итә, фәкыйрь-фөкарага ярдәм кыла, мәктәпләр тәрбия итә», – диләр. Аллаһы Тәгаләнең безгә кылган яхшылыклары, биргән нәрсәләре әйтеп бетергесез. Шулай булгач, Аны мактарга, бик мактарга кирәк. Шулай түгелме?

Шәкертләр: Шулай.

Мөгаллим: Әлбәттә, шулай. Без Аллаһы Тәгаләне һәрвакыт мактарга тиеш. Бигрәк тә берәр эшне эшләп бетерсәк, мактарга: «Ий, бөтен галәмнең Хуҗасы, Сине мактыйбыз», – дияргә кирәк. Тик без моны да гарәпчә әйтергә тиеш. Беләсезме, ничек әйтергә кирәк?

Шәкерт: Ничек?

Мөгаллим: Менә ничек әйтергә кирәк: «Әлхәмдүлилләһи раббил-галәмииииин». Йәле, Габдуллаһ, әйтеп кара әле?

Шәкерт: Әлхәмделилләһи...

Мөгаллим: Менә минемчә дөрес итеп әйт: «Әлхәмдү... »

Шәкерт: Әлхәмдү...

Мөгаллим: Кәрим, син дә әйт әле?

Шәкерт: Әлхәмдү...

Мөгаллим: Яле, барыбыз бердән әйтик: «Әлхәмдүлилләәһи раббил-галәмииииин».

Менә һәрбер эш соңында, ашап бетергәч, укып бетергәч, йоклап торгач, юынгач: «Әлхәмдүлилләәһи...», – дип әйтергә кирәк. Ягез әле, шәкертләр, бердән әйтик: «Әлхәмдүлилләәһи...»

Шәкертләр: «Әлхәмдүлилләәһи раббил-галәмииииин».

Текстны басмага ***Мәдинә Әбделганиева*** *әзерләде.* ■

МӨҺАҖИРЛЕКТӘГЕ ТАТАР КИТАБЫ

Бөек шагыйребез Котб әсәренең Истанбул басмасы (1968)

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы





ilāhi tevfıkıng kapġın aça bir
köngülge rahmeting urġın saça bir
köngül bir kim yakınıngġa yarasun
adın ġaflet bu könglümdin yırasun
bu könglüm közgüsin şaykal kılu bir
kamuġ müşkillerimni hal kılu bir
içimni öz nurung birle yarutġıl
tilimni öz senang özre yüritgil
dāvūd yanglıġ bu könglüm tāze kılġıl
zebūrumnı bedük āvāze kılġıl
bu söz kim başladım hoş kilsü cānġa
mübārek kıl sözüm barça cihānġa
anıng tig kim okıġan dil açılsun
tilimdin müşk ü ʿanberler saçılsun
karası közni toluġ nūr kılsun
işitgen maġzını mahmūr kılsun
maʿānī birle yüksek kıl sözümni
sāʿādet birle bār it bu özümni
köngüllerning müferrih nāmesi kıl
kamuġ müşkil kilidi bolsu bu til
şīrīn kıl şāh közinge söz cemālı
kim uş şīrīn irür söz içre fālı
ʿināyet birle kıl könglümni āgāh
bu söz içre medet kıl kulġa allah
ināyet kim sanga uş kıldı yarı
ni turdung tilge kiltür dilde barı

I

allahu taʿālānıng tevhidin ayur
idi atı birle[1] başla sözüngni
kim ol bar kıldı yokdın bu özüngni
uluġ tengri kim ajunnı yarattı
tutup bik yirni köklerni töretti

[1] Mısranın vezni bozuktur. Veznin düzelmesi için *birle* yerine *bile* olması lâzımdır.

Котб әсәренең Истанбул басмасы һәм бер бите

XIII гасырның 40 нчы елларында төзелеп, ике гасыр дәвамында яшәгән кодрәтле Алтын Урда Евразия тарихында, аның сәяси, иҗтимагый, милли, гыйльми-мәдәни тормышында үз заманында гына түгел, ә аннан соңгы дәвердә дә гаять зур роль уйный. Бу мәмләкәт нигезендә дистәләгән дәүләт, шул исәптән татар ханлыклары төзелү, Алтын Урда турында төрле телләрдә йөзләгән хезмәтләр язылу, сәнгати әсәрләр иҗат ителү – үзләре генә дә күп нәрсә хакында сөйли. Шунысын да искә төшерик: бу дәүләткә мөнәсәбәт, аңа бәя-хөкемнәр дә төрледән-төрле: объектив хезмәтләр белән бергә, тарихи хакыйкатькә хилафлык кылган, тенденциоз, ялган эчтәлекле язмалар да шактый. Соңгылары аеруча Рәсәй елъязмаларында, урыс телле басмаларда өстенлек итә.

Мәгълүм ки, яңа эрага кадәр меңеллар элек үк тарих мәйданына чыккан татар кавеме Азия, бераздан Аурупа кыйтгалары тарихында, аеруча этник процесс-та тирән эз калдыра. Ерак Шәрык, Себер, Һиндстан, Үзәк Азиядән алып Балкан, Венгриягә кадәр җәелгән иксез-чиксез җирләрдә элек-электән үк әлеге атамалы исем-топонимнарның булуы, биредәге халыкларның телләрендә татар белән бәйләнешле сүзләрнең очравы күпләргә билгеле. [Болар хакында, мәсәлән, Нурмөхәммәд Хөсәеновның (7-13 май, 2021 ел. – №16-17) «Звезда Поволжья» газетасында басылган «Афганские татары» исемле мәкаләләр сериясендә дә шактый гына факт-мәгълүматлар китерелә.] Дистәләгән халыкларның оешуында татар кавеменең катнашы бар. Бу аеруча төркиләрнең этник тарихында көчле. Мәгълүм ки, күп кенә чыганакларда, гыйльми хезмәтләрдә хәзәр, болгар, кыпчак, угыз, карлук, кимәк, искил һәм кайбер башка кавемнәрнең борынгы татарлар белән этник яктан тыгыз бәйләнештә булуы, хәтта шулар нигезендә оешуы искәртелә. Бишенче гасырда җыйнама исем буларак гамәлгә керә башлаган «төрки» этнонимы бераздан үзенең кулланылыш даирәсен арттыра. Әмма татар атамасы да гамәлдән чыкмый. Чорына, җирлегенә мөнәсәбәттә ул теге яки бу дәрәҗәдә кулланылышын дәвам итә. Чыңгыз һәм аның варислары чорында татар факторы, аның исеме һәм җисеме дә Евразия киңлекләрендә гаять киң таралыш таба, хәлиткеч көчләрнең берсенә әверелә.

Янә бер хакыйкатьне искә төшерү гөнаһ булмас. Алтын Урда чорында һәм җирлегендә (үзәге Идел-Йортта), Идел-Урал төбәкләрендәге болгар, кыпчак, хәзәр, татар һәм кайбер башка этник катламнар һәм төркемнәрнең үзара якынаюы, керешүе нәтиҗәсендә, билгеле бер үзенчәлекләргә, чагыштырмача мөстәкыйльлеккә ия булган зур бер этник-тарихи бөтенлек – хәзерге татарларның турыдан-туры әби-бабалары оеша. Соңгы дәвер татар язма һәм сөйләм теленең, сүз сәнгатенең, мәдәниятенең нигезендә Алтын Урда чоры һәм җирлегендәге рухи кыйммәтләрнең ятуы реаль хакыйкать. Әмма, ни кызганыч, шушы чынбарлыкны күрергә һәм танырга теләмәү инде шактый еллар буе тарихта күзәтелеп килә. Берәүләр бүгенге татарны Урта гасырлардагы болгарлар белән тәңгәлләштерүен һаман дәвам итә. Икенчеләре Ауразия киңлекләрендә яшәгән әби-бабаларыбызны Казан белән генә бәйләнештә карарга тырыша. Өченчеләре XIV гасырның тәүге чирекләрендә үк оешкан татар атамалы, телле халыкны «кыпчак», «коман», «угыз» һәм кайбер башка шундый этник төркемнәргә таркатуын дәвам итә. «Төрекчелек» («төркичелек») атамасы да шактый тирән тамырлы.

Билгеле ки, империя тоткан халыклар үз телләрен, диннәрен, гореф-гадәтләрен, этник-мәдәни кыйммәтләрен ил составындагы башка кавемнәргә дә тарату, этник берлеккә ирешү юнәлешендә дәвамлы һәм эзлекле сәясәт уздырып киләләр. Рәсәй һәм Төркия империяләре – моның гыйбрәтле дәлиле. Истанбул өчен, мәсәлән, үз иле эчендәге кавемнәр генә түгел, ә Ауразиянең зур киңлекләрендә элек-электән гомер кичергән күп кенә кардәш халыклар да «төрек». Шуңа нисбәттән ул аларның этник үзатамаларын да соңгы елларга кадәр юньләп танымады. Татар атамасы урынына ул «Казан төреге», «Төньяк төреге», «Идел-Урал төреге» кебек исемнәргә өстенлек биреп килде. Шунысы гаҗәп: бу агымга соңгы гасырларда Төркиягә күчеп киткән күп кенә зыялыларыбыз да кушылып китте. Болар арасында Садрый Максуди, Йосыф Акчура, Габделбарый Баттал, Рәшит Рәхмәти Арат, Әкъдәс Нигъмәт Курат һәм кайбер

башка мәшһүр милләттәшләребез дә бар. Бары Гаяз Исхакый, Әхмәд Ләбиб Каран кебек аерым затлар гына татар атамасына тугры калдылар, аны саклау, гамәлдә куллану өчен фидакярләрчә көрәштеләр.

Мәгълүм булганча, урта гасыр татар тарихын, әдәби мирасын, шул исәптән Алтын Урда язма истәлекләрен өйрәнүдә, бастыруда, халыкка кабат кайтаруда Төркия зур эшләр башкарып килә. Мәсәлән, Мәхмүд Болгариның «Нәһҗелфәрадис» (1358), Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» (1391) ядкярләренең тәүге басмалары, аларга багышланган җитди гыйльми тикшерүләр Төркиядә дөнья күрде. Без моның өчен бу ил галимнәренә рәхмәтле. Әмма ул басмаларда әлеге төр ядкярләр укучыларга һич тә татар язма истәлекләре дип түгел, ә төрек, кыпчак… телле әсәрләр рәвешендә тәкъдим ителә. Моңа еш кына безнең соңгы чор татар, Казан, Уфа, Мәскәү галимнәре дә кушылып китә.

Борынгы рун һәм уйгыр язулы истәлекләргә, Йосыф Баласагуниның мәшһүр «Кутадгу билик» ядкяренә, Әхмәд Ясәвинең дини-суфыйчыл шигырьләренә, Кол Галинең атаклы «Кыйссаи Йосыф» дастанына, халык авыз иҗатына һәм мифологиясенә нигезләнгән Алтын Урда чоры татар әдәбияты, Шәрык, аеруча фарсы рухи казанышларын мул һәм иҗади файдаланып, XIV гасырда гаять зур уңышларга ирешә. Кызганыч, бу дәвернең бик аз санлы әсәрләре генә безнең чорга билгеле. Әмма булган кадәресе дә Җучи Олысы сүз сәнгатенең идея-эстетик байлыгын, әдәби яктан камиллеген күрсәтеп тора. Рабгузыйның «Кыйссасел-әнбия» (1310), Харәзминең «Мәхәббәтнамә» (1353), Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис»(1358), Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» (1369), Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки» (1391) һәм «Сөһәйл вә Гөлдерсен» (1394) ядкярләре аерым-аерым да теләсә нинди милли әдәбиятны бизәп, югары күтәреп торырлык. Болар арасында Котбның мәгълүм «Хөсрәү вә Ширин» атлы шигъри роман-дастаны (1342) бик тә мөһим урынны били. Ул еш кына шигъри тел-стильнең, синкретик табигатьле әдәбиятның бер өлгесе итеп карала. Низаминың фарсы телендәге китабына таянып иҗат ителгән бу ядкяр татар-Шәрык әдәби бәйләнешләрен өйрәнүдә дә бәһаләп бетергесез бер чыганак.

Котб һәм аның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре хәзерге укучыларга шактый мәгълүм. Аның хакында күпләгән мәкалә-хезмәтләр, шул исәптән без фәкыйрегезнең дә махсус монографиясе (1976), төрле журнал-җыентыкларда, шулай ук академик басмаларда [8 томлык «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томында (2014)…] дөнья күргән язмалар бар. Котб әсәрен өйрәнүдә, халыкка кайтаруда татар галимнәреннән Габдрахман Таһирҗанов, Хатип Госман һәм Әмир Нәҗипләрнең эшчәнлекләре аеруча хуплауга лаек.

Бу шагыйрь хәзерге фәндә 1297 нче елларда туган дип карала. Аның кече ватаны Урта Иделнең уң ягына – хәзерге Пенза, Мордовия төбәкләренә нисбәт ителә. Гомеренең төп өлешен Алтын Урда башкаласы Сарайда уздыра. XIV гасыр урталарында шунда ук вафат булган дигән фикер дә яши. «Котб» – шагыйрьнең кушамат-тәхәллүсе. Аны Урта Иделдәге «Котоба» шәһәре һәм халык телендәге «Котб» (остаз, акыл иясе) сүзе белән бәйләп караучылар да бар.

«Хөсрәү вә Ширин»нең автор кулы белән язылган нөсхәсе хәзергә билгеле түгел. Ул 1383 елда Мисырда Бәркә Фәкыйһ исемле кеше тарафыннан төзелгән күчермәдә килеп җиткән. Бу зат чыгышы белән Идел-Йорттан. «Хөсрәү вә Ширин»нең 238 битлек әлеге нөсхәсе бераз соңрак нindидер юллар белән Франциягә барып эләгә һәм хәзерге вакытта Париж Милли китапханәсендә сак-

лана. Фәнгә ул, нигездә, XX гасырның икенче чирегендә генә мәгълүм булды. Котб әсәре тәүге мәртәбә узган йөзнең 50 нче елларында Варшавада Польша галиме (милләте белән – караим) А.Зайончковский тарафыннан нәшер ителде. Ул фотокүчермәдә һәм латинча транслитерациядә бирелгән. Сүзлеге дә бар.

«Хөсрәү вә Ширин»нең Казан, Ташкент һәм кайбер башка басмалары да билгеле. 1969 елда Казанда нәшер ителгән басмасы гарәп язуында. Ул Х.Госман һәм З.Максудова тарафыннан әзерләнгән. 2003 елда Котб романы хәзерге татар телендә Р.Әхмәтҗанов тәрҗемәсендә дә нәшер ителде. (Аның фәнни мөхәррире һәм күләмле генә кереш мәкалә авторы – Х.Миңнегулов.)

Алдарак әйткәнебезчә, «Хөсрәү вә Ширин»гә мөнәсәбәтле шактый гына мәкалә-хезмәтләр бар. Алар һәм әсәрнең үзе төрле төбәкләрдә, төрле елларда нәшер ителгән. Болар арасында бигрәк тә А.Зайончковский, Г.Таһирҗанов, Х.Госман, Ә.Нәҗип һәм Э.Фазилов язмалары, басмалары еш телгә алына. Әмма Котбка нисбәтле бер мөһим китап, ничектер, игътибардан читтәрәк кала килә. Аның исеме, гомумән, татар гуманитар фәнендә, Рәсәй тюркологиясендә бик күзгә ташланмый. (Бәлкем, без фәкыйрегез генә күрми, очратмый торгандыр?) Истанбул университетында әзерләнеп, 1968 елда дөнья күргән бу хезмәтнең титул битендә мондый язулар бар: *«Kutb'un Husrev ü Şîrin'i ve dil hususiyetleri Dr. M' Necmettin Hacıeminoğlu. – Edebiyat Fakültesi Matbaası, 1968»*. «Котбның «Хөсрәү вә Ширин» һәм аның тел ...аятьләре» дип исемләнгән төрек телендәге бу китап шактый күләмле [VI-XII, 477 битләрдән гыйбарәт (483 б.)]. Гәрчә Котб иҗаты белән 70 нче елларда шөгыльләнә башласам да, 1968 елгы Төркия басмасы безнең хезмәтләрдә дә телгә алынмый. Моның үзенә күрә аерым сәбәпләре дә бар. Ул узган гасыр ахырларына кадәр бик билгеле түгел иде. Төгәл хәтерләмим: М.Нәҗмеддин Хаҗиминоглу әзерләп чыгарган Котб турындагы бу хезмәт 90 нчы еллардагы Финляндиягә һәм Төркиягә сәфәрләремнең берсендә ниндидер юллар белән кулыма кергән иде. Казанга кайту белән мин бер мәзәк хәлгә тарыдым: китап «югалды». Эзлим-эзлим – юк та юк. Бер гаепсезгә аерым хезмәттәш-коллегаларымнан да шикләндем: «Әллә алып торып кире кайтармадылармы икән?..» – кебек уй да күңелне тырнап йөрде. Шушы (ягъни 2021) елның башларында шәхси китапханәмдәге басмаларны һәм кулъязмаларны барлап утырганда, бер папка эченнән Котбның 1968 елгы Төркия басмасы килеп чыкмасынмы! Куанычлы да, шул ук вакытта шактый үкенечле дә хисләр кичердем.

Бу хезмәт Казан китапханәләрендә күзгә ташланмый: гавам файдалансын дип мин аны [Сәйф Сараиның Андраш Бодроглигети (Будапешт, 1969), Али Фәһми Караманлоглу (Анкара, 1989), Эргаш Фозилов (Ташкент, 1968) басмалары белән берлектә] Татарстан Милли китапханәсенә бүләк итәргә җыенам (мин инде бу китапханәгә, КФУ һәм Татарстан Фәннәр академиясенә, Болгар академиясенә моңа кадәр дә күп кенә китап-кулъязмалар, аеруча мөһаҗирлектәге татар басмаларын тапшырган идем). Кызыксынган кешеләр җентекле танышыр, өйрәнер, файдаланыр. Биредә исә Хатыйп Йосыф углы 1968 елгы Төркия басмасы хакында кыскача гына аерым мәгълүматлар бирергә, гомуми күзәтү ясарга гына ниятли.

Котбның («Kutub»ның) 1968 елгы Истанбул басмасы аны әзерләүченең кечерәк кенә кереш сүзе (Önsöze – кереше) (VI-XII б.) белән башланып китә. Анда автор бу әсәрнең «төрек теле ядкярләре арасында мөһим урын алуын», А.Зайончковскийның күпкырлы эшчәнлеген уңай бәяли, үзенең асыл максат-

ларын әйтә. М.Нәҗмеддин – чыгышы белән Идел-йорттан булган, Кызылъярда (Петропавловскида) укыган, аннан Кытайда татар газета-журналларында эшләгән, бераздан Берлин университетында белем алган, гомеренең зур өлешен Төркиядә уздырган мәшһүр милләттәшебез тюрколог Рәшит Рәхмәти Аратның (1900-1964) шәкерте. (Бу да шактый мәгънәле!) Кереш сүзендә ул үз «хуҗа»сына тирән рәхмәт хисләрен белдерә.

Китапны басмага әзерләүче әлеге әсәрнең төрекчәгә тәүге тәрҗемә икәнлеген искә төшерә, оригинал белән ике арадагы уртак һәм кайбер аермалыкларны да телгә ала. Аның фикеренчә, Низаминың фарсы телендәге «Хөсрәү вә Ширин» дастаны 5700 бәеттән-икеюллыктан гыйбарәт. Котбта исә ул – 4370 (1300гә кимрәк). Ике текст арасындагы үзгәлекләрнең шактые керешбагышлау өлешендә. Мәгълүм ки, Котб үз әсәрен Алтын Урда ханы Тенибәккә һәм аның хатыны Мәликә бикәгә багышлый. Кереш сүздә бу хакта да бераз мәгълүмат бирелә. Фәнни әдәбиятта «Хөсрәү вә Ширин» кульязмасында вәзен һәм тел-стиль ягыннан аерым кимчелекләр – бәхәсле яклар очравы искәртелә. Әлеге мәсьәлә Төркия басмасының тәүге өлешендә дә кузгатыла. М.Нәҗмеддин фикеренчә, андый җитешсезлекләр йә Бәркә Фәкыйһнеке, яисә ул нигез итеп алган нөсхә белән бәйле. Китапны күчерүченең автограф белән түгел, ә копия-күчермә белән эш итүе дә бик ихтимал. «Кереш» мәкаләдә кайбер башка фикер-күзәтүләр дә бар. Китапның ахырында махсус «Библиография» дә бирелә (461-466 б.). Анда Котб әсәренә теге яки бу дәрәҗәдә мөнәсәбәте булган төрле телләрдәге шактый гына хезмәтләр, шул исәптән сүзлекләр дә күрсәтелә. Болар арасында В.Радлов, А.Кононов, А.Зайончковский, Р.Рәхмәти Арат, Т.Ковальский, Ф.Күприлезадә, Ф.Тимурташ, Э.Экман, А.Инан һәм кайбер башка тюрколог галимнәрнең китаплары һәм язмалары бар.

Китапның 1-178 битләрен «Dil Hususiyetleri», ягъни әсәрнең тел үзенчәлекләрен тикшерү алып тора. Хезмәт авторы үз алдына куйган төп бурыч – проблемага комплекслы якын килә, ягъни Котб романының тел хосусиятләрен лингвистика фәнендәге күп тармаклар, аспектлар аркылы яктырта. Биредә без фонетик, морфологик, синтаксик, стилистик сүз төркемнәре, җөмлә кисәкләре һәм кайбер башка мәсьәләләргә багышланган махсус бүлекбүлекчәләр белән очрашабыз («Jzmla hususiyetersl», «Ses» (аваз)... «Jsim...», «Sifat», «Edat» (бәйлек)... «Fiil»... [исем фигыль, шарт фигыль) һ.б.]. Әсәрнең телгә янә кагылышлы һәр очрак, һәр мәсьәлә конкрет мисалларга таянып тикшерелә. Төрек галименең бу юнәлештә гаять җентекле эш итүе хәтта сокландырырлык. Ул әсәрдән алган күпсанлы мисалларның конкрет бәйт (икеюллык) саннарын да күрсәтеп бара, тел күренешләрен шәрехләп, сүз-гыйбарәләргә шактый тәфсилле аңлатмалар бирә, урыны белән башка чыганак-әсәрләргә дә мөрәҗәгать итеп, теге яки бу дәрәҗәдә чагыштырма тикшерү ысулын да файдалана. Без фәкыйрегез тел белгече түгел, шуңа күрә хезмәт авторының Котб әсәрендәге тел хосусиятләрен тикшергән бу язмаларына фәнни-тәнкыйди бәя-хөкем бирүне әлеге тармакның махсус белгечләренә калдырам. Гомумән исә, 1968 нче монографиянең Котб әсәренең тел хосусиятләрен тикшерү нәтиҗәләре миндә уңай тәэсир калдырды.

Ахыры киләсе санда ■

ШАГЫЙРӘ САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВАНЫҢ ТУУЫНА 95 ЕЛ

Югалган дәфтәр

Саҗидә Сөләйманова

Саҗидәгә 16 яшь. Югары Тәтешле. 1942 ел

Балачакта, яшьлектә кемнәр генә шигырь язмаган. Мин 3 нче сыйныфта яза башладым. Ул шигырьләр язгы тамчылар, кар таулары, әнкәй һәм, әлбәттә, Ленин турында иде. Аларны берәүгә дә күрсәтмәдем. Ә олыгая төшкәч (7 нче сыйныфта), «проза»га күчтем. Үзебезнең яшьтәшләр турында пьеса язып карадым, чөнки балалар пьесалары аз иде. Ә мәктәп драмтүгәрәге бик актив эшли. Аптырагач, зурлар өчен язылганнарын куеп йөрдек.

Мәктәптә әдәби журнал чыгара идек. Анда бер хикәям басылды. Аннары... сугыш башланды. Халыкка килгән олы кайгы безне дә читләтеп узмады. Язу хыялы чигенде.

10 нчы сыйныфтан соң авыл мәктәбендә укыту. Уфа педагогия институтында уку. Тагын урта мәктәп коллективы (Аскар урта мәктәбе). Баштанаяк нагрузка. Минзәләдә дә шул ук хәл. Бала язмышы бит укытучыга бәйле. Гел шулар турында уйлыйсың, төшеңдә дә шулар белән саташасың. Башка чит нәрсә белән мавыгуны хәтта хыянәткә саныйсың. Кая анда шигырь язу турында уйлау.

***

...Еш кына «Ничек яза башладыгыз?» дигән сорау бирәләр. Менә бу юлы съездга баргач та, бер әфәнде шул сорауны бирде: «Язучыларның хатыннары яза башлый: Рәйсә Ишморатова, Гөлшаһидә, менә Сез. Ничек була ул алай?» Мин ничегрәк җавап бирергә, дөрес тә булсын, шаяру да булсын дип уйларга да өлгермәдем, әлеге мәҗлестә булган Миргазиян Юныс минем урынга җавап бирде: «Гаилә тормышы шундый нәрсә ул, монда шигырь язу гына түгел, әллә нәрсә эшли башларсың». Акыллы кеше әллә каян билгеле!

Әдип Маликов һәм Саҗидә Сөләйманова. 28 декабрь, 1951 ел

***

...Мин беркайчан да профессиональ язучы була алмадым, гомерем буе эшләдем. Язучы тормышны читтән күзәтеп торучы түгел. Ул аның эчендә кайнап яшәргә тиеш. Бу – минем иманым. Мин шуңа инанып яшим.

Төннәрен, бик соңга калып, кичке нефть техникумыннан эштән кайтканда һәм партия шәһәр комитеты лекторы чагымда иртәнге дүрттән вахта машинасы белән промыселларга чыгып киткәндә, үземә бер ачыш ясадым: шәһәр беркайчан да йокламый икән. Яңа төзелеш утлары, җем-җем итеп, күз кысыша. Кешеләр төнге сменага ашыга. Ышанычлы, салмак бер ритм белән буровойлар гөрли. Һәм менә шушы тынгысыз хезмәт ритмы үзе җыр сорап тора.

Саҗидә Сөләйманова (уртада) оныгы Гөлнара, каенанасы Рауза (сулда) һәм әнисе Галимә белән. Югары Тәтешле. Август, 1965 ел

***

Ниндидер сәер гадәтем бар: дөнья шаулаткан авторны мин шундук укырга ябышмыйм. Шау-шулар тынгач кына иркенләп укыйм, бу чакта инде миңа беркем дә үз фикерен такмый төсле, хөкемне үзем чыгарам. Хемингуэй белән шулай булды, Межелайтис белән... Һәр икесе алдында да баш иям. Димәк, минем өчен әле дә яңа. Соңгы елларда үзем өчен тагын бер яңа шагыйрь, димәк, яңа дөнья ачтым: Марина Цветаева. Китабы кулга төшкәнгә чаклы минем аның хакында бернәрсә дә укыганым юк иде. Бары ике юлын гына ишеттем:

«Милый не вечен, но вечен Мир.
Не понапрасну служим».

Шуннан эзләп табып укыдым. Фикер һәм хисләр укмаштырган яшен ташы. Вознесенскийлар яңа сыман тоелган иде, алар Цветаеваның артыннан гына кабатлаганнар икән.

Бездә, татарда, хатын-кыз шагыйрьләрне аерым исемлеккә теркәү кагыйдәләшкән. Чын шагыйрьләр рәтендә торырдайлары булмаганмы? Әллә алар хатын-кызга гына тулысынча аңлаешлымы? Ләкин бит хатын-кыз бөтен укучыларның яртысын тәшкил итә. Ә менә Маринаны мин форма һәм фикер бердәмлегенең көче ягыннан хәзерге күп ир шагыйрьләрдән өстен куям.

Яраткан шагыйреңә ирексездән ияргү була торгандыр. Сибгат Хәкимгә дә, Хәсән Туфанга да ияреп алдым бугай. Аз гына. Гомумән, мин иярү ягында түгел.

Нәҗар Нәҗми, Әнгам Атнабаев, Гамил Афзал, Сәвия Атнабаева, Әдип Маликов, Саҗидә Сөләйманова. Уфа. 21 июль, 1973 ел

***

Авырлыклар күрдем, дип әйтә алмыйм. Булганнары, вакытлыча булгандай, үтә шикелле тоелды. Әткәй тәэсире, аның халык арасындагы абруе һәрвакыт янәшә булгандыр, каршылыкларны җиңелрәк үтәргә ярдәм иткәндер.

С.Сөләйманова гомеренең соңгы елларын үткәргән йорт бинасы диварына (Әлмәт, Ленин урамы, 24 нче йорт) эленгән беренче мемориаль такта

Үткәннәр бездән корбан сорамый,
хәрабәме, коралмы –
ядь итеп, кеше баш ия.

Киләчәк алдында без –
аягүрә.
Ул бездән сабак ала,
бәя бирә.
Саҗидә Сөләйманова

Шагыйрь **Мөдәррис Әгъләмов:** *«Шигърияттә хатын-кыз шагыйрәләр күбәйгән саен, Саҗидә Сөләйманова иҗаты киңрәк күренә, биеккәрәк күтәрелә бара. Кызларыбыз шигъри ачышларга игътибарлы булмасалар, беркайчан да үзләре теләгән биеклеккә ирешә алмаслар дип борчылам мин»,* – дигән иде. Саҗидә Сөләйманова биеклеген ул ир-ат шагыйрьләр дә әйтергә курыккан чынлыкны әйтә белүдә күрде: *«Саҗидә апа шигърияткә соң килде, олыгаеп, эченнән әрнеп, янып... Өлгергән, шигъри образлар белән тәмам тулышкан иде инде ул. Жиде-сигез ел эчендә шуңарчы исеме дә билгесез шагыйрә баш әйләндерерлек биеклеккә күтәрелде, ир-ат шагыйрьләр өйрәнерлек, Туфаннар хөрмәт итәрлек Шагыйрь булып җитеште. Әгәр Ходай аңа Анна Ахматова гомерен биргән булса, без аңа үлгәнче үк һәйкәл куярга тиеш булыр идек».*

Шагыйрь **Зөлфәт** исә: *«Саҗидә апа бик кыска вакытта балкып очып үткән йолдыз булды. Аның шигырьләрен беренче укыганда ук андагы фаҗигале фәлсәфи хисләрнең тирәнлегенә, чисталыгына исләрем китә иде минем. Шул шигырь юллары артында ниндидер бер фаҗига җиле исеп тора кебек тоела иде. Ул чын мәгънәсендә мастер иде. Чын мәгънәсендә! Саҗидә апа бик күп шагыйрьләр ирешә алмаган биеклеккә күтәрелде поэзиядә. Укып карасаң, аның шигырьдәге һәр юлы көтелмәгән... Син аның киләсе юлда нәрсә әйтәчәген сизенә алмыйсың. Һәм аның рифмасын да чамалый алмыйсың син. Күп кешенең рифмасын чамалап була, ә Саҗидә апаныкын юк! Менә бу чын мәгънәсендә оста... Мастер!»* – дип язды.

Мин туганчук яңа йолдыз туган,
Женьшень үскән, көмеш табылган.
Миннән башка көзге бер яфракка
Кимрәк булыр иде табигать.

Урманнарда ялгыз гына йөрсәң,
Шул яфракны танып өз әле, –
Язмыш дәфтәрендә балкып калыр
Бөек рәссам Кояш безгә.
Сажидә Сөләйманова

Сажидә сеңлесе Мәдәния, энеләре Ренат һәм Фәнис белән. 1936 нчы еллар

Сажидәнең бала чагында, җиләккә барган җиреннән адашып, урманда төн кунган чаклары да була бит. Йөгерә-ашыга җиләк җыю белән шулкадәр мавыгып китә ул, караңгы төшкәнен дә сизми кала... Кайтырга дип җыена башлый, анда сугыла, монда сугыла... Килгән юлын таба алмый йөдәп бетә. Шулай да җаен таба – агач башына үрмәләп менеп, шунда төн үткәрә. Иртән өйгә үзе юл табып кайтып керә тагын...

...Сугыш елларында колхозлардагы авыр кыр эшләре ундүрт-унбиш яшьлек балалар өстенә төшә. «Кырда безне яңа чыгып килә торган кояш каршы ала, басудан кайтып киткәнне кояш күрмәскә тиеш», – дип яза ул соңрак.

Материалны журналга, «Сажидә Сөләйманова: шигъриятнең күкчәчәге» дигән китаптагы (авторлары – Әдип һәм Әнвәр Маликовлар, мөхәррире – Фәйрүзә Мөслимова. – «Рухият», 2016. – 351 б.) язмаларга нигезләнеп, ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

«Кешеләрне кызганам...»

(Кесә дәфтәреннән)

....

Адлер Тимергалин*

Кешеләр белән

Гади кешеләр белән контактны бик җиңел урнаштыра идем. Хәзер кыенрак...

Белмим, нигәдер, барча бәхетсезләр, кәефсезләр миңа килеп зарларын сөйләрләр иде. Бала-чага да, йомшаклыгымны бик тиз сизеп алып, сыртка менеп атланырга гына тора, ләкин, гомумән, ихтирам итә, хәтта ярсыта иде. Хәтта бер укыткан баламнан (кыз бала) соңыннан гына белдем: мин «сөйгән укытучылары» булганмын икән (авыл мәктәпләрендә физика, математика, химия һәм хәтта урыс телләре укытканым бар).

Адлер Тимергалин (уңда) һәм Марсель Галиев.
Фото Марсель Галиев архивыннан алынды.

Кешеләрне кызганам. Бик еш гафу итәм. Кайбер «дуңгызлар» моннан файдаланалар да. Туры әйтергә яратсам да, кеше күңеленә артык бәрелмәскә тырышам бугай.

Халык арасына чумып, күренмичә йөрүне артык күрәм шикелле. Мин «серая» масса эчендә...

Язучылар союзы

Союзга кермичә (гариза бирмичә) йөрүемнең сәбәпләре бар.

Беренчедән, мин Союзны изге җир дип күз алдыма китерәм. Аңа элек-электән ихтирамым зур. Союзда әллә ниткән шулерлар барлыгын белә торып шулай уйлыйм. Үземне изгеләрдән санамагач, Союзга бик ашыкмадым.

Икенчедән, кабул итүләренә дә ышанычым барлы-юклы иде. Биографиям тәти түгел бит. Ә XX съезд ерак калды...

Өченчедән, үземнең өлгереп җитүемне генә түгел, өлкәнрәк агайларның, теге яки бу атмосфера тудыра (яки сасыта) торган кешеләрнең дә өлгереп җитүен көттем. Бераз соңгарак та калдым бугай...

Алла бирсә, мин Союзга файда китерермен әле.

---

* Язучы-прозаик, фантаст, мәдәният тарихы белгече, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1981), Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты (2006). Адлер Тимергалин 1931 елның 1 гыйнварында Татарстанның Сарман районындагы Иске Минзәләбаш авылында туган. 2013 елның 16 гыйнварында вафат булды.

Киләчәк турында

Кешелек цивилизациясенең киләчәге турында уйлаганда, оптимистик нәтиҗәләрдән бигрәк, пессимистик фикерләргә киленә. Ләкин мин бер-бер юл бардыр дип һаман уйланам – оптимизм шулдыр, күрәсең.

Галимнәр аңлы тереклекнең гомере чикләнгән дип уйлый (күпчелек галимнәр). Аңлы тереклек үзен-үзе һәлак итүгә (үзе теләп) барып җитәчәк дигән фикер дә бар. Һәрхәлдә, без белгән галәмнең дә «гомере» чикләнгән: кояшлар сүнә, картая һәм, димәк, тереклек өчен энергия чыганагы да калмый.

Мәңгелек булыйм, дисә, кешелек дөньясы өчен бердәнбер юл (максат) – Алла кодрәтенә ирешү, Алла булу дәрәҗәсенә җитү. Галәмнәр, йолдызлар белән идарә итү...

***

1. Сюжет кору осталыгына инглиз-америка фантастларыннан өйрәнергә кирәк дип саныйм.
2. Фантаст язучыга күп укырга кирәк. Кичәге нәрсә бүген инде яңа түгел. Төп чыганакларны укырга кирәк, чөнки куян шулпасының шулпасын болай да укыйлар, телевизордан күрәләр, ишетеп беләләр.
3. Фантаст күпкырлы булырга тиеш. Әйтик, физик та, лирик та. Югыйсә ул чат сәнгать әсәре тудыра алмый.

***

Рус фантасты, «Андромеда томанлыгы»ның авторы И.Ефремов киләчәктә әдәбиятны нигездә фантастик булачак дип санавын әйткән иде. Минемчә, бик ихтимал бу. Реалистик әдәбиятка да сюжет, типлар һ.б. чик куя. Бик күп әсәрләр бер-берсен кабатлыйлар түгелме? Ә киләчәктә кабатлауга чик куелачак. Димәк, әдипләр хыялый игътибарны жанрга юнәлтерләр... Ә хыялның чиге бармы? Бу хыял тормышка ашкач та, икенчесе, өченчесе туып тормыймыни?! Әгәр шулай булмаса, яшәүнең (кешелек яшәешенең) мәгънәсе дә юк, минемчә.

Марсель Галиев

Санлый заман, сынап-сынап

Адлер Тимергалинга

Исәнбәтләр исәптә юк, димә,
Әллә каян калка кыюлар.
Кыю җанны сугарырга диеп,
Тибеп чыга изге коелар.

Инде бетте дигән чакта, кинәт
Халкым бирә шундый улларын, –
Аягүрә басып кешнәп куя
Йокымсырап яткан тулпарың.

Энә белән кое казый алган
Фидакярләр сирәк туганын
Онытма син, заман, санлый белеп,
Адлер атлы шаһи зат барын.

*Язмаларны журналга **Алсу Тимергалина** һәм **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №10 октябрь 2021

Әби биргән сабак

Мөдәррис Әгъләмов



Мөдәррис Әгъләмов. 1966 ел

Минем әби – Хәдичә карчык – әтинең әнисе 102 яшенә кадәр яшәде. Минем исәпләвемчә, ул 1852 елгы булырга мөмкин. Рәсәйдә крепостнойлык 1862 елда бетерелгән. Әби ул чакта 8-10 яшьлек үсмер кыз булып, моны бик яхшы хәтерли иде.

– Кяферләргә слабуда (ирек) биргән елны без Федот боярына урак урдык. Көлтә куйдык. Урысларның бер дә иреклебуласы килмәде. Алар, азат итмәвен сорап, хуҗалары алдында тезләнеп ялындылар. Урыска ирек төс түгел. Бабай әйтәдер иде: «Алар «Пугач явы»на да кушылмады. Җаек казаклары безнең белән иде, Пугач үзе дә казак бит», – дип. Көз җиткәч, Федот боярына эш хакы сорарга бардык. Мин яшь әле, ияреп кенә йөрим. Җирләр туңдырып, кар төшәм-төшәм дип торган кырпак, җүн чак иде. Ул елларда Кадер, Әхмәт авыллары аша тау эргәләп буалар, тегермәннәр тезелеп киткән. Ямь-яшел таулар өстеннән толым-толым җылкы көтүләре җылкылдап тора. Ул буалардагы каз-үрдәк. Күбекләнеп-күбекләнеп тора. Бояр үзе юк иде, управы гына. Безне таныш марҗа кызлары сырып алды. Хуҗаларын Питердә, диделәр. Башкалага кышларга киткән, имеш. Управлары шушы казларны берүзе чалачак икән. Без аһ иттек. Димәк, көтеп тору файдасыз. Без бит мөселманча уйлыйбыз. Безнең хуҗалыкта 40-50 каз-үрдәкне чалу да олы бер эш. Менә управ чыкты. Җиңен сызганган кызыл күлмәктән, кап-кара шалавардан. Кулында балта. Өстәл кадәр бүкән янына кызлар казны ташып кына торалар – бу башларын чабып тора. Өелде, өелде… баш тавы. Тау кырмыска оясы шикелле мыж килеп тора. Аны көрәк белән талдан үрелгән сап-сары кәрҗиннәргә тутырып, эт абзарына ташыйлар. Боярның бер кечкенә генә авылның сарык көтүе кадәр эт көтүе бар иде. Марҗа кызлары безне күәс суы белән сыйладылар. Бераз балга да охшаган. Башлар әйләнеп китә. Татарчалы-урысчалы тәтелдибез генә. Хәзер генә ул урыс татарча белми. Элек бездә барсы да белә иде.

Безгә эшләгәнебез өчен бакыр, көмеш тәңкәләр бирделәр, берәр башъяулыгы өләштеләр. Управ берәр уч кәнфит-перәннек өләште. Татарча: «Яхшы ушладың, рахмат!» – диде. Без көлештек. Безнең эшебезне мактады, янәсе. Без тезләнеп дога укып, амин тоттык. Марҗа кызлары чукына-чукына баш иделәр. Без әнә шулай яши идек. Хәзер инде андагы эт абзарында детдум (балалар йорты), чиркәүләрендә сөт

заводы. Таулар шәп-шәрә, көтүләр дә юк. Тирә-яктан кымыз эчәргә агылган халык та юк. Буалар беткәч, су да юк. Их, гомерләр!

Әби – Хәдичә карчык әнә шулай сөйли иде. Мин, Чаллы-Зәй юлыннан Федотка төшеп, әбием ялантәпи йөргән Кадер һәм Әхмәт аша, кулларны артка куеп, җәяү атларга яратам.

Хыялым үзем белән бергә атлый. Хәзерге техника белән буалар ясау – бер көнлек эш. Тауны, тау читләрен, яр буйларын агачлар белән каплатасың. Көтү-көтү җылкы җибәрәсең. Канатлы тегермәннәр, су тегермәннәре куеп, кымыз санаторие ачып җибәрәсең. Дөньяның кайсы гына почмакларыннан килмәсләр иде бирегә. Әхмәт авылын чыгып, Шыкмайга борылам. Хәзер, ни өчендер, Куш-Елга дип атыйлар икән. Адымнарым мине Түбән Бишкә илтә. Урта мәктәпле, хастаханәле, мин бала чакта үз аптекасы да бар иде әле, сельполы, тирә-якка атаклы базарлы авыл. Ул базарда азмы ишек чыптасы саттым. Минем өчен иң кадерлесе гаять бай китапханәсе иде. Купец йортының икенче катында. Бүгенге күзлектән карасаң, бик тә шыксыз булгандыр ул, ә минем өчен хан сарае иде, билләһи. Бу изге йорт миңа шәхес культы корбаннары булган Кәрим Тинчурин, Хәсән Туфан кебекләрне, кара елларда тыелган Шәехзадә Бабичларны алып килде. Рус теле аша дөнья әдәбиятын алып килде. Рәхмәт бу изге йортка.

Сүзем әби турында иде бит. Һәр атнаның атнакичендә мин Түбән Бишкә китапханәгә төшәм. Авылга килеп кереп, берничә йорт үтү белән, керәшеннәрнең ак таштан куелган чәчәүнәсе тора. Бу сүз урысның часовнясыннан алынган булырга тиеш. Мин аны һәрвакыт, әби кушканча, әйләнеп узам. Ә менә кайтканда, нинди шайтан котырткандыр, әйләнеп уза алмадым. Шулкадәр матур бизәлгән иде бу чәчәүнә... Андагы чүпләм сөлге. Шул чүпләм сөлге астындагы ялтыр-йолтыр килгән тиенле тәңкәләр, кәнфит-перәннекләр. Мин, 7-8 яшьлек малай, шул сөлгене тартып ал да, һәммәсен бергә төр дә... ычкын авылга. Янып-пешеп өйгә кайтып керүгә, әби каршылады:

– Кочагыңда нәрсә ул?

Әбидән яшерен әйбер юк. Мин, сөенә-сөенә, хәлне сөйләп бирдем. Әби сукмады-кыйнамады. Катты да калды. Әйткән сүзләрен хәзер дә онытмыйм:

– Сине моның өчен Алла сугар, бар хәзер үк илтеп куй! Без бер күк астында, Аллабыз бер! Мәнсез булып, Алласыз үсмә!

– Алар бит керәшеннәр генә, – дип мәмелдәдем мин.

– Телебез бер, Аллабыз бер, бар илтеп куй! Бар! Илтеп куй!

Караңгы иде. Мин, 7-8 яшьлек малай, караңгыда бер чакрымлы ярты авылны, тагын бер чакрымлы авыл арасын үтеп ничек бара алдым икән. Бары бер нәрсәне хәтерлим, бик тә истә калган: ике көн түшәктә авырып яттым.

Әби биргән сабак – гомерлек сабактыр. Әбием дөньядан киткәч, мин динсез тәрбия алдым. Көндәлек мәктәп тәрбиясе. Пионер булдым. Комсомол булдым. Коммунистка барып җитә алмадым. Әбинең дингә булган мөнәсәбәте-сабагы мине аңа алып барып җиткерә алмады.

Менә мин Түбән Биш авылыннан авылыма атлыйм. Караңгыда әбием куып төшергән юлдан атлыйм. Бүген коммунист та түгелмен. Мөселман динендә дә түгелмен, чукынмыйм да. Мин кем?! Кайсы диндә?

Әбием сабак биргән диндә мин. Иман иңдергәннәрне олыла, хөрмәт ит! Бу үзе бер дин! Бу – әбием биргән сабак. Әнә шул чакта гына илем матур, җирем матур булыр. Әнә шул чакта гына туган төбәгемә ямь кайтыр. Яшәүгә тәм кайтыр. ■

Безнең мирас №10 октябрь 2021

Ризван Хәмиднең «Хан кызы» драмасында Сөембикә ханбикә образы



Ризван Хәмид

Казан ханлыгы тарихын үзенең зирәк акылы, ханлыкның бәйсезлеге өчен күрсәткән иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге белән халык хәтерендә гасырлар буе сакланган Казанның соңгы ханбикәсе – мәшһүр тарихи шәхес Сөембикәдән башка күз алдына китереп тә булмыйдыр, мөгаен. Әлеге шәхескә багышлап, ул алып барган сәясәтне яктыртып, ватандаш һәм чит ил язучы-галимнәр, тарихчылар, әдәбият һәм тел белгечләре шактый мәкаләләр бастырып чыгардылар, аерым хезмәтләр яздылар.

Күп кенә тарихи чыганакларда һәм аерым мәкаләләрдә Сөембикәнең бик матур, акыллы, нык характерлы, зур дәүләт белән идарә итәрлек дәрәҗәдә тапкыр, зирәк һәм кешеләр белән игелекле мөнәсәбәттә булуына басым ясала. Рус елъязмаларында да Сөембикәнең чибәр һәм акыллы булуы турында әйтелә. Татар риваятьләрендә («Сөембикә», «Патша хәйләсе» һ.б.), әдәби әсәрләрдә дә ханбикәнең гүзәллеге һәм кешелеклелеге чиксез мактала[1].

[1] Казанская история / Под ред. В.П.Адриановой-Перетц; подгот. текста, вступ. статья и примеч. Г.Н.Моисеевой. – М. – Л.: Изд-во академии наук СССР. – 1954. – С. 99.; Глинка С.Н. Сумбека или падение Казанского царства / С.Н.Глинка. – М., 1806. – С.17.; Херасков М.М. Россиада / М.М.Херасков. – СПб: Тип. Глазунова, 1895. – С. 40.; Атласи Һ.М. Сөенбикә // Себер тарихы. Сөенбикә. Казан ханлыгы (Тарихи әсәрләр) / Һ.М.Атласи. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 139 б.; Нәүрүзхан И.В. Сөембикә: тарихи роман / И.В.Нәүрүзхан. – Чаллы: «Камаз» нәшр., 1992. – 7 б.; Батулла Р. Сөембикә: кыйсса / Р.Батулла. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1992. – 135, 136 б.; Латыйп К. Сөембикәнең яшь чагы: тарихи поэма / К.Латыйп // Мирас. – 2002. – №3. – 47 б.; Рәшит Ә. Мөхәммәдьяр: тарихи поэма / Ә.Рәшит // Мирас. – 1996. – №9. – 58 б.

Р.Батулла «Сөембикә кыйссасы» романында ханбикәне милләтебез азатлыгы, аның бәхетле киләчәге өчен җан атып яшәүче ватанпәрвәр, кешелекле, миһербанлы, батыр шәхес, зирәк акыл иясе итеп сурәтли. Әлеге әсәрдә Сөембикә – «азатлык өчен көрәш билгесе генә түгел, бәлки, әйдәүче байрак билгесе буларак та кабул ителә»[2].

Ризван Хәмид 1990 нчы елларда әлеге тарихи-легендар шәхесне сәхнә биеклегеннән яктыртырга алына. 1995 елда драматургның «Хан кызы»[3] (1993) тарихи драмасы дөнья күрә. Казан ханлыгы һәм Сөембикә турында бу бердәнбер сәхнә әсәре түгел. Әлеге чор һәм ханбикә турында 1900-1918 нче елларда ук пьесалар языла. Аларның беренчесе 1910 елда сәхнәгә куела, аннан Ф.Туйкин тарафыннан 1912 елда янә берсе иҗат ителә[4]. Шул ук елны ул «Шәрыкъ клубы»нда сәхнәләштерелә. Соңрак төрек драматургы Г.Хәйдәр тарафыннан «Шаһгали» пьесасы языла. Әлеге пьеса «Сәйяр» труппасы репертуарына уңышлы гына кереп китә. Күрәбез: мөселманны милли бәйсезлек мәсьәләсе бервакытта да битараф калдырмаган.

Р.Хәмиднең «Хан кызы» драмасында Казан халкы һәм, гомумән, татар халкы тарихында дәһшәтле вакыйгалары, фаҗигале язмышлары белән тирән эз калдырган 1550-1553 нче еллар тасвирлана. «Драматург, тарихи фактларга һәм Казан ханбикәсе Сөембикәнең үлеме турындагы мифларга һәм легендаларга таянып, неомиф иҗат итә»[5]. Әлеге неомифта Казан ханлыгы һәм аның ханбикәсенең аяныч язмышы яктыртыла. Әсәрдән аңлашылганча, төп каршылык ил азатлыгы, аның бердәмлеге һәм халык бәхете өчен көрәштән гыйбарәт.

Әдәби әсәрдә, тарихи чынбарлык, тарихи шәхес образы белән беррәттән, уйлап чыгарылган фактлар һәм образларның да урын алуы табигый. Бу уңайдан пьесада язучының иҗат фантазиясе булган, ханбикә Сөембикәнең «язмышын һәм эшен дәвам итүче» Язгөле образы игътибарга лаек. Шул рәвешчә, драматург, «тарихи фактлар һәм үз иҗат фантазиясе синтезы нәтиҗәсендә, XVI гасыр вакыйгалары фонында Сөембикә ханбикәнең һәм аңа тышкы кыяфәте белән бик тә охшаш төстәшенең якты образларын тудыра»[6].

Пьесада Сөембикә – татар язмышын билгеләүдә идея-фәлсәфи юнәлеш бирүче халыкчан, югары фаҗигале образ, ихтыяр көченә ия көчле шәхес; баласын өзелеп сөюче нечкә күңелле ана да, шул ук вакытта дәүләт эшенә аек акыл белән караучы, ил язмышы өчен хәлиткеч мизгелләрдә үзен тыныч тотарга тырышып, ыгы-зыгы куптармый гына дөрес һәм гадел карарлар кабул итәргә омтылучы кырыс һәм җитди сәяси эшлекле дә. Газиз халкын, илен өзелеп яратучы, милләтенең ачы язмышы, киләчәге өчен чын күңелдән борчылучы, аның иминлеге, бәхете өчен үзен аямыйча көрәшүче, халык ихтирамын казанган тугры милләт анасы да ул.

1552 елда казанлыларның мәскәүлеләргә бирешүләренең төп сәбәбен тарихчы галим И.Таһиров татар элитасында бердәмлек булмауда, җитәкче даирәләрнең татардай батыр һәм сугышта үзен-үзе аямаучы халыкны дошманга каршы оештыра алмауларында күрә[7]. «Казан дәүләтенең җитәкче даирәләре, тәхет тирәсендә

[2] Галимуллин Ф. Сөембикә һәм Каракош шәүләсе / Ф.Галимуллин // Шәһри Казан. – 1993. – 4 сентябрь.
[3] Хәмид Р. Хан кызы: Тарихи драма // Мирас. – 1995. – №1-2. – 102–114 б; №3. – 44-50 б; №4. – 52-61 б; №5. – 59-72 б. Алга таба цитаталар шушы чыганаклардан алыначак.
[4] Рамеева И.Р. Образ Сююмбике в литературе (Эпоха и литературный герой): автореф. дис. … канд.филол. наук / И.Р.Рамеева. – Казань, 2002. – С.16.
[5] Саттарова А.М. Современная татарская драматургия: 1985-2000 гг. (Концепция эпохи и героя): автореф. дис. … канд.филол.наук / А.М.Саттарова. – Казань, 2004. – С.15.
[6] Саттарова А.М. Там же. – С.16.
[7] Таһиров И. Казан-1552: фаҗига һәм киләчәккә өмет (фәнни-популяр мәкалә) / И.Таһиров // Мирас. – 2004. – №6. – 72 б.

тупланган көчләр череп-таркалып, үзара низагка кереп беткән була… Көнчелек, үзара дошманлык шулкадәр көчле була ки, мирзаларның шактый өлеше, үз мәнфәгатьләрен өстенрәк куеп, дошман ягына күчүдән дә баш тартмый»[8], – дип яза ул.

Дуслыкны ныгытыр һәм дошманга каршы көрәштә ярдәм алыр өчен, зирәк акыллы ил башлыгы Кырым, Нугай, Хаҗитархан һәм Себер ханнарына ашыгыч рәвештә илчеләр җибәрә. Тик сатлык шымчылар аркылы ханбикәнең әлеге ниятен алдан белеп өлгергән Явыз Иван ханлыктан чыгу юлларын яптырта, илчеләрнең һәммәсе дә кулга алынып, Мәскәүгә озатыла. Әмма Сөембикә югалып калмый. Ул Казан халкын шундый авыр, киеренке мизгелләрдә, үзара ызгыш-талашларны, ачу-үпкәләрне онытып, «бер тән, бер йодрык» булып берләшеп, дошманга каршы ныклап әзер торырга, Идел йортны дошман керүдән сакларга чакыра. Ханбикәнең халыкка мөрәҗәгате ялкынлы, кайнар, хисләре чик дәрәҗәдә киеренке, югары пафослы, Сөембикәнең һәр сүзендә халык язмышы, аның киләчәге өчен тирән борчылу сизелә. Драматургның Сөембикәне туган илен чиксез яраткан шәхес итеп сурәтләве әлеге образның иҗтимагый-сәяси, әхлакый-этик кыйммәтен тагы да арттыра төшә.

Драмада шагыйрь Мөхәммәдьяр образы ханбикәнең эчке кичерешләрен, рухи дөньясын ачуда, иҗтимагый әһәмияткә ия мәгънәне җиткерүдә зур роль уйный.

Әдәби тәнкыйть тарихи шәхесне әсәрдә кардиналь вакыйгалар, халык тормышы һәм язмышы үзәгендә бирүне таләп итә… Шәхес никадәр генә талантлы, бөек булмасын, ул – үз халкының баласы, вәкиле, аның язмышы халык язмышы белән тыгыз бәйләнгән[9]. Менә ни өчен ханбикәнең фаҗигале язмышы татар милләтенең дә фаҗигасе ул.

Ханбикәнең намуслы йөрәге явыз дошман кулына тоткын булып төшү хурлыгын күтәрә алмый. Дөрестән дә, бөтен көчен, яшьлеген халкына, аның бәхетле киләчәгенә багышлаган ил башлыгын, колларча дошман кулларга биреп җибәрү һәм аның моңа каршылык күрсәтә алмау – хурлык, рухи фаҗига. Моны Язгөленең сөйгән егете Таңайга әйткән сүзләре дә раслый: «Зур дәүләтнең башлыгын, улы белән бергә, дошман кулына коллыкка биреп җибәрәләр! Чөнки ул моңа каршы тора алмый: сарык кебек карусыз буйсынырга тиеш, шушы хурлык түгелме?!. Аның исеме мәңге тарихта каласы! Кем дип искә алачаклар аны мондый хәлләрдән соң?! Зирәк акыллы ил хөкемдары булган, дипме? Моңа кадәр тоткан данына карапмы? Һичкайчан да! Дошманыннан мәрхәмәт көтәргә мәҗбүр ителгән куркак һәм бичара хатын көненә төшкән бер мескен, диячәкләр! Яки кызганулары мөмкин!»

Дәүләт башлыгының, шәригать законнарын бозып, биек манарадан сикереп төшеп үз гомеренә чик куюы – аның дошман көчләргә каршы көрәшә алмау чарасызлыгыннан туган эчке көрәше нәтиҗәсе; рухи фаҗигасенең чик дәрәҗәгә җитүе. Әлеге гамәле белән горур ханбикә дошманнарына тирән нәфрәтен, алардан бәйсезлеген, бөек халкына тугрылыгы белән аңа булган үпкәсен дә белдерә. Бу ханбикәнең гаделсезлекләргә, түбәнсетелүләргә, кимсетелүләргә протесты һәм ялгыз көрәше дә булып аңлашыла.

Ханбикәнең милләт язмышы белән бәйле бәхетсезлеге дә, үлеме дә тирән трагизм белән сугарылган. Сөембикә үзе дә трагик шәхес. «Трагик герой, – дип яза К.В.Шохин, – игътибар үзәгеннән читтә калучылардан түгел, киресенчә, ул

[8] Таһиров И. Безгә тарих сабак бирә / И. Таһиров // Мирас. – 1994. – №11-12. – 161 б.
[9] Әшрәфҗанов Х. Тарихка әдәби сәяхәт / Х.Әшрәфҗанов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2000. – 193 б.

Сөембикә. ***Камил Муллашев рәсеме***

кай ягы белән булса да игътибарны җәлеп итә, йә нәфрәт, яки мәхәббәт уята»[10]. Пьесада физик һәм, иң әһәмиятлесе, рухи матурлыгы, халкына тугры хезмәте, ватанпәрвәрлеге белән газиз халкының гына ихтирамын казанып калмаган, дошманнарында да нәфрәт катыш соклану уяткан Сөембикә дә укучыда аңа карата хөрмәт һәм мәхәббәт уята. Шул рәвешчә, «Сөембикә язмышы бер үк вакытта милләтебезнең йөз аклыгын һәм драматик тарихын да гәүдәләндерә. Аның яшәешендә мәһабәтлелек белән ачы фаҗига аралаша… Сөембикә – татар халкының йөзек кашы, сөекле кызы, ихлас горурлыгы, шул ук вакытта йөрәгенең төзәлмәс ярасы да ул»[11].

Тарихта туган илгә хыянәте белән мәгълүм кырыс, явыз Камай морзага пьесада аеруча зур урын бирелә. Морзаның кылган гамәлләре, сөйләгән сүзләре һәрдаим аның миһербансызлыгын ассызыклый. Язгөлен тотып Казан шәһәренә китертү өчен үзенең йорт сакчыларын, хезмәтчеләрен бер гөнаһсызга үтертүе, шыгавыллары белән мәрхәмәтсез кылануы, гомумән, гади халык белән тупас мөгамәләсе, ялган сөйләве бу кешенең чын асылын фаш итә.

[10] Шохин К.В. О трагическом герое и комическом персонаже / К.В.Шохин. – М.: Гос.изд-во «Искусство», 1961. – С.9.
[11] Хатипов Ф. Романнарда Сөембикә образы / Ф.Хатипов // Казан утлары. – 1993. – №12. – 152 б.

Фаҗигагә сәбәпче булган икенче бер мотив – битарафлык. Ханбикәнең язмышы хәл ителгәндә «халыкның гамьсез йоклавы» шуны раслый. Димәк, ул үз язмышына да битараф.

Драмада Сөембикәгә «ике тамчы су кебек охшаш» Язгөле Казан ханбикәсе Сөембикәнең тормышын «дәвам итүче» социаль-иҗтимагый әһәмияткә ия образ буларак калка. Әлеге образның мәгънә йөге – фаҗигале рәвештә гомере өзелгән ханбикәсе өчен үч алу. Язгөле әсәрнең буеннан-буена игътибар үзәгендә. Ул – ятимә дала кызы, Камай морзаның җариясе. Әсәр башында ук бу кыз үткен телле, чая, курку белмәс, нык ихтыяр көченә ия дала кыргые булып күзаллана.

Камай морза, Казан ханлыгының кырымлылар белән бәйләнешен өзү өчен, чын ханбикәне вакытлыча яшереп, аның урынына төстәше Язгөлене куеп, үзе һәм аның даирәсе теләгәнчә идарә итү максатын күздә тота. Ил иминлеге-тынычлыгы һәм бердәмлеге өчен көрәшәсе урында, ханбикәне Мәскәү патшасы Явыз Иванга тотып бирүдә актив инициатива күрсәтергә җыенган Камай морза шулай да теләгенә ирешә алмый. Гади халык кызы Язгөле аннан күпкә хәйләкәррәк һәм җитезрәк булып чыга. Сөембикәгә дөресен сөйләп биреп, әлеге кешенең явыз ниятләрен җимерү һәм ханбикә белән «рольләрне вакытлыча алмашу» максатын күздә тотып, кыз качып китә.

Хәлләр шушы ук хәлләрне үзгәртүгә юнәлтелгән характерлар формалаштыра. Әсәрдә Язгөле дә шундый характер булып ачыла. Вакыйгалар кыз көтмәгән якка борылыш ала. Сөембикәнең аның күз алдында манарадан сикереп һәлак булуы кызның язмышын бөтенләй үзгәртә. «Әсәрдә төп игътибар Сөембикә образыннан Язгөле образына күчә… Берсе, тоткын хәлдә яшәгәнче, үлемне артыграк күрә, икенчесе, хәйлә юлы белән дошманнан үч алу, аннан көлү өчен үз теләге белән тоткын ролен кабул итә»[12]. Шул рәвешчә, конкрет тормышчан хәлләрдән, конкрет тормышчан шартларда героик характер үсеп чыга.

Күп кенә тарихи чыганаклардан мәгълүм булганча, Казанны дошман кулына бирүдә Шаһгали зур инициатива күрсәтә. Драмада да Шаһгали, Иван IV каршысына тезләнеп: «Гаскәр бир миңа! Бер айдан мин синең аягың астына Казан тәхетен китереп салачакмын! Синең изге эшең өчен тәнемдә аккан канымның һәр тамчысы шаһит китсен! Гаскәреңне һәм фатихаңны бир миңа!» – ди.

Ризаэддин бине Фәхреддиннең «Шаһ Гали хан» язмасына карата искәрмәсендә Р.Әмирхан Шаһгалинең тышкы кыяфәтенә мөнәсәбәтле барлык чыганакларның да уртак фикердә булуларын телгә алып, аның турында: «Тышкы кыяфәтендә шыксыз, җирәнгеч бер бәндә була»[13], – ди. Чордашлары аның хакында: «…беркем дә яратмый, аның белән аралашмый, кансыз, холыксыз бер кеше иде»[14], – дип язалар. Ул хәтта Мәскәү яклы татарлар өчен дә күңел кайтаргыч бер кеше була[15]. Рус чыганакларында да Шаһгали турында шуңа охшаш фикерләр хөкем сөрә[16].

Шаһгалинең физик һәм рухи яктан кимчелекле булуы Р.Хәмид драмасында да персонажның үз сүзләре белән искәртелә. Шаһгали белән «Сөембикә»нең ачыктан-ачык әңгәмәсендә әлеге хыянәтченең рухи фаҗигасе ачыла: «Кешенең кыяфәте – аның язмышы ул», – ди Шаһгали. Бу персонажның иләмсез зур, ямьсез тышкы кыяфәте аның каһәрләнгән рухи дөньясының чагылышы булып тора.

---

[12] Нигматуллина Ю. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве / Ю.Нигматуллина. – Казань: Фэн, 2002. – С.140.
[13] Фәхретдинов Риза. Шаһ Гали хан / Р.Фәхретдинов // Мирас. – 1995. – №3. – 89 б.
[14] Гариф Н. Казан каргышы / Н.Гариф // Мирас. – 1996. – №9. – 93 б.
[15] Фәхретдинов Р.Г. Казан ханлыгы / Р.Г.Фәхретдинов // Казан утлары. – 1999. – №10. – 116 б.
[16] Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства / М.Г.Худяков. – М., 1990. – С.177.

Шунысын да билгеләп үтү кирәктер: Шаһгалинең тышкы кыяфәте белән бәйле кимсенүләрен, газап тулы эчке кичерешләрен, рухи дөньясын калку сурәтләү образны тормышчан, җанлы итә, хәтта аңа карата кызгану хисе дә уята.

Сөембикә дип кабул итеп, ихластан күңелен бушаткан әлеге кешегә Язгөле үзенең Шаһгали гомере буе хыялланган ханбикә түгеллеген, ә гади бер дала кызы булуын әйтә. Һәм моның белән шушындый явызлар аркасында якты дөнья белән хушлашырга мәҗбүр булган Сөембикәнең үчен кайтара. Үч алу мотивы пьесада үзенчәлекле чагылыш таба. Халкына үчлеккән Шаһгалигә халык үче, боҗра сыман, үзенә үк әйләнеп кайта. Гап-гади бер дала кызын ханбикә дип белеп «шау» итү Явыз Иванга Казанның төп терәге булган Сөембикәне терелә́й тотып бирәм дип ант эчкән Шаһгалинең дә, Мәскәү патшасының да чын йөзләрен ачарга ярдәм итә.

Шул рәвешчә үзен Сөембикә ханбикә итеп таныта алган халык кызы Язгөле безнең күз алдыбызга зирәк акыллы, кыю, халык дошманнарына карата мәрхәмәтсез, дөреслек һәм гаделлек хакына үзен корбан итәргә дә сәләтле саф күңелле, ихтыяр көченә ия шәхес булып килеп баса. Ә Сөембикәнең һаман да «гүзәлләрдән-гүзәл» булып саклануы әлеге образның тарих битләренә мәңгегә кереп калырлык яшьлек, матурлык, батырлык, зирәклек символы булуын ассызыклый. «Сөембикә белән Язгөленең рухи бердәмлегендә, якынлыгында халыкның ханбикәгә булган мөнәсәбәте, уртак максатка омтылышы чагыла»[17].

Романтик пафос белән сугарылган «Хан кызы» драмасының ахыры да үзенчәлекле романтик чишелеш ала: Язгөле белән аның егете Таңайның яратып җырлый торган «Хан кызы» җыры яңгырый.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: Сөембикә образы – матурлык һәм зирәклек, батырлык, милли горурлык һәм азатлык символы, «татар халкының язмышы, иманы, фаҗигале бер чор булган тарихы да»[18]. Әдәби әсәрләрдә ул еш кына рәхимсез Явыз Иван сәясәтенең чарасыз корбаны һәм хәйләкәр дошманның ялган сүзләренә беркатлы ышанучанлык күрсәтеп ялгышкан, газиз халкының хыянәтенә юлыккан бәхетсез ил башлыгы сурәтендә бирелә. Шунысын да әйтеп китү кирәк: автор үзе әсәрне «тарихи драма» дип атаса да, жанр үзенчәлекләрен күздә тотып, әдәби тәнкыйтьтә бу әсәрне «трагедия» буларак тикшерү хупланыла[19].

Гөлия Каюмова,
филология фәннәре кандидаты, ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтындагы Энциклопедистика үзәгенең өлкән фәнни хезмәткәре ■

[17] Закирҗанов Ә.М. Драматургның сурәтле дөньясы (Ризван Хәмид) // Рухи таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Ә.М.Закирҗанов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. – 114 б.
[18] Хәбибуллин М. Сөембикә ханбикә һәм яман чор / М.Хәбибуллин // Сөембикә. – 2004. – №3. – 20 б.
[19] Закирҗанов Ә.М. Драматургның сурәтле дөньясы (Ризван Хәмид) // Рухи таяныч: әдәби тәнкыйть мәкаләләре / Ә.М.Закирҗанов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2011. – 114 б.

Безнең мирас №10 октябрь 2021

Гамьле затлар онытылмый

Тәлгать Галиуллин, филология фәннәре докторы

Җәмил Зәйнуллин

Үз галәме, үз киңлеге белән яшәгән Җәмил Зәйнуллин

Мирза Мәхмүтов атлы «каты тышлы чикләвек»не ватып, эчке серләренә төшенеп булмаячагын аңлап, кул селтәгән бер мәлдә, белгечлеге, белем дәрәҗәсе ишарә иткәнчә, Казаныбызга кайсыдыр гарәп иленнән икенче бер сәер дә, серле дә мосафир кайтып төште. Кызык ератучылар, хыялларын бәйдән ычкындырып, монысы да, Мирза агай кебек, «разведчик», шымчы, шпик булган, һәм, «койрыгына баскач», төрле михнәтләр күреп, өч көн, өч төн буе ашамыйча-эчмичә, туристик пароход трюмында качып кайткан дигән үтә романтик версияне сер итеп колактан-колакка ирештерделәр. Анысы да киләчәк язмышын шул ук мәгариф вә мәгърифәт үзәге Казан дәүләт дәрелфөнүне белән бәйләде. Бирим дигән колына чыгарып куяр юлына,

---

Ахыры. Башы журналның 9 нчы (2021) санында.

дигәндәй, ошбу шәхес яңа оешып килгән татар факультетына һәм, гомумән, милли мохиткә ятышлы белгеч булып чыкты. Бу зат белән таныша башлаганчы, шул чор вазгыятен күзаллау ләзим дип саныйм.

Мәгълүм булганча, 1980 нче еллар азагы тарихка яңа унъеллык, беренче буржуаз инкыйлабыннан (1906-1908) соң татар күген каплап торган кара пәрдәнең бер кырые ачылган чор булып кереп калды. Казан дәүләт университетында мәш килеп, ду кубып олы мәдәни тарихыбызда тәүге тапкыр үз деканаты, үз деканы булган Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетын гамәлгә куеп йөргән бәхетле көннәр. Татар теле, әдәбияты һәм тарих фәннәре буенча укытучылар җитәрлек. Төрки телләргә өйрәтердәй мөгаллимнәр үзебезнекеләр арасында да бар. Ифрат кыска гомерле булсалар да, татар-төрек гимназияләре ачыла башлаган чор. Хәтта кытай теле дә борчу тудырмады. Кытайда туып-үскән, университетның укыту эшләре буенча проректоры булган Миркасыйм Госманов шул илдән бер гаиләне чакырып китереп, фатир юнәтү генә түгел, ризыкланыр өчен Совмин аша бер капчык дөге дә табып, ул тел буенча ихтыяҗны каплады.

Мәгәр югары кимәлдә гарәпчәгә өйрәтерлек белгечне генә кулга төшерәсе калды. Әле бит укытучының телне белүе бер хәл, ул, педагогика, методика таләпләрен күзаллавы өстенә, галим дә булырга тиеш иде. Мин, декан вазыйфаларын үтәүче буларак, андый шәхесне эзләп табуны татар теле кафедрасы мөдире, күренекле галимә, фән докторы Диләрә Тумашевага йөкләдем. Озак та үтмәде, галимнәр, зыялылар арасында зур абруйлы профессорыбыз декан бүлмәсенә иркендә үскән нарат агачы төсле төз гәүдәле, текә маңгае астына кереп оялаган шомырт кебек кара күзле, урта яшьләрдәге бер ир затын алып керде. Каратут йөзе аның кыпчак-нугай нәселеннән икәнлеген, гарәпләр арасында да «үз кеше» булып саналырлыгы барлыгын «сатып» тора иде.

– Менә безгә кирәкле гарәп теле белгече. Фән белән шөгыльләнергә дә нияте бар, – дип аңлатма бирде Диләрә Тумашева,аны безгә тәкъдим иткәндә.

Мин дә, сүзгә катнашып китәргә тиешлегемне аңлап, иң гадәти сорауны бирдем:

– Сезне тумышыгыз белән кайсы яклардан дип белик инде? Югары белемне кайда алдыгыз?

– Анкетада барысын да яздым, укып карарсыз. Чирмешән районының Иске Кадый авылында туып-үстем. Урта мәктәпне шунда тәмамлагач, Ташкент университетының Көнчыгыш телләрне өйрәнү факультетында белем алдым. Аннан соң гражданлык вазыйфаларымны (бу сүзләрне ишеткәч, эсселе-суыклы булып китте) үтәдем.

Кайларда, кем булып эшләве турында ләм-мим сүз чыкмады. Без дә төпченә алмадык, тиз генә уку-укыту программалары, дәреслекләр мәүзугына кереп киттек. Соңрак мәгълүм булганча, аның тормыш юлы үзе бер «кысалы кыйсса» – маҗаралы әсәр икән. Гадәти мишәр авылында туып-үскән егетнең Урта Азия тарафларына юл тотуы, шунда студент булып китүе үзе үк бер батырлык һәм сер иде. Ул анда да гомуми масса арасында югалып калмаган. Укымышлы бабасыннан балачакта ук дин һәм гарәп теле дәресләре алган Җәмил алдынгы талибларның берсе булып китә һәм укуын тәмамлаганчы ук (1972-1973) аны Судандагы совет илчелегенә тәрҗемәче итеп тәгаенлиләр. Ә инде 1974 сәнәдә, дипломын алуга ук, яшь белгечне Иракка «эш»кә җибәрәләр. Шунда аның тормышында гаять үзенчәлекле, текә бер вакыйгага була. Гарәп телен, дипломатия үзенчәлекләрен дә күпмедер күләмдә яхшы үзләштерүен исәпкә алып, 1975 елда Ирак Президенты Саддам Хөсәен белән СССР Министрлар Советы рәисе А.Н. Косыгин арасындагы дәүләтара сөйләшүләрне турыдан-туры тәрҗемә итүне аңа ышанып тапшыралар.

Соңрак Иракка ялган сылтау белән АКШ гаскәрләре бәреп кергәч, Җ.Зәйнуллин, югарыда искә алынганча, кызык ятратучылар хыялындагыча маҗаралы юллар белән туган иленә кайтып төшә. Аңа монда да бәхет елмая. Чөнки ул яңа ачылган факультет өчен көтеп алынган, иң кирәкле укытучыларның берсе булып чыга.

Югары уку йорты мөгаллименең вазыйфасы дәресен вакытында уздыруга гына кайтып калмый. Ул, гыйльми әзерлегенә лаеклы юнәлеш табып, фәнни дәрәҗәләр алу өстенә, административ баскычтан югары күтәрелү турында да уйларга тиеш.

Җәмил Зәйнуллин уку-укыту мәсьәләләрендә ифрат төгәл вә таләпчән булып чыкты. Мин аның, лекциясен калдыру түгел, хәтта биш-ун минутка соңарып килүен дә хәтерләмим. Укыткан студентлары да, аның ихтыярына курку катыш хөрмәт аша буйсынып, тәртипкә өйрәнделәр. Лекцияләргә ачык изүле, кыска итәкле күлмәк киеп килгән кызларга да әдәп кагыйдәләрен төшендерә белә иде ул.

Җәмил Зәйнуллин, белем бирү дәрәҗәсенә хилафлык китермичә, фәнни-гыйльми эзләнүләрнең әһәмиятен дә дөрес бәяләде. Бу аның гыйльми дәрәҗәләр алу тизлегендә дә ачык күренде. 1988 елда ул «Татар әдәбиятында Калилә һәм Димнә» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклап, ВАКта бик тиз расланды һәм бер ел үтәр-үтмәс доцент дәрәҗәсен алды.

Җәмил Зәйнуллин 1999 сәнәдә «19-20 нче йөз башы татар дини әдәбияты һәм аның тел-стиль үзенчәлекләре» дигән шактый катлаулы вә четерекле темага докторлык диссертациясен яклый һәм бераздан профессорлык дәрәҗәсенә лаек була. Фәнни эзләнүләрнең энә белән кое казу шикелле авыр икәнен ошбу хезмәткә азмы-күпме мөнәсәбәте булган кеше дөрес аңлар.

Шунысын искәртү дә мөһим: докторлык дәрәҗәсенә тәкъдим ителгән хезмәтнең үзен язудан бигрәк, өстәмә таләпләре вакытны күбрәк ала. Моның өчен шул мәүзугъка караган 15-18 фәнни мәкаләң «ВАК» һәм «SCOPUS» (түләүле чит ил басмалары) журналларында басылуы һәм берничә монографияң дөнья күреп, аларның уңай бәя алуы мәҗбүри шарт. Шуннан соң төрле дәрәҗәдәге фәнни тикшеренүләр, оппонент бәяләрен алулар белән кимендә 15-20 ел үтә дә китә. Җәмил Зәйнуллин исә бу киртәләрне дистә елда үтеп чыга.

Төрле югарылыктагы фәнни конференцияләрдә катнашып, зур гыйльми дәрәҗәләр алса да, бу күренекле галим шул ук Җәмил булып калды. Ул, тыштан кырыс, таләпчән булып, үткән тормыш юлы турында ачылып китеп сөйләмәсә дә, аралашу өчен шактый җайлы, шаяртуны, төрттерүне аңлый торган кеше иде.

Үзе ниндидер дәрәҗәләр алуга омтылмаса да, шөһрәт аны үзе эзләп тапты. Профессорга өстәмә эшләр өйми калдыралармы соң инде?! Аның административ баскычлардан югары күтәрелүе фәнни-гыйльми дәрәҗәләренең лаеклы булуын раслап тора, диярсең.

Җәмил Зәйнуллин аңа кадәр татар теле кафедрасы доценты саналса, 1994 елда махсус аның өчен диярлек, гарәп, фарсы, төрек һәм кытай телләрен өйрәтү максаты белән, яңа – Көнчыгыш телләр кафедрасы оештырыла. 2000 елда ошбу юнәлешне татар филологиясе факультетыннан аерып алып, Көнчыгыш телләр институтына нигез салалар. Ахыр чиктә гөрләп үсеп килгән факультетны таркатуга китергән бу гамәлне аңлап та була. Казан университеты оешкан чорда «восточный разряд» дигән берәмлек булдырылып, анда, гарәп-фарсы телләреннән тыш, монгол һәм татар теле дә өйрәнелгән.

Шулай да зур авырлык белән, күп көч куеп ачылган бу кафедраны, әзергә-мәзер, дигәндәй (мине инсульт түшәккә егып салган вакыт иде), студентлары, укытучылары белән тартып алу Татар факультетының позицияләрен йомшартты.

Җ.Зәйнуллин яңа оешкан Көнчыгыш телләр институтының беренче һәм соңгы директоры вазыйфаларын башкара. Әлеге институтның да гомере озын булмый. 2011 елда ул, гарәп филологиясе кафедрасы буларак, КФУ составына керә. Кафедра мөдирлеген саклау өстенә, Җәмил Зәйнуллин Россия ягыннан Конфуция институты директоры да санала.

Кулыма каләм алып, галимнең тормыш юлын, укытучылык хезмәтен күзаллагач, аның холык-фигыле турында да уйландым. Ярты гомерен чит илләрдә уздырып, безгә мәгълүм булмаган күп вазыйфалар башкарган кеше «үтәкүренмәле» була алмый торгандыр. Ул, талиб-талибәләр белән уртак тел тапса да, укытучылар коллективында «үз кеше» булып китә алмады. Бу аның холкына һәм тәрбиясенә бәйле иде. Ул теләсә кем белән «братан» дип ачылып китеп, аркага шап-шоп сугып аралаша, ягъни буш, гомуми сүзләрдән тәм таба, ләззәт ала торган зат түгел иде. Шаушулы, эчемлекле мәҗлесләрне өнәмәде, юбилей шикелле җитди сәбәп булмаганда, андый утыруларны заяга вакыт уздыру дип санады (аның еш кабатлый торган әйтеме – «гомер болай да кыска» иде). Җәмил Зәйнуллин бөтен барлыгын фәнгә һәм уку-укыту эшенә, яшьләрне тәрбияләүгә бирде.

Кешенең мохитне аңлавына, холык-фигыленә бәя бирү, үз-үзен тота белү дәрәҗәсен күзаллау өчен, бигүк әһәмиятле күренмәсә дә, ике вакыйганы искә төшереп үтәсе килә. Кешенең асылы вак-төяк булып күренгән хәлләрдә ачыла дип тикмәгә генә әйтмиләрдер.

Җәмил Зәйнуллин факультетта эшли башлаган елларда Тобол пединститутына (анда да татар бүлеге бар иде!) махсус курслар укырга бардык. Шул көннәрдә үк анда әдәби бәйләнешләрны өйрәнүне үзәккә алган фәнни-гамәли конференциядә дә чыгыш ясарга тиеш идек.

Менә без өчәү – гарәп теле белгече Җәмил Зәйнуллин, доцент, язучы Мөхәммәт Мәһдиев һәм мин бер купега урнаштык. Поезд белән тәүлектән артык барасы. Юлда күп йөргән кеше буларак, мин эчемлеген дә, азык-төлеген дә алдым. Тере классигыбыз да нәрсәдер кыстырган иде. Җәмилебез исә барысын да үз кулына алды.

– Сезнең арада яшьрәк кеше буларак, каршы килмәсәгез, дастарханны мин әзерләрмен, – диде дә, җавапның уңай гына буласын чамалап, үзе белән алып килгән тастымалын җәеп, шуңа әле суынырга да өлгермәгән итле пәрәмәчләрен тезеп куеп, вагон хуҗабикәсенә чәй сорарга дип кузгалды. Мөхәммәт: «Буш стаканнар да ала кил», – дигән иде, чит мәмләкәтләрне айкап кайткан егетебез, барган җиреннән безнең якка борылып, өлгергән кара карлыгандай күзләренә, алары тагын нәрсәгә, дигәндәй, сорау билгесе чыгарды.

– Соң, бераз авызны чылатып, кәефләрне күтәреп алырбыз, озак барасы ич! – дип акланырга туры килде язучыбызга.

Сиземләвемчә, үзе һәм әсәрләре белән азмы-күпме таныш булган Җәмил Мөхәммәтне хөрмәт итүен, каләмен югары бәяләвен яшерми, гел сиздереп тора иде. Әмма аңа исеме белән мөрәҗәгать иткәнен хәтерләмим, ул аңа һәрвакыт, Мәһдиев абый, дип кенә эндәшә иде. «Мөхәммәд (с.г.в.)» сүзен яңгыратасы килмәдеме шунда – әйтә алмыйм.

Кыскасы, барганда да, кире кайтканда да, кунакханәгә урнашканда да бар мәшәкатьләрне үз өстенә алды Җәмил туганыбыз. Беренче каттагы ресторанга кичке ашка төшкәндә дә кайгы-хәсрәтне белмәдек. Шунда юлчыбызның кирәк чакта шактый кырыс була алуын да күрдек. Әле бит Совет чоры иде. Официантлар ашыкмыйча, үз кадерләрен белеп кенә эшлиләр. Озаграк көттергәч, Җәмил Габделхак улы, җаваплы кешесен табып: «Монда кемнәр, нинди затлар утырганын беләсезме,

алар кебек шәхесләр сездә булмаганнар, шулай мыскыл итсәгез, бирегә кабат аяк та басмаячаклар, сез дә монда эшләмәячәксез!» – дип, тегеләрне утлы табага бастырып алды. Күп вакыт узса да, шулчакта тавышына «металл кушып» сөйләшүе хәтердә калган.

Аның мөкиббән киткән эчемлеге затлы коньяк та, виски да түгел, ә куе кара чәй иде.

Хәтеремдә, чираттагы гыйльми шура (совет) утырышыннан соң ул мине кафедра мөдире бүлмәсенә чәйләп алырга дәште. Үзенә күрә бер сабак алдым. Аның Ташкентта университетның чит телләр факультетында белем алганда, үзбәкләр белән аралашып, аларның гореф-гадәтләрен миенә сеңдергәнлеген, шул традицияне хөрмәт белән саклаганлыгын аңладым. Гадәттә, чәйләп алуны без гадәти бер шөгыль яисә сусауны басу дип кенә бәялибез. Юк икән шул. Күзләремне тондырып карап торам: суны кайнатып чыгарып, фарфор чәйнекне җылыткач, эре кара бөртекле чәй салып, яңадан су агызгач, чәйнекне калын, йомшак сөлге белән каплап, берничә дәкыйка тотты. Шуннан соң, кечкенә фарфор чәйнектән пешкән чәйне чынаякка агызып, сыеклыкны чәйнеккә өч тапкыр кире салды. Минем гаҗәпләнеп карап торуымны күргәч, әлеге сәер хәрәкәтләренә бик теләп аңлатма бирде:

– Үзбәкләр пешкән чәйне шулай өч тапкыр кире салалар. Бу гамәлләрен алар, чәйне өйләндерү, диләр. Янәсе, шулай эшләгәч, чәй бөтен тәмен, сихәтен чыгара. Мин шуңа ышандым, файдасын күрәм.

Шулай пешерелгән чәй, сусаган вакытка туры килгәнгәме, миңа да ифрат ошады. Ахырдан үзем дә шул гадәткә өйрәндем, хатыным Фәүзияне дә шуңа күнектердем. Инде Җәмил бакыйлыкка күчкәч, шул йоланы аның васыяте дәрәҗәсендә саклыйбыз.

Мөхтәрәм укучым, гафу-гафу! Хисләргә бирелеп, читкәрәк киттем, ахры. Чүпрәле камыр төсле ташып торган җегәре аны милләтенә хезмәт итүнең башка юнәлешләренә дә алып кереп китә. Азга гына булса да, демократия җилләре исеп киткән арада, дин һәм аның юлына басу барышында гарәп теле белән кызыксыну уянып алуны истә тотып, иң әүвәл ул, зәңгәр экраннан гарәп әлифбасына һәм кагыйдәләренә өйрәтә башлый. Җәмил Зәйнуллинга студентлар белән эшләү, «ликбез» курсларын оештыру, суфыйларның шигъри мирасын өйрәнү генә аз тоела. Ул үзе өчен яңа бер юнәлеш таба: ислам диненең шигъри юлдашы мөнәҗәтләр белән чын-чынлап кызыксына, аларны өйрәнә башлый. Дастан, бәет, озын көйле җырлар шикелле үк, халкыбызның күңел түрендә урын алган мөнәҗәт жанры да, галимнәр фикеренчә, хәзерге Гыйрак, Сүрия илләре урнашкан төбәкләрдә туып, акрынлап бөтен ислам дөньясына таралган. Әүвәл алар Аллаһны бердәнбер бөек, илаһи көч дип таныткан, Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрне, аның гаиләсен, хәлифәт хакимнәрен олылаган дини салаватлар, зикерләр, мәүлидләр калыбында халыкның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндергән. Акрынлап аның эчтәлегенә ялгызлык, фираклык, туган җирдән, якыннарыңнан аерылу сагышы, үлем хәлләре кебек дөньяви мотивлар үтеп керә. Бәет, дастаннар, озын җырлар белән аралашу мөнәҗәтләрнең сурәтле фикерләү алымнарын баета. Ләкин ул үзенең яшәү мәгънәсе, кешенең хәяттәге урыны, «сабырлык бирсәнә, Аллаһ, без бу дөньяда кунак кына, ахирәткә ак йөз белән бармак кирәк» кебек үзәк мәгънәви вә зәүкый юнәлешен саклый. Нәкъ менә шундый эчтәлекле мөнәҗәтләр радио һәм телевидениедән тәүге тапкыр Җәмил әфәнде башкаруында яңгырады. Татар мөнәҗәтләрен башкарганда тавыш тембрыннан, бит, күз хәрәкәтеннән аның бәхет үрендә икәнлеген сиземләве кыен түгел иде. Совет чорында яшерен-орынтын гына тар мәҗлесләрдә, әбиләр авызла-

рын яулык очлары белән каплап кына әйткән мөнәҗәтләрне олы дөньяга чыгаручы кеше чит ил-җирләрне айкап кайткан Габделҗәмил Зәйнуллин булды, дисәм, ялгыш булмастыр.

Мөнәҗәтләрне төрле мөнбәрләрдән яңгырату барышында, ул аның иң күркәм, затлы аһәңле үрнәкләрен сайлап алып, аңа «Хан кызы: мөнәҗәтләр» дигән исем биреп, әтрафлы, үз милләтен, динен яраткан һәркайсыбызга барып җитәрлек кереш сүз белән бастырып чыгарды (Казан: Мәгариф нәшрияты, 1994).

Мөнәҗәтләрдән тыш, аның шөгыльләнәсе килеп, «теш кайрап» йөргән өлкәсе татар теленә гарәп-фарсы аша килеп кергән сүзләрне оныттырмау нияте белән төзелгән «Шәрык алынмалары сүзлеге» иде. Бу юнәлешнең әһәмиятен, лөгать байлыгыбызны саклауның кирәклеген ул вакытында сиземләп, ифрат файдалы, гамәли җыентык әзерләп бастырып чыгарып калдырды. Нигездә, үзенең шәкертләрен күздә тотып эзләнсә дә, бу татар теленә, әдәбиятына мөнәсәбәте булган шәхесләр, үткәнебез белән кызыксынучылар, дин әһелләре өчен ифрат файдалы китап. (Шәрык алынмалары сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 1994, 193 б.) 17 700 данә белән нәшер ителеп, тиз арада таралып та бетте ул. Бу сүзлектән һәркайсыбыз үз исем-фамилияләребезнең, көндәлектә йөргән атамаларның мәгънәсен, эчтәлеген ачыклый ала.

Җәмил Зәйнуллин җыентыкка кереш сүзендә болай дип яза: «Укыту процессында файдалану һәм мөстәкыйль рәвештә мәдәниятебез, халкыбыз тарихы белән кызыксынучылар өчен дә сүзлекләрнең җитешмәве үзен сиздерә. Менә шуларны исәпкә алып төзелгән җыйнак кына бу сүзлекнең мәктәп укучыларына, студентларга һәм иске язуыбызны үзләштерүчеләргә дә ярдәме тияр дип уйлыйбыз». (Б.3.)

Габделҗәмил Зәйнуллинның әти-әнисенә, балаларына ихтирам күрсәтеп яшәвен әйтеп тә тормыйм. Исламның әхлак кагыйдәләрендә тәрбияләнгән кеше буларак, ул үзенең арка терәгенә – тылына артык якын китермәде, башкаларның шәхси тормышы белән кызыксынудан да тәм тапмады. Искәртүемчә, аның белән якыннан аралашканчы артык кырыс күренгән Җәмилнең туган җанлылыгы чикләрне белми иде кебек.

Улы Данияр, профессор Вахит Хаков әйтмешли, «кампутрчы» булып китсә, кызы Айсылуны үз яныннан еракка җибәрмәде. Шулай ук татар филологиясе факультетында белем алган кызы Флер Фоат улы белән (ул хәзер Татарстан Фәннәр академиясендә ифрат җаваплы вазыйфалар үти) гаилә корды. Кызлары Газизә тыйб белгече булырга әзерләнә, медицина көллиятендә укый. Габделҗәмил хәзрәтләре, балаларының гаиләләре ныклыгын күреп, дәвамчылары калуына ышанып, 2020 ел башында тавыш-тынсыз гына бакыйлыкка күчте.

Ул депутат та булмады, түрәләр шикелле йомшак машиналарда да тирбәлеп йөрмәде. Хәреф чүпләп, мөнәҗәт әйтеп, борынгы әдәби мирасыбызны өйрәнүдән тәм, күңел сөенече табып, мәгънәле итеп яши белде.

Татар галәменә көнчыгыш телләрен өйрәтүгә, милләттәшләребезне тарихи чыганакларыбызга якынайтуга зур өлеш керткән, халкыбызның рухи тормышына яңалык алып килгән ике олы шәхес хакындагы бәянемә инде нокта куяр вакыт җитте.

Алар мәдәниятебез күгендә төрле елларда якты йолдыз булып, күпләргә юл күрсәтеп, милләтебезгә үзләре белгәнчә, аңлаганча хезмәт итеп, исән чакта рәхмәтләр ишетеп, мәңгелеккә күчте. Әмма якыннары, оныклары, шәкертләре йөрәгендә һәм язып-иҗат итеп калдырган хезмәтләрендә мәңге яшәрләр.

Мондый олы шәхесләр онытылмый. Һәрхәлдә, без аларны онытырга тиеш түгел.

Ә күңелдә якын-кадерле кешеләрне юксынудан туган чиксез моңсулык... ■

Аркаимга сәяхәт

Лирон Хәмидуллин

Аркаим каберлекләреннән табылган балчык савытлар

Көньяк Урал төбәге, борын-борын заманнардан бирле, төрки халыкларның яшәү урыны буларак, фәнни хезмәтләрдә теркәлгән. Тарихи язма әдәбият та, археологик эзләнүләр нәтиҗәсе дә бу фактны раслый. Мәсәлән, СССР Фәннәр академиясенең Археология институты галиме, тарих фәннәре докторы К.Ф.Смирнов җитәкчелегендәге археологлар 1950-1970 нче елларда Орск-Чиләбе шәһәрләре аралыгында скиф һәм сарматлар тарихын барлауга бәйле бик җитди тикшеренү эшләрен башкаралар. Шул тикшеренүләр нәтиҗәсе буларак, соңрак әлеге галимнең скифларга багышлы җитди китабы да басылып чыга.

Шул ук 1950 нче елларның икенче яртысыннан башлап Оренбург педагогия институты галиме, тарихчы һәм археолог С.А.Попов җитәкчелегендәге археологлар да, Оренбург һәм аңа чиктәш өлкәләрнең төрле төбәкләрендә казынып, байтак кына тарихи табышка ия булалар. Соңыннан аларның кайберләре Нью-Йорк, Мәскәү, Петербург һәм башка музейларга да алына. Сергей Александрович Попов исә күпчелек тарихчылар тарафыннан хуплап кабул ителгән «Тайны Пятимаров» (Җир асты серләре. – 1982, Чиләбе) китабын нәшер итәчәк. Һәм ул

китапта әлеге төбәктә гомер иткән шул ук скиф, сармат һәм башка төрки халыклар тормышын чагылдырган тарихи табышлар турында хәбәр ителә. Шул тарафтагы курган-каберлекләр куеныннан табылган бакыр эретмәләре калдыкларына нигезләнеп, монда аны кою һөнәре бик борынгы чорда ук үзләштерелгән булган, дип яза автор. Урал тауларның бу тарафлары хәзер дә алтын белән бакыр чыганакларына бик бай. Алтыннан бик затлы һәм кыйммәтле бизәнү әйберләре ясаган скиф осталары да, Алтай таулары алтыннарыннан тыш, Урал байлыгыннан да файдаланганнардыр, мөгаен. Җир куенындагы бакыр ятмаларын куллану өчен кайчандыр казылган тирән-тирән чокырлар хәзер дә Урал тавы җирлегендә очрап тора. Мондагы кешеләр җир эшкәртүгә дә күптән керешкән булырга тиеш. Бик борынгы чүлмәк төпләрендә сакланган иген бөртекләре (башлыча тары ярмасы) шул фикерне дәлилли, ди автор. Скифлар да, сарматлар да ат өстеннән төшмәгән диярлек. Яу-сугыш барышында да алар, чабып барган ат өстендә килеш уктан бер-бер артлы атып, дошман көчләрен юк итә алган. Археологларга казу эшләре барышында агачтан ясалган зур тәгәрмәч калдыклары да еш очрый. «Димәк, җирле халык ат һәм үгез дә җиккән», – дип яза А.С.Попов. Борынгы дәвердә монда яшәүчеләр башлыча скифларның бер кавеме – сарматлар булган. Соңрак аларга башка төрки кабиләләр дә килеп кушылган, ди автор. Элекке заман тарихчылары да идарәче скиф кабиләләренең төрки булу ихтималы хакында күп яздылар. Грек Геродот, Курций Руф, 18 нче йөз рус галиме Андрей Лызлов хезмәтләрендә скифларга нисбәтле кайбер сүзләр, исемнәр дә китерелә. Әйтик, ил башлыгының русча язылышта «атей» дип аталуы һ.б.

Таш чүкечкә ясалган кеше сыны (биеклеге – 11 см)

1980 нче еллар урталарыннан башлап Урал тауларның Оренбург өлкәсе чикләрендәге борынгы курганнарында Башкортстан галимнәре дә казу эшләрен башкарды. Һәм аларның затлы-затлы табышларга юлыгуы турында үзәк матбугатта да язып чыктылар. Мин ул елларда «Известия» белән «Комсомольская правда» газеталарын даими рәвештә укый идем әле…

Дәрдемәндкә багышланган альбом чыгарырга әзерләнү чорында, 1993-1994 нче елларда, фотограф Зөфәр Бәширов белән безгә дә Көньяк Уралның күп кенә урыннарында булырга туры килде. 1994 елның август башында без Башкортстанның Оренбург һәм Чиләбе өлкәләре белән чиктәш Баймак шәһәрендә идек. Баймак

районына кергән Юлык авылына бөек шагыйребезнең ата-анасы аңа өч яшь тулган көздә килеп урнаша. Дәрдемәнднең яшүсмер чоры шушында узган. Ул, мәдрәсәнең өлкән сыйныфларында укыганда, кыш айларында гына моннан йөз кырык чакрымдагы Орск шәһәрендә яшәгән. Ә җәй айларын алар аталары Мөхәммәдсадыйк хаҗиның шушы Баймак белән Орск шәһәрләре тирәләрендәге алтын приискасы бистәләрендә уздырганнар. Без аларның кайберләрендә булдык. Инде алтын чыганагына иң бай өч прииска урнашкан Балкан авылына гына барасыбыз калган иде. Ул авыл исә Чиләбе өлкәсенең Магнитогорск шәһәреннән көньяктарак, Казакъстанның Кустанай өлкәсе чигенә табарак урнашкан. Шунда ничек бару турында киңәшер өчен, мин район башлыгы урынбасары, милләттәшебез Шәүкәт Гали улы Тутаев янына киттем. Баймакка килгәч тә бер очрашкан идек инде. «Бик вакытлы килдең. Берсекөнгә мин ул якка Уфадан килгән ике артистны җибәрергә тиешмен. Икәү генә булгач, сез дә ул машинага сыярсыз», – дип ышандырды ул. Дөрес, әлеге артистлар Балкан белән Баймак арасындагы Аркаим дигән җиргә генә барасылар икән. «Аннан тимер юл станциясенә ерак түгел. Машина сезне шунда илтеп куяр. Магнитогорскига шуннан китәрсез», – дип тә өстәде Шәүкәт иптәш.

Урал тавы сыртындагы Александровка авылы янәшәсендәге Аркаим дигән урында бик җитди археологик эзләнү-тикшеренү эшләре барганлыгы турында үзәк матбугатта берничә язма урнаштырылган иде инде. Мин аларны укыган идем.

– Алайса без дә ул атаклы урынны күреп, танышып китә алырбызмы соң? Машина безне шунда күтәрме? – дип сорарга мәҗбүр булдым.

– Күтәр, әйтермен мин шоферга, – диде җитәкче абзабыз.

Һәм 1994 елның 9 август иртәсендә без шушы сәяхәткә чыгып киттек. Илгә Аркаим буларак танылган бу урында археологик эзләнү-барлау эшләрен Чиләбе шәһәре университеты галимнәре башлап җибәргән. Соңрак аларга ярдәмгә үзәктән дә берничә абруйлы галим килә. Монда казу эшләрен башлаучы тарихчы галим Геннадий Борис улы Зданович була. Без ул җиргә сәяхәт кылган җәйдә инде аның шушы вакыйгаларга багышланган китабы да басылып чыккан иде. (Соңрак тагын берничә автор: «Бу шәһәрчекне төзүчеләр, мөгаен, безнең ерак бабаларыбыз булгандыр», – дип язып чыкты.)

9 август көнендә без аның белән очраша алмадык. Ул шәһәрдә әле, диделәр. Ә күрше республикадан килгән кунакларны аның ярдәмчеләреннән берсе Дмитрий Александрович Мальцев кабул итте. Ул кыскача гына галимнәрнең әлеге тарихи курган белән кайчаннан кызыксына башлаулары турында сөйләде. «Бу кечкенә шәһәрчекне барлыкка китерүчеләр скиф-сарматларга чаклы яшәгән халык булырга тиеш. Ул – бик үзенчәлекле шәһәрчек урыны. Аңа хәзер өч мең җиде йөз ел чамасы дип фаразлана. Археологлар моңа чаклы СССР җирлегендә шундый унөч урынны тикшерделәр инде. Алар, бер тезмә булып, моннан дүрт йөз чакрымгача – Сыр-Дәрья елгасының урта өлешенәчә тезелешкәннәр. Шушындый ук рәвешле тагын бер шәһәрчек бездән ерак түгел – Кустанай өлкәсенең төньяк өлешендә урнашкан», – диде әңгәмәдәшебез.

Галимнәр әлегәчә мондый утрак-шәһәрчекләрне төзүче-оештыручылар – зороастризм диненә нигез салучы, «Авеста» китабын бар иткән, һинд-европа телендә сөйләшүче кабиләләр булгандыр дип фаразлыйлар. Шул сәяхәттән кайткач та, мин Мәскәүнең тагын бер атаклы археологы, академик Сергей Павлович Толстов китапларын актарырга керештем. Аның төп хезмәтләре Урта Азия



Аркаим каберлегендәге бронза пычаклар, сөңге очлыгы һәм бәлҗә (аркылы балта). Б.э.к. XVII-XVI гасырлар

республикалары биләмәсенә кергән җирләрдә археологик эзләнүләргә бәйле. Ул аеруча хәзерге Үзбәкстан белән Төрекмәнстан биләмәләренә кергән, элекке Харәзем дәүләте тарихына кагылышлы җирләрдәге борынгы авыл һәм шәһәр урыннарында зур эшләр башкара. Шул төбәктә яшәүче халыкларның бронза чорыннан бирле җирне эшкәртеп көн күрүен дәлилли. Һәм Толстов та Аму-Дәрья елгасы буенда Аркаим шәһәрчегенә тартым көнкүреш итүгә исәпләнгән ике шәһәрчек турында бик тәфсилләп яза. Һәм ул бу төбәктә яшәүчеләрнең көнкүрешен тарихи шумерлар көнкүрешен дәвам итүчеләр буларак кабул итә. Кызганыч ки, Сергей Павловичның әлеге китапларын мин соңрак кемнәргәдер бүләк иткәнмен. Күпчелек галимнәр шумерлардан сакланып калган ташка язулы сүз-җөмләләрнең төрки сөйләмгә тартым булуын таныйлар. Харәзем мәмләкәтендә төп сөйләм теле фарсыча булган дияючеләр дә, төркичәлекне яклаучылар да бар. Әлбәттә, Россия галимнәренең күпчелеге фарсычылык яклы.

Чирек гасыр элек булган бу сәяхәттән соң вакыт-вакыт күңелдә шундый сорау туа: гомер-гомергә төркиләр белән угро-фин вәкилләре яшәгән Урал тауларының бер сыртында урнашкан бу Аркаим шәһәрчеге кешеләре кемнәр булды икән соң? Ул сәяхәттән кайтышлый шул хакта без Уфадан килгән оста курайчы – артист Ташбулат Дәүләтшин белән дә уйный-шаяра сөйләшеп алган идек. Әмма, ни кызганыч, җавабын таба алмадык. ■

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

КАРИ ӘНӘС (1925-1954)

Балалар язучысы, мөгаллим. 1925 елның 11 июнендә Азнакай төбәгендәге Уразай авылында туган.

1942 елда Орел каласы өчен барган сугышларда каты яралана. Гарипләнгән килеш Татарстанга кайта, Арчаның укытучылар әзерләүче уку йортында гомере буе мөгаллимлек кыла – балалар укыта.

1954 елда аның сугышта алган җәрәхәтләре ачыла һәм ул күп кан югалтудан вафат була.

КУРАТ ӘКЪДӘС (1903-1971)

Татар галиме, профессор. Алтын Урда ярлыклары белгече. Әкъдәс Нигъмәт Курат 1903 елда Татарстанның Чирмешән районындагы Бәркәтә авылында туган.

Әкъдәс Курат совет иленнән качып китә һәм калган гомерен чит илдә – Төркиядә уздыра. Ул 1978 елның сентябрендә юл фаҗигасендә һәлак була. Төркиядә җирләнгән.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

КРЫЙМОВ МАНСУР (1898-1938)

Татар шагыйре. 1898 елда Апас төбәгенең Чүри-Бурнаш авылында туган. Бик яшьтән ятим калып, авылның Кәрим Фәтхуллин исемле мәзине аны уллыкка ала. Ул аларга бик тиз ияләшә һәм уллыкка алган әтисе Кәрим исеменнән Крыймов псевдонимы ясый. Мансур Крыймов үсмер чорында Грозный шәһәрендәге нефть эшкәртү промыселенда эшли.

«Контрреволюционер» дигән ялган гаеп тагып, аны Уфа зинданына ябалар, ул шунда 1938 елның 1 августында атып үтерелә.

КОРМАШ ГАЙНАН (1919-1944)

Татар шагыйре, хисап укытучысы. 1919 елның 27 февралендә Казакъстанның Актүбә өлкәсендә туган.

1939 елда Кызыл Армия хезмәтенә алына. Кече командирлар мәктәбен тәмамлагач, Гайнан Кормашка лейтенант дәрәҗәсен бирәләр. Шуннан соң Фин сугышында катнаша. Бөек Ватан сугышы башлангач, Кормашны – яхшы әзерлекле һәм ышанычлы офицер-разведчикны дошман тылына җибәрәләр. Ул, әсирлеккә алынып, «Идел-Урал легионы»на эләгә. Гайнан Кормаш анда, фашистларга каршы көрәшер өчен, яшерен оешма оештыра. 1944 елның 25 августында, көндезге 12 сәгать 6 минутта, фашистик Алманиягә каршы көрәшнең төп оештыручысы буларак, беренче булып аның башы киселә.

КӘРИМ ФАТИХ (1909-1945)

Татар шагыйре. 1909 елның 9 гыйнварында Уфа губернасына караган Бәләбәй өязендәге Ает авылында (Бишбүләк районы) туган.

1938 елда ул, ялган гаеп тагылып, зинданга ябыла. Югары суд утырышы шагыйрьне 10 елга төрмәгә ябылуга һәм 5 елга гражданлык хокукларын чикләү җәзасына хөкем итә. Фатих Кәрим Бөек Ватан сугышын Сталин төрмәсендә каршылый. Ул, сугышка ирекле булып язылып, фронтка китә һәм 1945 елның 19 февралендә Кенигсберг (хәзер Калининград) тирәсендәге (Көнчыгыш Пруссиядә) сугышта батырларча һәлак була. Кабере Багратионовск шәһәрендәге Туганнар каберлегендә.

КУТУЙ ГАДЕЛ (1903-1945)

Татар шагыйре. 1903 елның 28 ноябрендә Пенза өлкәсендәге Татар Кынадысы авылында туган. Сугыш бетәр алдыннан – 1945 елның язында Гадел Кутуйның сәламәтлеге начарлана һәм ул 1945 елның 15 июнендә Польшаның Згеж шәһәре госпиталендә вафат була һәм шул шәһәрнең зиратында җирләнә.

Текстны басмага
***Рабит Батулла** әзерләде.* ■

Истә, һаман да истә!

Язучы Идрис Туктарның туууына 125 ел

Язучы, 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Идрис Ильяс улы Туктаров 1896 елның 2 октябрендә Башкортстанның Благовар районына караган Булышлы (Балышлы) авылында туган.

И.Туктар 1924 елда яза башлый. 1930 елда исә беренче зур күләмле әсәрен – «Сиксән беренче штольня»ны язып тәмамлый. Әдип балалар өчен дә иҗат итте, тәрҗемә белән дә шөгыльләнде (мәсәлән, А.Купринның «Ак пудель» хикәясен 1950 елда тәрҗемә итте).

И.Туктар 1982 елның 20 октябрендә Яшел Үзән шәһәрендә вафат булды.

Артист Камал IIнең туууына 90 ел

Артист Камал II (Габдрахман Галиәкбәр улы Камалетдинов) 1896 елның 5 октябрендә Казанда туган.

1915 елдан башлап татар театры сәхнәсендә: беренче ролен «Сәйяр» труппасында уйный, Казан, Пермь, Уфа, Троицк, Петропавел шәһәрләрендәге театрларда эшли. 1924-1939 нчы елларда Татар академия театрында хезмәт итә. 1938-1945 нче елларда рус драматургларының әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. 1941 елда исә «Галиәсгар Камал» дигән альбом чыгара. Балалары – Сөембикә, Мария, Эдуард, Розенкранц (беренче никахтан), Розалия, Искәндәр (икенче никахтан).

Камал II 1948 елда Казанда вафат була.

Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовның туууына 75 ел



Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1992), Татарстанның халык шагыйре (2006), 1973 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Мөдәррис Әгъләм (Мөдәррис Зөфәр улы Әгъләметдинов) 1946 елның 13 октябрендә Зәй районының Биш Субашы (Пуст-Ашыт) авылында туган.

М.Әгъләмовның беренче шигырьләре 1959 елда Татарстан һәм Башкортстан пионер газеталарында һәм журналларында басыла. 1970 елда «Кыңгырау» исемле мөстәкыйль китабы дөнья күрә.

М.Әгъләмов 2006 елның 26 ноябрендә Казанда вафат булды.

Язучы Әсгать Фәхринең тууына 120 ел

Язучы Әсгать Фәхри (Әсгать Йосыф улы Фәхретдинов) 1901 елның 13 октябрендә Татарстанның Әлки районындагы Алпар (Иске Алпар) авылында туа.

Башлангыч белемне авыл мәктәбендә алгач, унике яшендә Казанга килеп, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. 1917-1921 нче елларда укуын Чистай шәһәрендәге педагогия һәм авыл хуҗалыгы техникумнарында, аннан соң Казан авыл хуҗалыгы институтында дәвам иттерә. Институтның ике курсын тәмамлагач, авыруы көчәю сәбәпле, ул укуын ташларга мәҗбүр була. Шуннан соң Ә.Фәхри иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Аның тәүге хикәяләре һәм нәсерләре 1919-1920 нче елларда «Кызыл яшьләр» газетасы һәм «Безнең юл» журналы битләрендә күренә, «Тормыш кочагында» исемле беренче җыентыгы 1925 елда, ә икенчесе – «Сүзләрдән чәчәкләр» дигәне авторның вафатыннан соң 1927 елда басылып чыга.

Ә.Фәхри 1926 елның 25 сентябрендә вафат була.

Язучы Марсель Зариповның тууына 90 ел

Язучы-публицист, журналист, Х.Ямашев исемендәге премия лауреаты (1972), Татарстанның (1981) һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре (1987), Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1987), 1970 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Марсель Зарипов (Марсель Харис улы Зарипов) 1931 елның 23 октябрендә ТАССРның Сарман районындагы Янурыс авылында туган.

1951-1955 нче елларда ул СССР Хәрби диңгез флотында хезмәт итә. «Татнефть» берләшмәсе каршындагы кыска курслы бораулау кадрлары мәктәбендә укып, электромонтер һөнәрен үзләштерә һәм 1958 елның көзенә кадәр «Әлмәтнефть» идарәсендә нефть промыселларында эшли. Шушы елларда аның Әлмәт шәһәр газетасы «Знамя труда» битләрендә беренче әдәби язмалары күренә башлый. 1958 елда исә М.Зариповны әлеге газета редакциясенә әдәби хезмәткәр итеп алалар. Тәрҗемәче буларак, ул Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять», Г.Ахуновның «Артышлы тау буенда», Н.Фәттахның «Итил суы ака торур» әсәрләрен русчага тәрҗемә итә.

М.Зарипов 2017 елның 6 гыйнварында Казанда вафат булды.

Шагыйрь Равил Бохараевның тууына 70 ел

Шагыйрь, прозаик, драматург, публицист, журналист һәм тәрҗемәче, Республиканың М.Җәлил исемендәге премиясе лауреаты (1986), Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (2006), 1978 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Равил Бохараев (Равил Рәис улы Бохараев) 1951 елның 18 октябрендә Казанда туган.

1968-1974 нче елларда Казан дәүләт университетының механика-математика факультетында укый һәм кибернетика белгечлеге буенча аспирантура тәмамлый. Ул – 20дән артык китап авторы.

Р.Бохараев 2012 елның 24 гыйнварында Лондонда вафат булды.

Театр белгече Рәуф Игъламовның тууына 80 ел



Театр белгече һәм тәнкыйтьче, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (1991), Д.Сираҗиев исемендәге премия лауреаты (2002) Рәуф Игъламов (Рәуф Мәхмүт улы Игъламов) 1941 елның 19 октябрендә Казанда туган.

1971-2001 нче елларда ул – Казан мәдәният һәм сәнгать академиясе, аннары Казан театр училищесы укытучысы. Татар һәм башка милли театрларның тарихына һәм үсеш проблемаларына багышланган күпсанлы мәкаләләр, «Күренекле драматург» (1987), «Уйнаучы курчаклар сәнгате» (2004), «Вакыт аша сынау» (2007) китаплары авторы.

Р.Игъламов 2016 елның 25 маенда вафат булды.

Җырчы Фәхри Насретдиновның тууына 110 ел

Җырчы, ТАССРның һәм РСФСРның халык артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Фәхри Хөсәен улы Насретдинов 1911 елның 23 октябрендә Татарстанның Апас районындагы Шәмбалыкчы авылында туган.

1921 елгы ачлык вакытында олы абыйсы Фәхрине Мәскәүгә алып китә. Анда ул мәктәптә укый, соңыннан текстиль фабрикасында эшли, шундагы драмтүгәрәккә дә йөри. Татар опера театрына нигез салучыларның берсе буларак, ул милли һәм классик операларда төп рольләрне (Ленский – «Евгений Онегин», Фауст – «Фауст», Җик-Мәргән – «Алтынчәч», Галимҗан – «Башмагым», Вәли – «Тапшырылмаган хатлар», Кирәмәт – «Качкын» оперась) беренче булып башкарды.

Ф.Насретдинов 1986 елда вафат булды.

Драматург Ризван Хәмиднең тууына 80 ел



Драматург, Республиканың М.Җәлил исемендәге премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1991), 1981 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Ризван Хәмид (Ризван Мирхәбибулла улы Хәмидуллин 1941 елның 24 октябрендә Башкортстанның Ярмәкәй районындагы Усман-Ташлы авылында туган.

Урта мәктәпне тәмамлагач, 1959 елда Октябрьск шәһәрендәге «Нефтеавтоматика» заводына күчеп, слесарь булып эшли. 1962 елда ул, Уфага барып, түбән вольтлы электр аппаратуралары заводында елга якын слесарь булып эшләгәннән соң, югары белем алу нияте белән Казанга килә һәм педагогика институтының татар мәктәпләре өчен рус теле һәм әдәбияты укытучылары әзерли торган бүлегендә укый башлый. 1971 елда аны «Чаян» журналына эшкә чакыралар, анда башта фельетонист, соңрак хатлар бүлеге мөдире булып эшли.

Р.Хәмид 2017 елда Казанда вафат булды.

Актриса Гөлсем Болгарскаяның тууына 130 ел

Татар сәхнәсенең күренекле актрисасы, ТАССРның халык һәм РСФСРның атказанган артисты (1926) Гөлсем Болгарская (Өммегөлсем Муса кызы Әҗимова-Колмәмәт-Мостафина) 1891 елның 28 октябрендә Казанда туган.

Ул уйнаган рольләрнең кайберләре: Галидә карчык («Шәмсекамәр», М.Әблиев), Зөһрә («Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш), Ханзафа («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Җиһан («Ак калфак», М.Фәйзи) һ.б. Актрисаның иҗади үсешенә Г.Тукай, Г.Камал, Ф.Әмирхан, Г.Коләхмәтов һәм Ш.Камалның йогынтысы зур була.

Г.Болгарская 1968 елның 10 гыйнварында вафат булды һәм Казанның Яңа бистә зиратында җирләнде.

Язучы Рафаэль Сибатның тууына 75 ел

Язучы, 1997 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты (2001) Рафаэль Сибат (Рафаэль Шәйхуҗа улы Хуҗин) 1946 елның 28 октябрендә туган.

Ул 1970-1978 нче елларда туган ягында укытучы булып эшли, урта мәктәптә директор була. 1978 елда Казанга килеп, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры администраторы, тулай торакта тәрбияче хезмәтләрен башкара.

1988 елдан Р.Сибат гомеренең соңгы көннәренә кадәр туган авылында яши. Ике ел Түбән Шөн мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе, унөч ел Киров өлкәсендә татар телендә чыгучы «Дуслык» газетасының Нократ Аланындагы үз хәбәрчесе һәм әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире булып эшли.

Р.Сибат 2003 елның 15 августында вафат булды.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Җуелмас хәзинә

«Зәңгәр күз» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Зәңгәр күз

(Исмәгыйль Вәлиев сүзләре һәм көе. Җәүдәт Фәйзи эшкәртүендә)

Зәңгәр күзең, күз керфегең
Тибрәндереп карама.
Күз каравың утлы уктай
Йөрәгемә кадала.

Кушымта:
Әй, бөд(е)рә чәч, зәңгәр күз,
Әйтмәм, бәгърем, авыр сүз.

Зәңгәр күзең охшатамын
Зәңгәр таң йолдызына.
Иркә гәүдәң охшатамын
Диңгезнең дулкынына.
Кушымта.

Җилфердәп искән җилләрдә
Бөдрә чәчең таралган.
Яр булып син яралмаган,
Җан көйдерергә яралган.
Кушымта.

Зәңгәр күзләр, бөдрә чәчләр –
Алар безгә тиң түгел.
Тиң түгеллеген дә беләм,
Өзелеп сөя яшь күңел.

Кушымта:
Әй, бөд(е)рә чәч, зәңгәр күз,
Әйтмәм, бәгърем, авыр сүз.

Хәзерге татар эстрадасында «Зәңгәр күз» җырының сүзләре һәм көе үзгәртелгән берничә варианты бар.

Әлеге җырның тарихы болай. Композитор Ж.Фәйзи бу җырны 1936 елда Казан шәһәрендә яшәүче Исхак Камалов дигән кешедән язып алган була. Казан елга техникумын тәмамлаган Исмай *(Исмәгыйль)* Вәлиев исемле егет Казан музыка техникумында укучы кызга гашыйк була. Егет туганнарына үзенең серен ача. Бик күпләрнең күңелен үзенә тарткан, чыннан да зәңгәр күзле, бөдрә чәчле бу чибәр кызны егетнең туганнары да якын итә. Егет музыкага да сәләтле икән: гармунда да, пианинода да матур гына уйный, тавышы да бик матур була. Уйнавын, җырлавын яратса да, кыз аның мәхәббәтен кабул итми. Кичләрнең берсендә егет кызга багышлап чыгарган җырын җырлый. Җыр барысына да бик нык тәэсир итә. Ә кыз исә, хурланыптырмы, мәҗлесне ташлап чыгып китә. Соңрак ул бер җитәкчегә кияүгә чыга.

Бу хәл 1935 елның язында була. Яшь белгеч Исмәгыйль Вәлиев, капитан ярдәмчесе булып, теплоходка эшкә урнаша. Тик Агыйдел буйлап Уфага барганда, беренче рейста ук ул, суга ташланып, үз-үзен һәлак итә. Сәбәбе – җавапсыз мәхәббәтме, әллә башкамы – билгеле түгел. Ә бу вакытта аның җыры «Зәңгәр күз» Казан халкы арасында киң таралган була инде.

«Зәңгәр күз» җырын фольклорчы **Илбарис Надиров** «Татар халык җырлары» китабында *(1965 ел)* себер татарлары фольклорының бер үрнәге дип бирә. Композитор **Ж.Фәйзи** моның белән килешми: «Зәңгәр күз», һичшиксез, Казан фольклоры, – ди. Композитор бу җырны 1936 елда җырчы Мәрьям Рахманкуловага биргән була. Җырчы исә аны бер-ике генә җырлый. Әмма радио фондында әлеге җырчы башкаруында «Зәңгәр күз»нең язмасы сакланырга тиеш, чөнки узган гасырның алтмышынчы-җитмешенче елларында М.Рахманкулова башкаруындагы бу җыр радиодан, еш булмаса да, яңгырый әле. Атаклы җырчы Фәридә Кудашева исә әлеге җырны озак еллар башкара.

Җыр А.Ключаревның «Татар халык көйләре» китабына *(42 нче бит, 1937)*, И.Надировның «Татар халык җырлары» китабына *(433 нче бит, 1965)* кертелгән. Җырның Әнвәр Бакиров язган көе дә бар.

Җыр багышланган зәңгәр күзле, бөдрә чәчле кызның кем булуы билгеле. Ул – музыкант, татар хатын-кызларыннан беренче махсус һөнәри белем алган флейтачы Разия Фәйзуллина *(1913 елда Казанның Дары бистәсендә туган, 1991 елда вафат булды)*. Беренче ире – Татар дәүләт академия театрының 1936-1938 нче еллардагы баш режиссеры Гомәр Исмәгыйлев *(1907-1983)*. Икенче ире *(1945 елдан)* – җырчы Усман Әлмиев *(1915-2011)*. Улы – рәссам Надир Усман улы Әлмиев *(1946)*.

Бу җыр Бәширә Насыйрова, Зөфәр Билалов һәм Румия Фәтхетдинова *(алар башкаруында яңгыраган җырның кайбер юллары башкача)* репертуарында бар.

Тәртип радиосы

(Сәхифә «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан көзге» тапшыруы материаллары нигезендә әзерләнде. Тапшыруның авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева.) ■

Көлке куа килә...

Гәрәй Рәхим.
Ләбиб Лерон рәсеме

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Әйт шуны!
(Пародия)

Татар җыелган җирдә
Бәйрәмсез булмый бер дә.
Гәрәй Рәхим

Татар җыелган җирдә
Бәхәссез булмый бер дә.
Өч-дүрт татар – ун мәсләк.
Берсен-берсе дөмбәсләп,
Милләт, ди-ди көн итә,
Дин, дип сәҗдәгә китә.
Кирәк икән укына,
Кирәк икән чукына –
(Мөселман һәм керәшен)
Шундый кавем, күрәсең.
Типтәрләре, мишәре,
Кырымдагы ишләре
Якты көн өмет итә.
Көн артыннан көн үтә,
Ә Мәскәү абзый көтә –
Бу татар кайчан бетә?
Тик татар төкерми дә,
Еламый, үкерми дә.
Ипи булса, шул җитә –
Җыелып бәйрәм итә.

Туфан Миңнуллин.
Илдус Әҗемов рәсеме

Мостай Кәрим (1919-2005)

Равил Фәйзуллинга

Кыска шигырьләргә остамын –
Берьюллыкны кичә очладым:
Рекорд куячакмын бик тиздән –
Шигырь торыр бары бер сүздән.

Даһилыкка, димен, ни җиткән?
Коеп куям шигырь, теләсәм,
«Мин» дигән бер бөек иҗектән.

16 ноябрь, 2001 ел

Безнең мирас №10 октябрь 2021

Фәнзаман Баттал (1939-2015)

Артык сүз

Фәнзаман Баттал.
Рушан Шәмсетдинов рәсеме

Фәнзаман Баттал, үзенә кардәш туры килүче кампитр остасы белән киңәшеп утырганда, Чуашиядән Чаллыга кайтып баручы Айдар Хәлим килеп керә. Фәнзаман, кәнәфигә иңгән Айдар Хәлимгә ишарә ясап, энесенә болай ди:

– Таныш бул, Мансур, менә бу абыең – татар дөньясының бөек язучысы, Тукай йолдызлыгындагы иң якты йолдыз!

Шул бәяне ишеткән Айдар Хәлим, ләззәт белән елмая-елмая күзләрен йома да, тәмам эреп, мәрткә киткәндәй тынып кала. Шулчак, кардәш егеткә күз кысып алгач, һәр кешедән, һәрнәрсәдән кызык табучы Фәнзаман, сүзен дәвам итеп:

– Әйе-әйе, энем, бөек язучы белән таныштың син! Бик бәхетле син! – ди дә янә өстәп куя: – Айдар абыең ул бөеклек җәһәтеннән миннән генә калыша!

Шулчак Айдар Хәлим, сискәнеп уянган көйсез сабый кебек калкына да ялварган, ыңгырашкан тавыш белән болай ди:

– Фәнзаман! Мин бит юлдан арып, тамагым кибеп кайткан кеше! Кызган мине! Сүзне артык озайтып торганчы, чәй куеп җибәрсәң шәбрәк булыр иде бит, дустым!

Фәез Зөлкарнәй (1951-1997)

Бүрек

«Салават күпере»нең баш мөхәррире булып эшли башлаган елны туганнары Зиннур Хөснияргә затлы бүрек бүләк иткәннәр иде. Ләкин озак куанырга туры килмәде аңа. Атна үтте микән, гадәтенчә, соңлап эштән кайтып барганда башыннан салдырып алганнар.

– Ярый инде, бушка килгән иде, – дип юатты ул үзен. – Хатыннан яшереп, бүрекнең маңгай өстенә илле сум акча кыстырган идем, малай тугач бала тәпие юарга дип, шунысы кызганыч, – дип бик озак сөйләнеп йөрде.

Быелгы кышның зәмһәрирләре башланып, иске бүрегенең җылысы бөтенләй калмагач, базарга киткән бу. Берничә йөз меңгә алып (акчалар үзгәрде шул инде!), бик үк яңадан булмаса да, матур гына бүрек киеп кайткан. «Идел»гә кергән чагында егетләр моны шундук күреп алдылар. Әлеге урлаткан бүрегенә охшаган икән, дип мактаучылар да булды. Зиннурның да хатирәләре уянды:

– Менә шушы төшенә иске акча белән илле сум яшергән идем, – дип сөйләп китте ул. Һәм бүрегенең маңгай турысын кайтарып күрсәтте.

Аннан урталай бөкләнгән яшел кәгазь акча килеп төште. Иске иллелек.

1995

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Без барыбыз да – балачактан

«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, әлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!

Без дә бардык борчакка
(Такмаза)

Борын-борын бер чакта,
Әйдә, барыйк борчакка.
Һич тә урын булмаса,
Тутырырбыз корсакка.
Бирән корсак, таш күкрәк,
Нишләп ятасың бу чакта?
...Бардык борчакка,
Төядек корсакка.
Килеп чыкты Якуп,
Без калдык ятып.
Килеп чыкты Йосып,
Калдык буразнага посып.
Әй без дәшми ятабыз,
Тешне генә кысып.
Килеп чыкты бер Барый,
Менә безне кармалый.
Килеп чыкты Кашшап,
Ул карый безне капшап.
Килеп чыкты Сәрвәри,
Ул да безне сәрмәли.
Килеп чыкты Мокыт,
Алды бит безне тотып!
Килеп җитте Хаттап,
Ул йөри икән безне мактап.
Менә мактый бу безне,
Аркага менеп таптап!
Бирделәр шулчакны,
Койдылар борчакны.
Качып котылдык чак-чак!



Мөдәррис Әгъләмов (1946-2006)

Бүләк

Безнең туры атыбыз
Бер сылу колын бирде –
Басу аңа, сый итеп,
Бер тубал солы бирде.

Ә болын, бүләк итеп,
Бер арба печән бирде:
«Колының җәен миндә
Уйнаклап үсәр!» – диде.

Марсель Галиев (1946)

Сәяхәтче бал корты

Истанбул аэропортыннан самолет һавага күтәрелде. Айдар әнисе янында, тәрәзәдән карап бара. Аста – диңгез зәп-зәңгәр көзге сыман…

Шулчак тәрәзәгә бал корты килеп кунды.

– Әни, әни, күр әле! Бал корты да безнең белән Мәскәүгә кайтамы? – дип, Айдар кычкырып җибәрде.

– И-и, адашып кергән инде ул самолетка, – диде әнисе, бал кортын кызганып.

Бал корты Айдарның иңенә кунды.

– Мин – сәяхәтче! – диде ул, горур безелдәп.

– Мин илләр гизәм! – диде ул, канатларын җилпеп.

– Кайда җәй – мин шунда. Австралия чәчәкләрендә бал бетүгә, самолетка утырам да Америкага очам. Анда көз җитүгә, Африкага китәм. Әнә шулай итеп илләр гизәм! – диде Бал корты, мактанып.

Айдар аның күпме илләр күрүенә кызыкты, әмма сер бирәсе килмәде:

– Ә мин Казанга кайтам. Анда мине матур песием көтә, белдеңме! – диде.

Казан сүзен ишетүгә, бал кортының күзеннән мөлдерәп яшь чыкты:

– Мин дә үз йортымны сагындым. Минем дә кайтасым килә. Мин дә бит Казан кырыендагы бер авылда яши идем. Идел болыннарындагы кебек матур чәчәкләр беркайда да юк, – диде бал корты.

Аны, бал ташымыйсың, дип өлкән кортлар шелтәләгән булганнар икән. Шуның өчен үпкәләгән дә бу, үз йортын ташлап киткән.

– Кайтып җитәлсәм, өлкән кортлар сүзен тыңлар идем, бүтән беркая да китмәс идем, – диде бал корты.

Айдар аны кәнфит кабына салды да үзе белән алып кайтты. Идел күперен чыгуга, поезд әкренәйгәч, бал кортын тәрәзәдән очырды.

Бишек җыры

Әлли-бәлли итәр бу,
Йокыларга китәр бу,
Бәү-бәү итеп, күз йомып,
Изрәп кенә китәр бу.
Алма кебек тәгәрәп,
Үсеп буйга җитәр бу,
Абыйлары артыннан
Казаннарга китәр бу,
Казаннарда укыгач,
Галим булып җитәр бу.
Әлли-бәлли, бәлли-бәү…

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

СЕНТЯБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында



● Сентябрьдә язучы, журналист, А.Алиш, Ф.Бурнаш һәм М.Ломоносов исемендәге премияләр лауреаты, табиб-пульмонолог Нәкыйп Фәсхетдин улы Каштановның «О коронавирусе – самое важное» дигән китабы дөнья күрде.

● 1 сентябрьдә «Мәйдан» журналының баш мөхәррире итеп «Көмеш кыңгырау» газетасы хезмәткәре, шагыйрә Лилия Фәттахова билгеләнде.

● 3 сентябрьдә Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай исемендәге клубында танылган прозаик Айгиз Баймөхәммәтовның (Уфа) «Нахак» китабын тәкъдим итү чарасы узды.

● 3-10 сентябрьдә Омск өлкәсендәге Үләнкүл, Каракүл авылларында һәм Омск, Тара шәһәрләрендә, Свердловск өлкәсендәге Әрәкәй авылында VI Бөтенроссия татар төбәк тарихын өйрәнүчеләр җыены булып узды. Әлеге чарада, галимнәр, төбәк тарихын өйрәнүчеләр белән бергә, «Безнең мирас» журналы, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы, «Мәдәни җомга» һәм «Шәһри Казан» газеталары хезмәткәрләре Л.Лерон, Л.Гобәйдуллин, Р.Каюмов, С.Кашапова, Й.Шәрәпова да катнашты.

● 6 сентябрьдә Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре Гәрәй Рәхим (Григорий Васильевич Родионов) вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде Лаеш районындагы Габишево авылы зиратында җирләнде.

● Сентябрьдә төрки дөньяның «Кардәш каләмнәр» әдәби һәм иҗтимагый-мәдәни журналының сентябрь санында күренекле галим Надир Дәүләт (1944-2021) хакында мәкалә басылды. Аны Мимар Синан университеты галиме Исмәгыйль Түркоглу язган. Мәкаләдә Надир Дәүләтнең морзалар нәселеннән булуы әйтелгән, әнисе Рокыя һәм әтисе Ибраһим Дәүләткилделәрнең Ерак Көнчыгышта «Милли байрак» исемле татарча газета чыгарулары һәм шуның өчен совет хакимияте тарафыннан кулга алынып, 10 елга хөкемгә тартылулары да бәян ителгән.

● 7 сентябрьдә рәссам, каллиграф, шамаилләр ясау остасы (ул ясаган шамаилләр Иркутскидагы, Буа һәм Мөслимдәге мәчетләрдә

урын алган), Россия һәм Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзасы, Мөслим районының Метрәй авылы тумасы Зөлфия Мөхәммәтдинова вафат булды. Мәрхүмәнең җәсәде туган авылы зиратында җирләнде.

● 10 сентябрьдә Самосыроводагы Мөселман зиратында Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисты Исламия Мәхмүтова каберенә таш куелды һәм мәрхүмә рухына багышлап Коръән аятьләре укылды.

● 10 сентябрьдә Свердловск өлкәсендәге Әрәкәй авылында узган VI Бөтенроссия төбәкчеләр җыенында бертөркем зыялылар (алар арасында «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон да бар иде) татарча диктант язды.

● 13 сентябрьдә Казакъстанның Күкчәтау шәһәрендә, Татарстанның атказанган мәдәният эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, язучы Ибраһим Сәлаховның тууына 110 ел тулу уңаеннан, шәһәр һәм өлкә җәмәгатьчелеге, Казакъстан халыклары ассамблеясе, ветераннар оешмалары советы, шулай ук туганнары һәм якыннары катнашында, әдип яшәгән йорт янында митинг булды. Әлеге чарада ветераннарның шәһәр советы рәисе Шияп Алиев, Дуслык һәм татулык сарае директоры Ярмәк Ногманов, Акмулла өлкәсе татарлары һәм башкортлары иҗтимагый берләшмәсе рәисе Рафаил Сулькарнаев үзләренең истәлекләре белән уртаклашты.

● 14 сентябрьдә Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Казакъстан Республикасының Казандагы яңа Генераль консулы Ерлан Искаков белән очрашты. Әңгәмә барышында сүз мәдәният, мәгариф, телне һәм тарихи мирасны саклап калу өлкәсендәге уртак проектларның мөмкинлекләре турында барды.

● 18 сентябрьдә, Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, ТФ академиясе академигы, тарих фәннәре докторы Индус Таһиров, ТР Мәдәният министрлыгының массакүләм мәгълүмат чаралары һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек бүлеге мөдире, тарихчы Айрат Фәйзрахманов, Татарстанның атказанган урманчысы Ирфан Халитов, авыл хуҗалыгы белгече, галим-агроном Харис Камалиев, «Безнең мирас» журналы хезмәткәре Ленар Гобәйдуллин, Гомәр хаҗи Гайнетдинов, мөгаллим-остаз Зөлфәт Мингалиев һәм шәкертләр катнашында, Казандагы Ал мәчеттә «Күренекле шәхесләребезнең исемен мәңгеләштерү, тарихи биналарны саклау мәсьәләләре» дигән түгәрәк өстәл утырышы узды. ■

МИРАСВОРД

Мәҗүсиләр табына торган сын, балбал, пот

Гарәп хәрефе

«Галия» мәдрәсәсендә (Уфа) чиркәс шәкертләре чыгарган кулъязма журнал

Ишкәкле спорт көймәсе

Олы ир туган, абый

Наип ... (әдәбият галиме, тәнкыйтьче)

Кәҗә мамыгын чистарта торган тарак

Курган өлкәсендә татар-башкортлар күпләп яши торган район

Шабаев, Макаров / Әхсән Баян поэмасы

1930-1932 елларда Казанда татарча чыккан әдәби журнал

Тартыктан соң сузык авазның булмавын күрсәтүче билге

Актуаль темага караган эстрада постановкасы

Бик тиз ярсып, кызып китүчән

Шагыйрь Нур ... / ... Нәҗми

Яуга чакыру авазы

Ерак басуда эшләүчеләрнең күчмә өе

Ашлык әрҗәсе / Көлтә киптерү урыны

Дельфинның бер төре

Куышлы уйнаганда аркага бәрү һәм шулай бәргәндә әйтелүче сүз

Язучы ... Вергазов

Татар интеллектуаль милек агентлыгы

Габдулла Тукайның 1908 елда язган шигыре

... Такташ / Язучы ... Хәсәнов

Бензин маркасы / ... Акъегет

Балаларның кояшка, болытка һ.б. атап әйтә торган такмазасы

Татар халкының милли ризыгы

«Алтынчәч», «Сания», «Качкын»

Пар / Гаффар, Сафиуллин

... Гыйззәт

Тозлы күл суы

Тур Хейердал көймәсе

... Хангильдин (тел белгече, педагог)

Шагыйрь ... Кәшфуллин

Язучы ... Камалов

Данлы исем, яхшы ат

Шигырь үлчәменең бер төре

9 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Алкей, «Түбә», ләһ, илд, «Афәт», һун, кабилә, әзи, танин, иртүк, әче, кам, авлос, Дунай, Ева, тари, яса, Лорка, Әюп, Ярми, Одра, ерма, атта, Ван.
Өстән аска: Аллаһбирдиев, ур, каһин, намә, әукат, Юзеев, «Йолдызкай», ял, Оман, «Солдат», атчабар, ти, Атнабаев, Амаяк, фин, Ленар, Әбҗәлилов, тән, Садри.

Рәис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас»
елъязмасы / октябрь



Әстерхан каласы. ***Хаҗи Абдулла Дубин тупланмасыннан***

465 ел элек (1556)

Явыз Иван гаскәре Хаҗитархан каласын басып ала. Кала яңа урынга күчерелә. Татарлар, патша әмере буенча, иске каланы ташлап чыгып, Иделнең каршы ярына күченергә мәҗбүр булалар. Беренче Хаҗитарханнан бераз түбәнрәк урында ныгытма-крепость төзелә. Хәзерге Әстерхан – шуннан үсеп чыккан кала.

220 ел элек (1801)

Казанда ачылган беренче татар типографиясендә (нашире – Габделгазиз Туктамыш улы Бурашев) тәүге ике китап дөнья күрә. Боларның беренчесе – «Әттәһөҗи» исеме белән мәктәп-мәдрәсә өчен чыгарылган татар әлифбасы, икенчесе – Һәфтияк.

115 ел элек (1906)

Кырымның Бакчасарай шәһәрендә «Тәрҗеман» нәшрияты тарафыннан һәм Исмәгыйль Гаспралы мөхәррирлегендә балаларга атап «Галәме сыйбийан»(«Сабыйлар дөньясы») дип аталган әдәби журнал (айга ике тапкыр) чыга башлый.

100 ел элек (1921)

Габдулла Тукайның «Өзелгән өмет» («Разбитая надежда») исемле шигырьләр җыентыгы П.Радимов тәрҗемәсендә урыс телендә басылып чыга.

90 ел элек (1931)

Урта Идел өлкәсендә беренче күчмә татар театры һәм Уралда күчмә татар-башкорт эшче театры оештырыла.

80 ел элек (1941)

12 октябрьдә Абдулла Алиш, чолганышта калып, фашистлар әсирлегенә эләгә.

Октябрь-декабрь айларында Муса Җәлил Минзәлә шәһәрендә хәрби-политик курсларда укый.

65 ел элек (1956)

20 октябрьдә Болгариянең башкаласы София шәһәрендә «Шүрәле» балетының премьерасы була.

*Журналга **Марат Закир** әзерләде.* ■

Содержание. Октябрь 2021

И останется в мире слово моё...: Мударрис Аглямов.

Историческое наследие: «Знаки Золотой Орды». Д.Гайнетдинов; «Казанская трагедия»; «Учитель мулла Садыйк». Д.Гарифуллин; «Счастливая Фатима из Сарманово». Д.Кашипова; «Казачьи войска Сарманово». В.Ихсанов; «Сармановцы в Первой мировой войне». Г.Нуретдинова; «Сарманово под смутой политической репрессии». Ф.Салихова; «1963-1965 года: общие исторические даты Сармановских и Муслюмовских районов». *Р.Шафигуллина;* «Ох, сейчас бы быть в деревне!» М.Файзи.

Татарский мир: Фарит Хуснуллин: «Наше прошлое достойно гордости, будущее проникнуто надеждой»; «Лошади, собаки и люди». Р.Джамал.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Уроки религии». С.Бикбулат.

В глубинах памяти: «Стамбулское издание сочинений великого поэта Котб (1968)». Х.Миннегулов; «Утерянная тетрадь». С.Сулейманова; «Урок, приподнесённый бабушкой». М.Аглямов; «Путешествие в Аркаим». Л.Хамидуллин; «В памяти, до сих пор в памяти!».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:

Кырым татарларының балалары («Кырым тамгалары». *Л.Гобәйдуллин*)

● **Укытучы Сания Галимова истәлекләре.**
Равил Салиев

● **Казаковлар мирасы: «түгәрәк өстәл»**

● **Кырым тамгалары.**
Ленар Гобәйдуллин

Татар әдипләре — Сарманда

Сарман төбәге язучылары белән очрашу

Дамир Гарифуллин (сулда), Госман Садә, Хәниф Хәйруллин



Хәниф Хәйруллин һәм Илдар Юзеев

Әсләх Гаязов, Әзһәр Габиди, Хәниф Хәйруллин. 1966 ел

Марсель Галиев (сулда), Ринат Мөхәммәдиев, Гәрәй Рәхим, Әзһәр Габиди, Клара Булатова

Фотолар Сармандагы Бөек Ватан сугышы һәм туган якны өйрәнү музее фондыннан алынды.

ИКЕ САРМАН

Сарман авылының совет чорындагы күренеше.
Фото Бөек Ватан сугышы һәм туган якны өйрәнү музее фондыннан алынды.

Бүгенге Сарман

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.